Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының
мәгариф идарәсе

# Сыйныф сәгатьләрен конструкцияләү

Методик җыентык

Казан
2021

УДК 372.8
ББК 74.26

Казан шәһәре мәгариф идарәсенең фәнни-методик совет карары белән басылды

**Фәнни редакторы:**

**З.И.Җамалетдинова**, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының мәктәпкәчә һәм башлангыч белем кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты

**Рецензентлары**:

**Э.Х.Кадирова**, Татарстан Фәннәр Академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты

**Л.М.Антонова**, Совет районы Дәрвишләр бистәсе балалар иҗаты үзәгенең милли белем һәм тәрбия бүлеге мөдире

**Төзүчеләре**:

**Р.К.Зиннәтуллин**, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф идарәсе методисты,

**И.М.Ильясова**, Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районы мәгариф бүлеге методисты,

**Л.З.Бикмөхәммәтова**, Казан шәһәре Совет районы мәгариф бүлеге методисты,

**М.В.Җиһангирова**, Казан шәһәре Вахитов һәм Идел буе районы мәгариф бүлегенең укыту-методик секторы мөдире

**Компьютерда биткә салучы:**

**М.А.Потанина**, Казан шәһәре мәгариф идарәсенең белем процессын ресурслар белән тәэмин итү бүлеге методисты

**Сыйныф сәгатьләрен конструкцияләү: методик җыентык**. - Казан: Казан шәһәре мәгариф идарәсе. 2021. – 120 бит

Җыентыкта сыйныф сәгатьләре үткәрү өчен үрнәк план-конспектлар, сценарийлар, технологик карталар бәян ителгән. Җыентык татар телендә белем бирә торган гомуми белем оешмаларында эшләүче укытучылар, сыйныф җитәкчеләре, директор урынбасарлары, өстәмә белем педагоглары өчен тәкъдим ителә.

© Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф идарәсе, 2021

## Сыйныф сәгате – ул тәрбия процессын оештыруның мөһим формаларыннан берсе

Бүген тәрбия эшен оештыруның мөһим формаларыннан берсе – укучылар белән үткәрелә торган сыйныф сәгате. Ул атнага бер тапкыр, билгеле бер көнне һәм билгеле бер вакытта үткәрелә. Сыйныф сәгате вакытында сыйныф җитәкчесе укучылар белән әңгәмәләр үткәрә, аларны тәрбияли, белем дәрәҗәсен киңәйтә, сыйныф коллективы белән эшләүнең бурычларын һәм максатларын билгели. Сыйныф сәгате – сыйныф җитәкчесе белән укучылар арасында аралашу формасы. Бүгенге көндә ул һәр гомуми белем оешмасында үткәрелә. Уку расписаниесенә кертелә һәм, югарыда әйтелгәнчә, атнага бер тапкыр уздырыла. Үткәрү вакыты 40 - 45 минут тәшкил итә. Гомумән алганда, мондый бүленеш бик үк дөрес түгелдер. Сыйныф сәгате азрак яки күбрәк вакытны да алырга мөмкин, чөнки анда сыйныф җитәкчесе куйган бурычларны үтәү сорала. Сыйныф сәгатен сыйныф бүлмәсендә дә, актлар залында да, китапханәдә, музейда, гомумән, класс сәгатен уздыру өчен уңайлы булган теләсә нинди урында үткәрергә мөмкин.

Мәктәптә сыйныф сәгате берничә максатны күздә тота. Беренче чиратта, бу мәгърифәтчелек, ул укучыларны тормышның төрле өлкәләрендә белемнәр даирәсен киңәйтүдән гыйбарәт. Алга таба, юнәлеш бирү, ягъни мәктәп укучылары тормышының гамәли ягына, аларның үз-үзләрен тотышына һәм тормышка мөнәсәбәтенә йогынты ясау. Ориентлашуга ярдәм итү – әйләнә-тирә чынбарлык объектларына билгеле бер мөнәсәбәтләр, рухи һәм матди кыйммәтләр формалаштыру.

Сыйныф сәгатенең төп тәрбияви бурычларына түбәндәгеләр керә:

-укучыларның индивидуальлеген күрсәтү өчен шартлар тудыру;

- аларның әйләнә-тирә дөнья турындагы белемнәрен баету;

- эмоциональ-тойгылы мохит формалаштыру;

- сыйныф коллективын туплау.

Сыйныф сәгатен үткәрү формалары төрле булырга мөмкин: лекция, әңгәмә, конкурслар, викториналар, уеннар, ШТК (шаяннар, тапкырлар клубы), мәртәбәле шәхесләр белән очрашулар, экскурсияләр, дискуссия, телдән журнал, социаль-мәдәни проектлар һ.б.

Сыйныф сәгатенә әзерләнгәндә, иң элек теманы барларга кирәк. Моны укучылар белән әңгәмә яки сораштырулар (анкета) үткәреп, алдан ук ачыкларга мөмкин. Сыйныф сәгате темасын сайлаганда, укучыларның яшь үзенчәлекләрен, аларның мәнфәгатьләрен белергә кирәк. Сыйныф сәгате сценариен язганчы, иң элек үзеңә түбәндәге сорауларны биреп карарга кирәктер:

1. Балаларны сыйныф сәгатендә катнашуга ничек кызыксындырырга?

2. Әзерлек эшенә ничек һәм кайчан тотынырга?

3. Укучыларның кайсысы әлеге сыйныф сәгатен үткәргәндә төп ярдәмче була алыр иде.

4. Балалар кайсы биремнәрдә үзләрен тулырак күрсәтә алачак?

5. Сыйныф сәгатенә ничек итеп дөрес йомгак ясарга?

Әлбәттә, һәрбер сыйныф сәгатенең план-конспекты, сценарие класс җитәкчесе тарафыннан гына язылырга тиеш дигән күрсәтмә юк. Педагоглар әзер материалларны төрле интернет-ресурслардан, махсус журналлардан (“Мәгариф”, “Гаилә һәм мәктәп” һ.б.) алып, класс сәгатьләрен үткәргәндә кулланырга мөмкин. Ләкин шул ук вакытта эшкәртмәләрнең күбесенә үзгәрешләр кертү мөһимдер. Чөнки теге яки бу биремнәр балаларга артык катлаулы булып тоелырга яки аларны кызыксындырмаска да мөмкин. Мондый биремнәрне җиңелрәк яисә кызыклырак сорауларга алмаштырырга кирәк.

Тулаем алганда, сыйныф сәгатенә әзерлек түбәндәге юнәлешләрдән тора:
1. Теманы һәм максат-бурычларны ачыклау.
2. Үткәрү урынын һәм вакытын билгеләү.
3.Төп юнәлешләрне билгеләү.
4. План һәм сценарий әзерләү.
5. Материал сайлау.
6.Үткәрү урын билгеләү, аны бизәү.
7. Сыйныф сәгатендә катнашучыларны билгеләү.

Сыйныф сәгатен уздырганнан соң, аңа анализ ясау сорала. Балаларның фикерләрен, теләкләрен белү дә файдалы булачак.

Сыйныф сәгатен нәтиҗәлерәк үткәрү өчен түбәндәге киңәшләргә таянырга мөмкиндер: 1. Сыйныф сәгате үткәрелә торган бүлмә җыештырылырга һәм җилләтелергә тиеш. 2. Чәчәкләр, кәгазь гирляндалар, шарлар ярдәмендә кабинетны бизәү мәслихәт. 3. Сыйныф сәгатен тактага яки экранга язып куярга кирәк. Шулай ук афоризмнар, күренекле шәхесләрнең фикерләрен куллану сыйныф сәгатен нәтиҗәлерәк итәр. 4. Мультимедиалы проекторлар һәм презентацияләр куллану укучыларның материалга булган кызыксынуын сизелерлек арттырыр. 5. Сыйныф сәгатен уздырганда күрсәтмә материаллар - брошюралар, буклетлар, сүзлекләр, карталар һ.б. турында онытмагыз. 6. Башлангыч мәктәптә сыйныф сәгатьләрен уен, сәяхәт рәвешендә уздыру яхшырак. Шулай булганда, сез укучыларны тизрәк кызыксындыра, аларның игътибарын җәлеп итә аласыз. 7. Укучыларга уңайлыклар, тиешле шартлар тудыру турында да онытмагыз. Аларга ничек ошый, шулай утырырга рөхсәт итегез. Дәрестән аермалы буларак, парталарны түгәрәк буенча урнаштырырга, күчерергә мөмкин.

Сыйныф сәгатен уздырганда булышу өчен шулай ук медицина, хокук саклау, гражданнарның иминлеген тәэмин итү системасында эшләүче белгечләрне, психолог, мәдәният хезмәткәрләрен чакырырга була. Алар кайбер мәсьәләләрдә сыйныф җитәкчесеннән мәгълүматлырак булырга, сыйныф сәгатен кызыклырак, нәтиҗәлерәк үткәрергә ярдәм итәргә мөмкин.

Сыйныф сәгатенең структурасы нинди булырга тиеш соң? Гадәттә, ул кереш өлештән тора. Ягъни аның бурычы - укучыларның игътибарын активлаштыру, проблемаларны билгеләү. Сыйныф сәгате бурычлары белән билгеләнә торган төп өлеш аның эчтәлеген тәшкил итә. Йомгаклау өлешендә исә укучыларның үз-үзен тәрбияләүгә булган ихтыяҗлары стимуллаштырыла.

Сыйныф сәгате түбәндәге мәсьәләләргә (юнәлешләргә) багышланырга мөмкин:

Гражданлык-патриотик

Әхлакый һәм рухи тәрбия

Хезмәткә һәм иҗатка уңай мөнәсәбәт тәрбияләү, профориентация

Интеллектуаль тәрбия

Сәламәтлекне саклау

Социаль һәм медиамәдәни тәрбия

Мәдәни һәм эстетик тәрбия

Хокук тәрбиясе һәм куркынычсызлык культурасы

Гаилә кыйммәтләрен тәрбияләү

Коммуникатив культура формалаштыру

Экологик тәрбия

Әлеге тематикадан чыгып, сыйныф сәгатен уздыру өчен кайбер темалар тәкъдим ителә: “Батырлык һәм кыюлык битләре”, “Әдәплелек мәктәбе. Үз-үзеңне тоту культурасы һәм син”, "Үз илеңә чын мәхәббәт үз телеңне яратудан башка мөмкин түгел” (К.Паустовский), “Мөһим һәм кирәкле һөнәрләр турында”, “Талант һәм хезмәт”, “Китап безнең тормышыбызда”, “Сәламәт булу модада”, “Мин сыйныфташларым күзлегеннән...”, “Мода һәм культура”, “Хәтәр виртуаль дөнья. Интернет: уңай һәм тискәре караш”, “Имин көн - имин тормыш”, “Мин үз гамәлләрем өчен җаваплы”, “Минем гаиләм - минем байлыгым”, “Аралашу серләре”, “Хәзерге заманның экологик проблемалары”, “Нәрсә ул бәхет?”, “Дуслык белән көчле без”, “Низаглы хәлләр. Хәл итү юлын ничек табарга?”, “Нәрсә ул имидж?”

Шулай итеп, сыйныф сәгате - ул тәрбия процессын оештыруның иң мөһим формаларыннан берсе. Ул атнага бер тапкыр уздырыла. Дәрес барышында укытучы укучыларның мәдәни дәрәҗәсен күтәрә, аларның тормышка җайлашуларын һәм рухи кыйммәтләрен формалаштыра, коллектив

оештыра. Үткәрү рәвеше, дәрес темасына һәм укытучы куйган максатларга карап, теләсә ничек булырга мөмкин.

*Р.К.Зиннәтуллин, Казан шәһәре мәгариф идарәсе методисты,*
*Татарстан Республикасының атказанган укытучысы,*
*Кол Гали исемендәге халыкара бүләк иясе*

*Төзүчеләр: Казан шәһәре Идел буе районы 73 нче урта мәктәпнең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Арсланова Әнисә Дәүли кызы һәм беренче квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Шәрәпова Лилия Каюм кызы*

**Тема: Тел күрке – сүз.**

**Максатлар:** 1. Укучыларда туган телгә карата хөрмәт, ихтирам, горурлык хисләре тәрбияләү.

2. Укучыларда кешелеклелек сыйфатларын үстерү.

**Бурычы:** Туган телнең матурлыгын, байлыгын күрсәтү.

**Җиһазлау:** Рәсемнәр (өй, кояш); биремле карточкалар, тартмалар, видео, экран, ноутбук, колонкалар.

**Сыйныф сәгатенең барышы**

**I. Оештыру өлеше**

Хәерле көн, укучылар! Әйдәгез, барыбыз да матур итеп басып, кулга – кул тотышыйк, бер-беребезгә елмайыйк. Куллардан – кулларга җылылык, күңелдән – күңелгә рәхәтлек йөгерсен, йөзләргә якты нур булып елмаю сирпелсен. Менә шушы җылылык , рәхәтлек, елмаю безгә көн буена җитәрлек көч бирсен. Хәзер матур итеп утырыгыз.

**II. Төп өлеш**

Бүген без сезнең белән бер бик матур аланга барабыз. Күзләрегезне йомыгыз әле! (*Күзләрен йомалар, шул арада өй макеты куела*).

- Укучылар, күзләрегезне ачыгыз әле. Сез монда нәрсә күрәсез?
- Өй, кояш, чәчәкләр.
- Укучылар, бу гади генә өй түгел, бу – белем йорты. Әйдәгез әле, шушы өйгә кереп карыйк. Өйгә кергәч, иң беренче нишлибез?
- Бу йортта яшәгән кешене эзлибез.
- Бу өйдә кемнәр яши дип уйлыйсыз?
- Кешеләр.
- Әйе, кеше – йортның хуҗасы. Кеше йортны төзи дә, җимерә дә ала. Ә җәмгыятебездә кеше булып яшәү өчен, без нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Әйтеп карыйк әле. Аның өчен менә шушы өйгә игътибар итәбез, һәр бүрәнәдә бер сыйфат бирелә. (*Балалар әйткән саен, бүрәнәләр ачылып барыла*).
- Тырыш
- Уңган
- Гади
- Акыллы
- Намуслы
- Тәртипле

- Эшчән
- Лаеклы
- Укучылар, бу сүзләрнең беренче хәрефләреннән нинди сүзтезмә килеп чыга?
- ТУГАН ТЕЛ

Хәзер мин сезгә диктор Зәмирә Рәҗәпова укуында бер видеоязма куям. (*Видеоязма куела*). Сез игътибар белән тыңлап, нәрсә соң ул – тел, дигән сорауга җавап табарга тиеш буласыз. (*Укучыларның җаваплары тыңлана*)

Әйе, иң беренче чиратта тел - ул аралашу чарасы. Кешенең бөтен тормышы тел белән бәйле. Туганнан алып, соңгы сулышына кадәр тел һәм сүз – кешенең аерылгысыз юлдашы. Ә телнең төп коралы – сүз. Ачык, дөрес итеп сөйли белмәсәң, иң ялкынлы хисләр дә кешеләргә барып җитә алмый.

- Безнең телебез нинди тел? (*Балаларның җаваплары тыңлана*)

Татар теле – безнең милли телебез. Без шушы телдә сөйләшеп аралашабыз, белем туплыйбыз. Шуңа күрә без туган телебезне яратырга, аны яхшы белергә, әдәби телдә сөйләшергә тырышабыз. Сүз байлыгы чикле булса, теләгән фикереңне аңлатып бирүе бик авыр. Әдәби телне үзләштерү өчен, күп укырга, хәтердә калдыра барырга кирәк.

“Иң татлы тел – туган тел, анам сөйләп торган тел,” – ди халык. Менә шушы татлы, туган телнең серләренә, матурлыгына, байлыгына төшенү өчен, телнең сүзлек байлыгын, ягъни лексикасын белү зарур. Тел байлыгыбызны арттыру өчен, мин сезне “Тел күрке – сүз ” дип исемләнгән лексик чарага чакырам.

Чарабызны нәтиҗәле, уңышлы үткәрү өчен, мин классны 3 төркемгә бүләм.

Мин һәр төркемгә конверт бирәм. Сез шушы конверттагы сүзләрне бер юлга җыярга тиешсез. Сезгә 1 минут вакыт бирелә. (*Ком сәгате куела*)

1 нче төркемнән башлыйбыз.

Тел дигән дәрья бар, (*1 төркем*)
Дәрья төбендә мәрҗән бар.(*2 төркем*)
Белгәннәр чумып алыр, (*3 төркем*)
Белмәгәннәр коры калыр. (*Бергә уйлап табалар*)

Чыннан да, чара ахырына кадәр сүзләрнең мәрҗән икәнен аңласак, максатыбызга ирешкән булырбыз.

1. “Әйтем – сүзнең бизәге, мәкаль- сүзнең җиләге”.

Мин сезгә битләр бирәм, анда мәкальләр язылган. Шул мәкальләрнең башын ахырына дөрес итеп тоташтырырга кирәк. Сезгә 1 минут вакыт бирелә. (*Ком сәгате куела*)

1 нче төркемгә

1. Ана теле (бер булыр).
2. Әдәп башы (тел).
3. Иле барның (теле бар).
4. Туган телем үзем өчен, (башка тел көнем өчен).

2 нче төркемгә

1. Татлы тел (тимер капканы ачар).
2. Тел байлыгы бай итәр, (тел юклыгы юк итәр).
3. Татлы сүздән (тел корымый).
4. Сөйдергән дә тел, (биздергән дә тел).

3 нче төркемгә

1. Инсафлының ( теле саф).
2. Теле бозыкның (күңеле бозык).
3. Теле татлының (дусы күп.)
4. Кылыч ярасы бетәр, ( тел ярасы бетмәс).

Афәрин, укучылар, сез бу эшне дә бик яхшы башкарып чыктыгыз.

2. “Фразеологизмнарны аңлату” бәйгесе.

3 төркемгә дә тартмалар бирелә. Шул тартмалардан фразеологизмнарны алып укып, бер сүз белән әйтергә. Сезгә 3 минут вакыт бирелә.(*Ком сәгате куела*)

1 нче төркемгә

1. Белем эчү- уку
2. Сагыз булу - әрсезләнү
3. Учта эретү - буйсындыру
4. Таң калу - соклану

2 нче төркемгә

1.Сабын күбеге очыру-мактану
2.Кәкре каенга терәтү – алдалау
3.Тетмәсен тетү- орышу
4.Җене сөймәү- яратмау

3 нче төркемгә

1. Тал чыбыгы ашату-кыйнау
2. Терсәкне тешләү – үкенү
3. Салпы ягына салам кыстыру – алдалау
4. Тел йотарлык - тәмле

Бик яхшы, сез бу чарада да сынатмадыгыз.

3. “Тәрҗемәчеләр” бәйгесе

Фразеологизмнарны мәгънәләре туры килерлек итеп тәрҗемә итү.

*(Чиратлашып тәрҗемә итәләр*).

1. Вертеть хвостом - койрык болгау
2. Золотые руки - алтын куллы
3. Сидеть сложа руки - кул кушырып утыру
4. Длинный язык - озын телле
5. В мутной воде рыбу ловить – болганчык суда балык тоту
6. Говорить в лицо – йөзенә бәреп әйтү
7. Волос долог, да ум короток – чәче озын, акылы кыска
8. Бездонная бочка –төпсез мичкә
9. Акча капчыгы – денежный мешок

Әйбәт, бу сынауны да уңышлы үттек.

4. Шигырь уку

Укучылар, туган телебездә – татар телендә бик матур шигырьләр дә күп бит безнең. Хәзер безгә һәр төркем үзенең шигырен тәкъдим итә.

1 нче төркем

Туган телемдә сөйләшеп
Яшим мин туган илдә.
“Туган ил” дигән сүзне дә
Әйтәм мин туган телдә.

Иң изге хисләремне мин
Туган телдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин, яратам.

2 нче төркем

Мин сөйлим анам телендә,
Яшим атам җирендә.
Бу бәхет миңа бирелгән
Туган йорт бишегендә.

Тәүге кабат аяк басып
Сукмактан киттем йөреп.
Әйттем анам теле белән:
-Мин җирдә кеше! – диеп.

3 нче төркем

Күзләремне ачты минем,
Иркәләде үз телем.
Үз телем яктыртты юлны,

Үз телем бирде белем.
Үз телеңне сөймәгәндә
Ярты ул алган белем.
Канатсыз коштай буласың,
Белмәсәң ана телен.
Әткәм – әнкәм телен белсәң,
Алдашмассың кайда да.
Туган телемдә эндәшәм
Кояшка да, айга да.
Туган телемдә аңлашам
Үткән, бүгенем белән...
Әлифбамны дога итеп
Укыймын күңелемнән.
Игелекле булып үсим
Газиз туган телемә.
Туган тел бер генә була –
Әнкәй кебек бер генә.

Бала, тугач та, анасының телен үзләштерә. Шуңа күрә ул “Ана “ теле дип атала. “Ана” сүзе аһәңле , моңлы, шигъри сүз ул.

Ләкин кайберәүләр: “Татар теле белән кая барып була?” – диләр. Туфан Миңнуллин әйтмешли, япон теле белән кая барып була соң? Мондый сүзләр һәм күренешләр җанны телгәли. Сез бу сүзләр белән килешәсезме? (*Балаларның фикерләре тыңлана*).

Тирә-юнебездә руслашу гадәти күренешкә әйләнеп бара. Саф татар авылларында гына татар теле саклана. Бу һәр татар кешесен сискәндерергә, борчырга тиеш. Кая таба барабыз? Татар теле Кызыл китапта гына калмасмы? (*Балаларның фикерләре тыңлана*).

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай да “Халык – зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул, - дигән.

Ә бит бездән еракта яшәүче милләттәшләребез үз телләрен онытмый. Читтәге милләттәшләребездән үрнәк алып, безгә дә телебезне сакларга, үстерергә кирәк.

Татар теле дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелде. Яшәгән җиребез – Татарстан Республикасы. Безгә төп йортыбызның хуҗалары булып яшәргә кирәк. Туган телебез – татар теле, шушы чәчәкләр кебек матур, кояш нурларыннан җылылык алып, мәңге шиңмичә балкып, нур сибеп торсын иде. Бүгенге чарадан туган телебез язмышы турында уйланып таралабыз икән, димәк, безнең татар җанлы халкыбыз яши икән әле, диярбез.

Тел ачылгач әйтә алсаң: “Әни!” – дип,
Тел ачылгач әйтә алсаң: “Әти!” – дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.
Соң минутта әйтә алсаң “Әни!” – дип,
Соң минутта әйтә алсаң “Әти!” – дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр...
Туган тел ул - бездән соң да
Яшәр өчен туган тел.
Бүгенгедән киләчәккә
Дәшәр өчен туган тел.

**III. Йомгаклау өлеше**

Чарабызны йомгаклап, бөек шагыйребез Г.Тукайның “Туган тел” җырын башкарабыз. (*Күмәкләшеп “Туган тел” җыры башкарыла*).

Тел – халыкның, милләтнең иң беренче, иң әһәмиятле билгесе. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен туган телне кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү – һәр кешенең изге бурычы. Бүгенге чарабыз сезгә телебезнең мөһимлеген, зарурлыгын ача алган булса, мин бик шат булыр идем.

*Төзүчеләр: Казан шәһәре Идел буе районы 19нчы гимназиянең*
*югары квалификация категорияле туган тел һәм әдәбият укытучылары*
*Хәйбуллина Ләйлә Минненакип кызы,*
*Гыйззәтуллина Линиза Миңнехөрмәтулла кызы*

**Тема: “Туган илем- татар җире, туган телем- Тукай теле”**

**Сыйныф сәгатенең төре:** квест-уен

**Максат, бурычлар:**

1.Туган телгә мәхәббәт хисе булдыру, ана теленең мөһимлеген күрсәтү;
2.Башка телләргә карата кызыксыну, ихтирамлы һәм хөрмәт хисенә ия булу;
3.Балаларның уйлау һәм иҗади сәләтләрен үстерү, фикерне дәлилли, нәтиҗәләр ясый белү.

**Катнашучылар:** 5-7 сыйныф укучылары өчен.

**Сыйныф сәгатенең барышы**

**1. Оештыру өлеше.**

Укытучы:

- Хәерле иртә, кадерле укучылар! Әйдәгез бер-беребезгә хәерле иртәне ишарәләр белән дә теләп карыйк. Мин кемнәргә мөрәҗәгать итәм, шулар мине кул күтәреп сәламлиләр.

- Кызларга хәерле иртә!

- Егетләргә хәерле иртә!

- Кемнәр конфет ярата аларга хәерле иртә!

- Кемгә бүгенге һава торышы ошый, аларга хәерле иртә!

- Кемнәр яңа белем алырга килде, аларга хәерле иртә!

- Кемнәрнең кәефләре яхшы, аларга да хәерле иртә!

- Бик әйбәт! Көнне һәрвакыт елмаеп башларга кирәк, шул вакытта ул уңышлы узачак дип уйлыйм мин.

**II. Актуальләштерү.**

Укытучы:

- Бүген без сезне гадәти булмаган, кызыклы квест-уен үтәргә, үзара көч сынашырга чакырабыз. Квестның темасын да үзегезгә табарга туры киләчәк. Әйдәгез, сыйныф сәгатен башлап җибәрик. Һәрбер катнашучыга рәсемнәр таратылачак. Беренче карашка алар сезгә аңлашылмас, ләкин әлеге рәсемнәрне пазллар рәвешендә кулланып, гомум бер рәсем төзергә мөмкин.

*(Укучыларга кисәкләргә бүленгән рәсемнәр таратыла. Алардан 4 рәсем килеп чыгарга тиеш: гармун, кеше, сәгать, учак. Балалар шул рәсемнәр буенча төркемнәргә җыйналалар.)*

Укытучы:

- Афәрин, рәсемнәрнең өлешләрен берәштереп, сез картиналарны җыя алдыгыз һәм 4 төркемгә туплангыгыз. Командаларны өстәлләр артына чакырабыз.

*(Укытучы картиналарны тактага элә)*

Укытучы:

- Ягез, танышып үтик, нинди рәсемнәр килеп чыкты икән?

**1 төркем** *гармун.*



**3 төркем** *сәгать*




**2 төркем** *кеше.*



**4 төркем** *учак*



**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укытучы:

- Укучылар, сез ничек уйлыйсыз, бу рәсемнәрне нәрсә берләштерә икән?

*(Һәр төркемгә сүз бирелә, укучыларның җаваплары тыңлана)*

Укытучы:

- Әйе, бу рәсемнәрнең барсында да “тел” бар: гармун теле, кеше теле, сәгать теле, янгын теле.

Сәгыйтьнең дә теле бар,

Сәгатьнең дә теле бар.

Гармунның да теле бар,

Янгынның да теле бар.

Телнең дә төрле төре бар.

Тагын кемнең теле бар? (Р.Миннуллин “Тел” )

Шигырьдә “тел” сүзе нинди мәгънәләрдә кулланылган?

*(Укучыларның җаваплары тыңлана)*

Укытучы:

- Ничек уйлыйсыз, безнең квестның “тел” төшенчәсенең кайсы мәгънәсенә багышланыр?

*(Укучыларның җаваплары тыңлана)*

Укытучы:

- Бик дөрес, бүгенге сыйныф сәгатенең исеме- “Туган илем – татар җире, туган телем – Тукай теле”. Ул һәркемнең өчен дә газиз, изге һәм кадерле булган туган тел темасына багышланыр.

Туган телем син – йөрәк җылысы,

Туган телем син – күңел тойгысы,

Туган телем син – тарих баскычы,

Туган телем син – белем ачкычы.

Белгәнегезчә, ТР Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов тарафыннан 2021 нче ел Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде. Дөньяда җиде меңгә якын тел бар. Татар теле – ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья халыкара аралашу теле дип саналган 14 телнең берсе. Бу – туган телебез белән горурланырлык мөһим фактор.

**IV. Төп өлеш. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

Укытучы:

Әйдәгез, дуслар, көч сынашыйк,

Кыюлар алга чыксын.

Һәрбер төркем зирәклеген,

Тапкырлыгын күрсәтсен!

Иң беренче, эшебезгә бәя бирүчеләр белән танышыйк. *(Жюри белән таныштыру)*

Квестны башлап җибәрәбез!

**1 бирем- конвертлардагы биремнәрне үтәү.**

Укытучы:

- Төркемнәргә кызыклы биремнәр белән тулы конвертлар ясалды. Төркемнән бер кеше конвертны сайлап ала. Биремне үтәү өчен сезгә 3 минут вакыт бирелә.

<u>1нче конверт- кроссворд чишәргә.</u>

Кроссворд сораулары һәи җаваплары:

1. Табышмакның җавабын табыгыз. (китап)

    Юк аягы, юк күзе,
    Сөйли, өйрәтә үзе.
    Телгә аннан оста юк,
    Аннан якын дус та юк.

2. Сүзләр тәрҗемәсе язылган китап. (сүзлек)
3. Татар халык мәкален язып бетер. Әдәп башы – (тел)
4. Татар теле нинди телләргә керә? (төрки)
5. Халыкара аралашу теле булып нинди тел санала? (инглиз)
6. Туган тел сүзенең антиномы- ... тел. (чит)
7.Күп телләр белгән кеше ничек дип атала? (полиглот)






<u>2 нче конверт- мәкальләрнең ахырын табарга.</u>

Иле барның- илләр гизгән.

Әдәп башы – үз хикмәте.

Телләр белгән- акылның баскычы.

Һәр телнең тел.

Тел-белемнең ачкычы- теле бар.

Дөрес җавап:

Иле барның-(теле бар)

Әдәп башы – (тел)

Телләр белгән - ( илләр гизгән)

Һәр телнең (үз хикмәте)

Тел-белемнең ачкычы - (акылның баскычы)

<u>3 нче конверт- шигырьнең татарча вариантын язарга.</u>

Родной язык - святой язык, отца и матери язык,
Как ты прекрасен! Целый мир в твоем богатстве я постиг!

Качая колыбель, тебя мне в песне открывала мать,
А сказки бабушки потом я научился понимать.

Дөрес җавап:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

<u>4 нче конверт- канатлы фразаның җөмләләрен дөрес итеп урнаштырырга.</u>

Тел – кешеләрнең аралашуы өчен бик әһәмиятле чара. Тел, тел дибез, нәрсә соң ул тел? Ул кеше тормышында гаять зур урын тота. Тел кешеләргә бер-берсе белән аралашырга, бер-берсен аңларга, бер-берсенең теләк-максатларын, уй-фикерләрен белергә ярдәм итә. Ул тормыш чыганагы, белем чишмәсе.

Дөрес җавап:

Тел, тел дибез, нәрсә соң ул тел? Тел – кешеләрнең аралашуы өчен бик әһәмиятле чара. Ул кеше тормышында гаять зур урын тота. Ул тормыш чыганагы, белем чишмәсе. Тел кешеләргә бер-берсе белән аралашырга, бер-берсен аңларга, бер-берсенең теләк-максатларын, уй-фикерләрен белергә ярдәм итә.

*(Һәр төркемнең эше тикшерелә)*

**2 бирем- видеоязма белән танышу һәм “Түбәтәй” уенын уйнау.**

Укытучы:

- Хәзер игътибарны экранга юнәлтик, кичәбезне “Татар галәме: тарих, тел, шәхесләр, милли горурлык” исемле видеоролик белән дәвам итәрбез. (https://ok.ru/video/236258751 )

Игътибар белән карагыз, соңыннан фильмның эчтәлеге буенча биремнәр эшләрбез.

*(Түбәтәй уены. Музыка астында укучылар түбәтәйне кулдан-кулга йөртәләр. Түбәтәй эчендә видеоролик буенча сораулар язылган карточкалар ята. Музыка туктагач, түбәтәй кемнең кулында кала, шул укучы бер карточканы ала һәм сораууга җавап бирә.)*

Сораулар:

Күпме кеше өчен татар теле туган тел булып тора?

Татар телен белү кешегә нәрсә бирә?

Кайсы өлкәләрдә татар теле киң таралган?

Россиядә сан ягыннан ничәнче урында торабыз?

Татар телен белү нинди өстенлекләр бирә?

Сез безнең шәһәрдә (республикада) кайсы халыклар сөйләмен ишетәсез?

Сөйләмегездә башка тел сүзләре кулланасызмы? һ.б.

**3 бирем- “Биш эшләпә” уены**

Укытучы:

Әткәй, әнкәй, я, апай, бабушка, дедушка һәм песи,
Безнең дома без җидәү: безнең кошка җиденчесе.
Вместе ашый, чәй пьет, безнең лә вместе спит ул.
Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан охраняет ул.

- Бүгенге көндә менә шулай телне бозып, берничә телне катыштырып сөйләүчеләр күп. Шагыйрь Дәрдемәнднең шул мәсьәләгә үз фикерен белдергән шигыре дә бар:

*Кил, өйрән, и туган бер башка телне*
*Бүтән телләр белү яхшы һөнәрдер.*
*Катыштырма вә ләкин телгә телне*
*Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.*

Бу шигырь өстендә без “Биш эшләпә” уены буенча эшләрбез.

1 төркем ак эшләпә – шигырь нәрсә турында? соравына җавап әзерли.

 2 төркем сары эшләпә – шигырьдә нинди уңай күренеш турында язылган? соравына җавап әзерли.

3 төркем кара эшләпә – шигырьдә нинди тискәре күренеш турында язылган? соравына җавап әзерли.

 4 төркем кызыл эшләпә – шигырьне укыгач нинди хисләр туды? соравына җавап әзерли.

 5 төркем (тамашачылар) зәңгәр эшләпә – автор белән килешәсезме? Сез нинди киңәшләр бирер идегез? соравына җавап әзерли.

*(Төркемнәрнең җаваплары тыңлана)*

**4 бирем- "Placemat Consensus" структурасы**

Укытучы:

Асыл сүзләреңне, туган телем,
Биреп торчы миңа аз гына.
Бөтенләйгә түгел - вакытлыча,
Тик җитәрлек гомер азагыма.
Синнән алган һәрбер сүземне мин
Күз карасы кебек саклар идем.
Ул сүзләрнең затлыларын сайлап,
Дога итеп кенә ятлар идем.
Ул сүзләрне җырга әйләндергәч,
Мин кайтарып сиңа бирәчәкмен.
Исраф булмас ул сүзләрең миндә,
Җыры булыр алар киләчәкнең.
Әйтә алмыйм әле - ул сүзләрдән
Аз булса да дөнья үзгәрерме?
Тик югалтмам, туган телем, синнән
Алып торган асыл сүзләремне, - дип язган Роберт Миңнуллин “Туган телемә” исемле шигырендә.

Гомумән, күпчелек шагыйрьләрнең иҗатында кызыл җеп булып туган телне, гореф-гадәтләрне саклау проблемасы бара. Авторлар бүгенге җәмгыятьтә бик актуаль булган татар милләтенең язмышы турында сөйли, аның киләчәген кайгырта. Хәзер без дә бергәләшеп туган телне саклау һәм үстерү юллары турында баш ватып алыйк. Тактада "Placemat Consensus" структурасы эленгән. Һәр төркем чиратлашып “Туган телне ничек сакларга һәм үстерергә?” дигән сорауга җавап эзли һәм әзер фикерне схемага яза.

*(Укучыларга төркемнәрдә фикер алышу өчен 5 минут вакыт бирелә)*




Балаларның көтелгән җаваплары:

1."Күбрәк татарча укырга, файдалы тапшыруларны карарга".
2." Туган телне яклап законнар кабул итү".
3."Гаиләдә балалар белән туган телдә сөйләшү "
4."Мәктәптә татар телен тырышып укырга".
5."Күбрәк татар телендә аралашырга" һ.б.

*(Һәр төркемнән берәр укучы чыгыш ясый)*

**V. Рефлексия. Йомгаклау.**

Укытучы:

- Әйе, сезнең җавапларыгыз белән килешәбез. Туган телне саклап калу өчен нинди ысул яхшырак икәнлеген һәркем мөстәкыйль хәл итә. Үз-үзен хөрмәт итүче һәр кеше туган телендә аралашырга, укырга, тел белән кызыксынырга тиеш. Ә схеманың уртасына төп фикерне язасым килә. Иң мөһиме- туган телне чын күңелдән яратырга кирәк.

*(Укытучы төп фикерне структураның урта өлешенә яза)*

Укытучы:

- Үз туган телебезне, илебезне яратып яшик, чөнки аның киләчәге – безнең кулда. Туган телебез горурланырлык булсын өчен, кулдан килгән кадәр тырышсак иде.

Ә хәзер нәтиҗәләр ясау өчен сүзне жюри әгъзаларына бирәбез.

*(Нәтиҗәләр ясала, җиңүчеләр игълан ителә. Төркемнәрне котлау оештырыла.)*

Чәчәк кебек матур бит ул туган тел,
Гөлләр-гөлләмәләр бизәп торган тел.
Назлыйсың да, иркәлисең җанымны,
Ничек итеп күтәрмисең даныңны?
Сагыш-моңым таратучы назлы тел,
Иң газизе, бу дөньяда азмы тел?!
Сине зурлап күпме җырлар җырланган,

Иң мөкатдәс шигъри юллар юлланган.
Рухи яктан үстерүче - туган тел,
һәр милләтнең бердәнбере булган тел.
Татар барда яшәр әле минем тел!
Ышана бит, инана бит күңел гел. (Рәзинә Мөхияр “Яшәр әле телем”)

Кадерле укучылар, туган телебезнең сафлыгын, матурлыгын саклагыз дигән изге теләкләр белән сыйныф сәгатен тәмамлыйбыз! Сау булыгыз!

*Төзүче: Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 33 нче гимназиянең югары квалификация категорияле туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучысы Шакирова Рәсүлә Габделвәли кызы*

**Тема: “Вәгъдә – күңелнең иманы”.**

**Максат:** 1. Сүздә тору, вәгъдәне үтәү кешене кешелекле иткән гүзәл сыйфатларның берсе икәнлеген укучыларга төшендерү.

2.Укучыларда мәрхәмәтлелек, бер-береңә ихтирамлылык хисләре, сүзеңдә тора белү сыйфатлары тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Презентация.

**Эшне оештыру төрләре:** Командада, индивидуаль, парлап.

**Кулланылган әдәбият:** Фәнис Яруллин “Кыядагы ояда” әкияте.

**Катнашучылар: 8 нче сыйныф укучылары.**

## Сыйныф сәгатенең барышы

- Менә тагын яңа көн туды. Яңа көн туугa бу җирдә яшәүгә омтылышыбыз, теләгебез арта. Яңа көн туугa үзебезнең газиз җиребездә бик бәхетле була алуыбызга тагын бер кат ышанабыз, сөенәбез. Әнә шундый омтылышлар, изге теләкләр, шатлык-сөенечләр белән бүгенге сыйныф сәгатебезне башлыйбыз. Әйдәгез, хәзер бер-берегезгә карап елмаегыз әле.

- Укучылар, без бүген сезнең белән тормышта кирәк була торган әхлакый сыйфатларның берсе турында сөйләшербез. Ф.Яруллинның “Кыядагы ояда” әкиятенең эчтәлеге белән танышып чыгыгыз әле**.**

*(Өстәлдә пазллар рәвешендә мәкальләр бирелгән.Төркемнәрдә эшләү. Билгеле вакыт эчендә мәкальләрне җыярга.*

- *Кулыңнан килмәгәнгә, телең белән сүз бирмә!*
- *Вәгъдәсен ашыкмый биргән кеше вәгъдәсендә торучан була.*
- *Вәгъдә – намус көзгесе.*
- *Әйткән сүз – каккан кадак.*

*1-2 укучыдан укыту. Мәкальләр слайдта күрсәтелә).*

- Укучылар, бу мәкальләрне нинди тема берләштерә? *(Җавапларны тыңлау).*

- Бу мәкальләр белән Ф.Яруллинның "Кыядагы ояда" әкияте арасында нинди уртаклык бар? *(Җавапларны тыңлау).*

- Димәк, без бүген сыйныф сәгатендә нинди тема буенча сөйләшербез? *(Җавапларны тыңлау. Тема слайдта бирелә. Сыйныф сәгатенең максаты белән бурычларын билгеләү).*

- Сыйныф сәгатендә сүздә тора белү проблемасының бүгенге көндә дә әһәмиятле булуын дәлилләрбез.

- Сүздә торуны сез икенче төрле ничек аңлыйсыз? *(Җавапларны тыңлау). (Сүзлек эше слайдта бирелә).*

**Вәгъдә** — 1. Берәр нәрсә эшләргә, башкарырга дип үз ризалыгың белән алган йөкләмә 2. Ант 3. Үзара килешү, алдан сүз беркетү.

*(Ф.Яруллинның "Кыядагы ояда" әкияте буенча эш. Сорауларга җавап бирү. Төркемнәрдә эшләү).*

1. Елан нинди вәгъдә бирә?
2. Еланның шарты нинди?
3. Бөркетләр сүзләрендә торалармы?
4. Еланның соңгы сүзләре нидән гыйбарәт?

*(Төркемнәрдә эш. Рәсемнәрне әкият эчтәлеге буенча тиешле тәртипкә куеп, әкиятнең кыскача эчтәлеген сөйләп чыгу).*

- "Үзегездән үзегез кача алмассыз, намусыгыз сезне һәрвакыт эзәрлекләп йөрер" дигән җөмләнең мәгънәсен аңлатып карагыз. *(Җавапларны тыңлау).*

- "Вәгъдәне бирү җиңел, ләкин үтәве авыр" дигән җөмләне сез ничек аңлыйсыз? (*Җавапларны тыңлау).*

- Сүздә тору нинди кешеләргә хас сыйфат?

- Үзеңдә шул сыйфатны тәрбияләү өчен нәрсә эшләргә кирәк?

**Күтелгән җавап тактага языла:**

1. Вәгъдә бирү алдыннан ныклап уйла.
2. Шартны белергә кирәк.
3. Вәгъдәне үти алмаган очракта сәбәбен аңлат, гафу үтен.

- Сүзендә тормаган кешеләрне икенче төрле ничек атыйлар? Тормыштан мисаллар китерә аласызмы? *(Җавапларны тыңлау).*

- Бүгенге сыйныф сәгатендә нәрсә турында сөйләштек?

- Вәгъдә бирү турында сыйныф сәгатенә кадәр нәрсә беләиден, сыйныф сәгатеннән соң нәрсә белдең? *(Җавапларны тыңлау).*

- Без биргән вәгъдәбезне үтәргә, кешелекле , иманлы булып калырга тиеш. Тормышта үз кыйблаңны табып, дөрес яшәргә кирәк. Сыйныф сәгатебез тәмам, катнашуыгыз өчен рәхмәт.

*Төзүче: Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 33 нче гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мисалова Гөлия Наил кызы*

**Тема: Халыклар дуслыгын ныгытуда, татар телен үстерүдә татар блогерларының роле.**

**Максат:** Татар телен, миллилекне саклау һәм үстерү теләге уяту, блогер төшенчәсен аңлату, блогерларның эшчәнлеген анализлап, алар эшчәнлеген чагыштырырга өйрәнү, уңай һәм тискәре якларын аеру күнекмәләре булдыру;

**Җиһазлау:** Компьютер, проектор, интерактив такта, презентация, видеоязмалар.

## Сыйныф сәгате барышы

### I. Укучыларда уңай халәт тудыру

**Укытучы:** Исәнмесез, укучылар!

**Укучылар:** Исәнмесез!

**Укытучы:** Кәефләрегез ничек?

Укучылар, бүген мин сезнең белән рәхәтләнеп сөйләшергә дип килдем. Мин сезнең күзләрегездән күреп торам сез фикер алышырга яратасыз. Сез фикер алышырга яратасызмы? *(Укучыларның җавабы).*

**Укытучы:** Игътибар тактага. Карагыз! Уйлагыз! Без нәрсә турында сөйләшербез икән?

(*Тактага рәсемнең бер кисәге генә чыга, фикерләр тыңлана. Икенче кисәге дә ачыла, фикерләр өстәлә, өченче кисәге өстәлгәч, кабат фикерләр тыңлана*).

**Укытучы:** Бу рәсемдә без кемнәрне күрәбез? (татарлар, чувашлар, руслар, марилар, башкортлар).

**Укытучы:** Бу нинди бәйрәм? Сабантуй ул нинди бәйрәм?

Сабантуй ул – татар халкының борынгыдан килгән милли бәйрәме. Ә халык ул телдән башка булмый. Тел һәм халыкны аерып булмый.

**Укытучы:** Димәк, без нинди темага сөйләшербез? (Халыклар дуслыгы турында).

**Укытучы:** Безнең бүгенге сыйныф сәгатебез әңгәмә-дискуссия формасында узачак. Шуңа күрә үзегезнең фикерләрегезне курыкмыйча, ирекле белдерүегезне үтенәм. Фикерләрегезне + яки - тамгаларын күтәреп белдерә аласыз. + – килешү, - – килешмәү билгесе.

**Укытучы:** Без хәзер сезнең белән бер физик күнегү үтәрбез һәм фикерләшеп алырбыз.

**Күнегү: Аркага арка.**

Сезнең өстәлләрдә лалә чәчәкләре ята. Чәчәкләрне алыгыз. Торып басыгыз. Минем янга чыгыгыз әле. Кызыл чәчәк яшел чәчәк белән парлашыгыз.

Үз парыгызга арка белән борылып басыгыз әле. Һәм кызыл чәчәкләр яшел чәчәкләрне иртәгә бәйрәмгә чакырсын. *(Сөйләшеп алалар).* Ә хәзер бер-берегезгә йөз белән борылыгыз. Һәм шул ук очрашу турында бер-берегезнең күзләренә карап, кабат сөйләшегез. *(Сөйләшеп алалар).*

**Укытучы:** Сезгә ничек аралашу җиңелрәк булды? Аркага аркамы, күзгә күзме? *(Җаваплар тыңлана. Утыралар!)*

**Укытучы:** Әгәр кешенең үзен күрмәсәк, тагын информация белән ничек бүлешеп була?

**Укучылар:** Интернет ярдәмендә, телефон белән, социаль челтәрләрдә, хат язышып.

**Укытучы:** Ә бүгенге көндә кайсы аралашу төре актуаль? Тере аралашумы, яисә виртуаль аралашумы?

**Укучылар:** Виртуаль аралашу күбрәк кебек. Сез безнең белән килешәсезме?

**Укытучы:** Ә виртуаль аралашуда бүген кемнәр иң зур роль уйный?

**Укучылар:** Блогерлар.

**Укытучы:** Укучылар, безнең тема килеп чыкты.

Халыклар дуслыгы, телләрне үстерү, блогерлар. Бу өч тема арасында бәйлелек бармы?

**Укучылар:** Әйе. *(Фикерләр тыңлана)*

**Укытучы:** Ярый, рәхмәт. Укучылар, димәк, әңгәмәбез нинди темага булыр?

Укучылар, сез социаль челтәрләрдә дә актив битләр алып барасыздыр. Шуңа күрә бүген мин сезнең белән "Татар телен үстерүдә һәм халыклар дуслыгын ныгытуда татар блогерларының роле " дигән темага сөйләшергә телим.

**Укытучы:** Сезнең фикерегезчә, блогер кем ул?

Укучыларның җаваплары тыңлана:

**Укучы:** Блогер - ул, интернетта нәрсәдер язып, нәрсәдер сөйләп эшләүче кеше.

**Укучы:** Блогер – ул, социаль челтәрдә үзенең тормышын яктыртып килүче.

**Укучы:** Блогер – ул, журналист, телгә, җәмгыятькә, сәясәткә карата үз фикере булган кеше.

**Укытучы:** Аңлатмалы сүзлеккә күз салсак (*Слайдка чыгарыла*), блогер – ул Онлайн-көндәлек, "блог" алып баручы, анда һәрдаим яңа постлар язып торучы кеше.

**Укытучы:** Ә сез блогерларны беләсезме? Нинди татар блогерларын беләсез? *(Укучыларның җаваплары тыңлана).*

**Укытучы:** Татар блогерларына нинди сыйфатлар хас булырга тиеш?

**Укучы:** Татар блогерлары татар телендә язарга тиеш.

**Укучы:** Әдәби телдә язарга тиеш.

**Укытучы:** Үзегезнең фикерегезне + - тамгалары белән белдерегез әле. Татар блогерлары бары татар телендә генә язып, татар халкының гына яшәешен күрсәтергә тиеш. Килешәсезме? *Фикер* + -

- Ә бәлки телебезне үстерү өчен рус телле сүзләрне кертеп сөйләшү ярыйдыр. Чөнки инстадуслар арта, караучылар арта. *Фикер* + -

- Бәлки кылану кирәктер, бу татар теленә йогынты ясый аламы? *Фикер* + -

**Укытучы:** Менә күптән түгел Инстаграмда “Татароязычный блог года” дигән конкурс булды. *(Интерактив тактада инстаграм битеннән фотосурәт куела).* Монда иң нык популярлык казанган 6 блогер чыкты. Сез санап үткән блогерлар алар арасында бармы? Әйдәгез, карыйк әле. Кемнәрне әйтмәдегез икән? *(Укучылар үзләре әйтмәгән исемнәрне ачыклыйлар).* Менә алар: “Татар малай”, “Кызык мызык”, “Инстататарки”, “Разиль Борчак”, “Гөлназ Сафарова”, “Дневник татарина”. *(Укытучы нәтиҗә чыгара)*

**Укытучы:** Укучылар, сез бик күп блогерларны беләсез икән. Әйдәгез, “Татар телле блог алып баручы” конкурсында җиңү яулаган блогерның язмасын карап китик, аннары сөйләшүне дәвам итәрбез.

*(Видеоязма 1. “Татар малай” карала).*

**Укытучы:** Бу блогер сезгә танышмы?

Аны татар телле блогер дип атап буламы?

Бу видеоязмада ул нинди проблема турында сөйләде?

Ничек уйлыйсыз бу блогер татар телен үстерүгә йогынты ясый аламы?

*(Укучыларның фикерләре тыңлана, нәтиҗә чыгарыла).*

**Нәтиҗә:** Сез аның белән килешәсезме?

**Укытучы:** Хәзер сезнең игътибарыгызга тагын бер видеоязма тәкъдим итәм. Бу кем? (*Җырчы, Гүзәл Уразова*) Сезгә танышмы? Җырчыларны блогерлар дип атап буламы? Ул нинди юнәлештә эшли? Татар җырлары аша халыкларны берләштереп буламы? Телләрне үстерүгә йогынты ясый аламы?

*(Укучыларның фикерләре тыңлана).*

- Ә менә татар телен популярлаштыру максатыннан татар җырларын бозып җырларга ярыймы?

**Нәтиҗә:** Мин сезнең фикерләрне ишеттем Ләкин мин уйлыйм: без саф татар телебезне саклауга омтылырга тиешбез.

**Укытучы:** Экранга игътибар итик. (*Ләбиб Лерон*) Таныдыгызмы? Бу кем? Аның нинди шигырьләрен беләсез? Ул үзенең блогында тарихи битләр, фотолар, шигырьләр куя. Бу эше татар теленә, халыклар дуслыгына уңай йогынты ясыймы? *Фикер* + -

Мин сезнең белән очрашуга әзерләнгәндә Ләбиб Леронга мөрәҗәгать иттем. Ул сезгә махсус видео юллады. Аның фикерләрен тыңлап китик.

*(Ләбиб Лерон турында видеоязма карала).*

**Укытучы:** Укучылар, ә татар телле блогерлар Татарстанда гына яшиме?

**Укучылар:** Юк, татарлар чит илләрдә, чит төбәкләрдә дә яшиләр. Алар чит төбәкләрдә дә бар.

**Укытучы:** Ә чит илдә яшәп, татарча язучы берәр блогерны атый аласызмы? *(Укучылар җавап бирә).*

**Укытучы:** Әйдәгез, видеоязма карап китик. *(Видеоязма карала).*

Бу кем, таныдыгызмы? Бу - хәзер Канадада яшәп тә, татар телен үстерүгә зур өлеш кертүче кыз - Алимә Сәләхетдинова. Аның @alima.academy дигән онлайн татар мәктәбе дә бар. Ничек уйлыйсыз, чит илдә яшәп телне үстереп, халыклар дуслыгын ныгытып буламы? *(Укучыларның фикерләре тыңлана. )*

Димәк, кайда яшәүгә карамастан телне үстерүгә, халыклар дуслыгына виртуаль аралашу йогынты ясый ала. Килешәсезме? *Фикер +- Нәтиҗә чыгарыла.*

Димәк, безнең кайда яшәвебез виртуаль аралашуда мөһим роль уйнамый.

**Укытучы:** *(Слайдлар күрсәтелә).* Укучылар, Мәскәүдә Татар яшь блогерлар форумы узган. Шулай ук Татарстанда да популяр блогерлар һәм тик-токерлар очрашуы булган. Очрашу кысаларында популяр Instagram-блогерлар һәм тик-токерлар Интернетта татар телен үстерү юлларын тәкъдим иткәннәр.

**Укытучы:** Укучылар, 2021 нче елны безнең Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнеханов "Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы"- дип игълан итте. Ничек уйлыйсыз, блогерлар 2021 нче елда телне үстерү, милләтебезне саклау буенча эшне активлаштырырмы? Аларның саны артыр дип уйлыйсызмы? *(Укучыларның фикере тыңлана).*

**Укытучы:** Укучылар, без бүген төрле юнәлештәге блогерларны карап киттек: шагыйрь, җырчы, онлайн татар мәктәбен ачучы, гади кеше.

Әйдәгез әле, үзегезне популяр татар телле блогер дип күз алдына китерегез. Татар телен үстерү, татар халкын берләштерү максатыннан нәрсәләр эшләр идегез? Лалә чәчәкләренә язып куегыз әле. *(Үз фикерләрен язалар).*

Ә хәзер әлеге чәчәкләр белән түгәрәккә басыйк. Фикерләрне укый барабыз. Үзегезнең татар телле, милли рухлы блогыгызга нәрсәләр язар идегез? Нинди юнәлештә эшләр идегез? *(Укучылар үзләренең фикерләрен әйтәләр)*

**Укучылар:**

- татар музыкасы турында язарга,
- татар телендә сыйфатлы фильмнар һәм сериаллар төшерергә,
- яңа форматтагы күңел ачу тамашаларын чыгарырга.

**Укытучы:** "Халыкның теле аның рухи тормышы беркайчан да шиңми, мәңге яшәреп тора торган иң матур чәчәге" дип әйтә Константин Ушинский. Ә мин, укучылар, сезгә карата әйтергә телим. Телебезне саклагыз, башка милләт вәкилләренә хөрмәт белән карагыз һәм киләчәктә милләтебезнең горурлыгы булыгыз!

*Төзүче: Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 33 нче гимназиянең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мисалова Гөлия Наил кызы*

**Тема. Юллар имин булыр бергәләп.**

**Максат**:

1. Балаларның юл йөрү кагыйдәләре, юл билгеләре турындагы белемнәрен уен формасында ныгыту һәм киңәйтү.
2. Дидактик уеннар, ситуатив мәсьәләләр аша балаларда игътибарлылык, тәрбияләү, уйлау сәләтләрен үстерү.
3. Юл йөрү кагыйдәләрен тагын да тирәнрәк өйрәнергә кызыксыну уяту. Балаларда ярдәмчеллек сыйфаты тәрбияләү.

**Бурычлар:**

1. Юл йөрү кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү.
2.Юлда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үтәгәндә җаваплылык хисләрен формалаштыруны дәвам итү.
3. Юл йөрү кагыйдәләре, юл билгеләре турында белемнәрне ныгыту.
4. Игътибарлык тәрбияләү.

**Кулланма материаллар:** юл билгеләре макетлары., проектор һ.б.

**Кереш өлеш.**

- Хәерле көн, укучылар!
- Исән-сау килеп җиттегезме?
- Мин дә исән-сау килеп җиттем?
- Уйлагыз әле, ерак юлга чыкканда кешеләр бер-берсенә нинди сүзләр әйтәләр?
- "Хәерле юл!" дип озатып калалар.
- Ә кайтып кергәндә ничек каршы алалар?
- "Исән-сау кайттыңмы?" дип каршы алалар.
- Укучылар, ничек уйлыйсыз, ни өчен?
- Чөнки юлда йөрү куркыныч.
- Ә ни өчен куркыныч соң юлда йөрү?
- Юл йөрү кагыйдәләре бар бит?
- Чөнки бөтен кеше дә ул кагыйдәләрне үтәп бетерми.
- Кызганыч, бөтен кеше дә бу кагыйдәләре үтәп бетерми, шул сәбәпле төрле күңелсез хәлләргә юлыгабыз.
- Димәк, без бүген нинди темага әңгәмә алып барырбыз икән?
- Бүген без "Юлда йөрү кагыйдәләре" дигән темага сөйләшү алып барырбыз.

**Төп өлеш.**

- Әйдәгез әле, бер видеоязма карап китик. Аннары әңгәмәбезне дәвам итәрбез. *(Видеоязма карыйлар)*

- Укучылар, нинди ялгышлыклар күрдегез?

- Дустына кызыл төстә юлны чыгарга чакырдылар.

- Ә дусты нишләде?

- Яшел төсне көтеп торды.
- Монда куркыныч ситуация күрдегезме?
- Юк, куркыныч хәл булмый калды.
- Ни өчен фаҗига булмый калды?
- Укучылар, сез дә көн саен юлга чыгасыз. Кайларга барасыз?
- Мәктәпкә, түгәрәкләргә.
- Юлда йөргәндә куркыныч урыннарны күрәсезме? Беләсезме?
- Әйе.
- Әйе, шуңа күрә әйдәгез бер эш эшләп алабыз.

Сезнең каршыгызда ак битләр ята. Анда зәңгәр төс белән схематик рәвештә мәктәп билгеләнгән, ә яшел төс белән өй. Ә кара төс белән - юл.

Бирем: кызыл фломастер алып, юлның кайсы урыннарында бик игътибарлы булырга кирәк, билгеләгез әле.

- Кайда игътибарлы булырга кирәк?
- Юл янында.
- Исән-имин барып җитәр өчен нишләргә кирәк?
- Юл йөрү кагыйдәләрен белергә кирәк.
- Укучылар, мин сезгә бер музыкаль күчтәнәч белән килдем. Рәхим итеп тыңлагыз! *(Светофор җырын тыңлыйлар)*
- Светофор нәрсә өчен кирәк?
- Тагын юл хәрәкәте иминлеге сагында кем тора?
- ЮХИДИ тора.

*(Укытучы инспектор булып киенә).*

- Таныш булыйк! Мин ЮХИДИ хезмәткәре Мисалова Гөлия Наил кызы. Юл йөрү кагыйдәләре беләсезме?
- Әйе.
- Я, тикшереп карыйк әле.

**“Сорау миннән, җавап сездән.”**

- Җәяү йөрүче кем дип атала? (җәяүле)
- Светофорның ничә төсе бар? (3)
- Машина юлы аша ничек чыгарга? ( зебра аша, .....)
- Җәяүлеләр өчен яшел ут янса, машиналар өчен тинди төс янар?( кызыл)
- Җәяүле юлы.( тротуар)
- Зебра ничә төсле? (2)

- Трамвай кайдан йөри? ( рельстан)

Соңгы елларда республикабызда һәм шәһәребездә автотранспорт саны, юлларда машина хәрәкәте бик нык артты. Шуның нәтиҗәсендә балаларның юл-транспорт һәләкәтенә юлыгу куркынычы да көчәя. Күп кенә очракта бу куркыныч һәләкәткә балалар үзләре сәбәпче була. Мин бүген сезне куркынычсызлык формуласы белән таныштырырга телим.

Бу - **куркынычсызлык формуласы**!

Игътибар экранга:

1. Тукта! (Остановись!)
2. Уйла! (Подумай!)
3. Эшлә! (Действуй!)
4. Үзеңне макта. (Похвали себя)

*(Һәр укучыга формулалар язылган карточкалар өләшенә).*

Әйдәгез, шушы формуланы кулланып, бер ситуацияне чишеп карыйк әле. Игътибар экрана.

- Нәрсә дөрес түгел?

**“Юл йөрү кагыйдәләре буенча мәсьәләләр чишү”.**

**“Юл билеләрен таны” уены**

Сезнең алдыгызда зәңгәр тасмалар ята. Алып укыгыз. Туры килгән юл билгеләрен табып басыгыз.

**Җәяүле чыгу урыны.**

**Җир асты юлы.**

**Велосипед юлы.**

**Тукталыш.**

**Ерак түгел ашыгыч ярдәм, яки шифаханә.**

**Тайгак юл.**

**Велосипед йөрү тыела.**

**Велосипед юлы.**

**Машина юлы.**

**Җәяүлеләргә йөрү тыела.**

**Балалар.**

Ә хәзер әйдәгез, искә төшереп китик. Чираттан укый барабыз, юл билгесен күрсәтә барабыз. *(Укучылар юл билгеләрен тотып тезелеп басалар)*

Укучылар бу юл йөрү билгеләрен белү - бик мөһим.

**Флешмоб**

Ә хәзер, укучылар, **“Дөрес”, “дөрес түгел”** дигән уен уйнап алабыз. Дөрес булса “дөрес” дип бер адым алга атлыйсыз, дөрес булмаса “дөрес түгел” дип туктап торасыз. (*Инспектор дөрес булмаса свисток сызгырта*)

1. Мәктәпкә соңга калсаң, юлны йөгереп чыгарга ярый. (-)
2. Тротуардан йөргәндә, уң яктан барырга кирәк. (+)
3. Светофорның сары утына туктап торырга кирәк. (+)
4. Юл кырындагы тротуарда туп белән уйнарга ярый. (-)
5. Әгәр дә светофорның кызыл уты янса, ә машина ерак булса чыгарга ярый.(-)
6. Һәрбер кешегә юл йөрү кагыйдәләрен белергә кирәк. (+)

**Проект эшләү.**

Яхшы, укучылар! Ә хәзер формула язылган битләрне алыгыз әле. Һәм өйдән мәктәпкә бару өчен ясалган схеманы шунда ябыштырып куегыз. Өйдә әти-әниләрегез белән кабат юлның схемасын карап чыгарсыз. Мин сезгә менә шундый фликерлар таратам. Бигрәк тә кич белән урамнан кайтканда бу әйбер сезнең өс киемегездә булырга тиеш. Нәрсә өчен кирәк икәнен беләсезме фликерларның?

**Йомгаклау.**

- Димәк, укучылар юл йөрү кагыйдәләрен белү нәрсә өчен кирәк?
- Безнең иминлегебез – юлда үзебезне ничек тотуыбызга бәйле.

Кадерле укучылар, мин сезнең юлларда исән-имин йөрүегезне теләп калам. Рәхмәт сезгә!

*Төзүче: Казан шәһәре Совет районы 11нче татар гимназиясенең югары квалификация категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы, 9 нчы сыйныф җитәкчесе Хафизова Зөләйха Муса кызы*

**Тема: Иҗат ул- тылсым**

**Максат:** 1) Туган телдә иҗат итү сәләтләрен, төрле жанрда язу күнекмәләре үстерү. Шигырь төзелеше, шигырь төрләре турындагы белемнәрне камилләштерү. Интервью жанры турында алган белемнәрне гамәлдә куллану күнекмәләрен ныгыту. 2) Төрле һөнәрләр турында мәгълүмат бирү, һөнәр сайлауга әзерлек. 3) Сәләтле укучыларның үзара тәҗрибә уртаклашуларын, иҗади мөмкинлекләрен үстерү. 4) Күренекле шәхесләр белән таныштыру, аралашу осталыгын арттыру.

**Класс җитәкчесе:** Бу класс сәгате **“Әдәби кунакханә”** формасында уза.. Укучылар, Сез бүген мөхәррир, җаваплы сәркатип, журналист, шагыйрь, диктор ролендә булырсыз, иҗат итәрсез, әңгәмә корырсыз, интервью алырсыз. Шулай итеп үзегезне булачак һөнәр сайларга да әзерләрсез. Өстәлләргә күрсәтмә карталар куелган, теләгән юнәлешне сайлап алыгыз. Ялгышсагыз, дөрес җавапны тапмасагыз, ярдәм итәр, киңәш бирер кешеләребез янәшәдә. Кунакларыбыз – шагыйрә Йолдыз Шәрәпова һәм КФУның татар журналистикасы кафедрасы

доценты, филология фәннәре кандидаты Зәйни Резидә Локмановна. Бүгенге класс сәгате сезгә рухи күтәрелеш, иҗади омтылыш китерсен.

Укучылар төркемнәргә бүленеп утыра. **1. Интервью турынданиләр белдегез?** Интервью жанры хакында белгәннәрне искә төшерәләр, төркемнәрдә киңәшәләр, бер укучы фикерләрне берләштереп, нәтиҗә ясый. Җаваплар тыңлана.

1. Интервью алып аерым фактлар, күренешләр һәм проблемаларга кагылышлы төрле фикерләрне белергә мөмкин.
2. "Интервью - матбугат хәбәрчесенең берәр атаклы кеше белән гомуми кызыксыну тудыра торган берәр темага матбугатта игълан итү өчен махсус әңгәмәсе", диелгән "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә.
3. Интервью (инглизчәдән тәрҗемә иткәндә "әңгәмә") - матбугатта бастыру яисә радио, телевидение аша тапшыру өчен журналист тарафыннан бер, я булмаса берничә кеше белән үткәрелгән әңгәмә.
4. "Интервью" термины үзе ике төрле мәгънәгә ия. Беренчедән, ул жанр төшенчәсен аңлатса, икенчедән, төрле кешеләр белән әңгәмә корып, мәгълүматлар туплау дигән сүз.
5. Интервью-материал язу өчен мәгълүмат туплауның бер чарасы. Газетаның барлык жанрларында иҗат иткәндә дә журналист үзе яктырта торган вакыйгага күпмедер катнашы булган бер яисә берничә кеше белән әңгәмә (ягъни, интервью) үткәрә.

**Класс җитәкчесе: Интервью жанрында иҗат итүче журналист билгеле бер кагыйдәләр кысасында эш итәргә тиеш. Алар нинди ләр?**

Укучылар төркемнәрдә киңәшә. Җаваплар тыңлана.

1.Интервьюның башламы җанлы булсын. Мавыктыргыч башлам куллану текстның тәэсир көчен арттыра.
2.Яктыртыласы тема нинди дә булса яңалык хәбәр итсен;
3.Язмада исемнәр, саннар төгәл әйтелсен;
4.Язачак тема нәрсәгәдер өйрәтсен һәм шулай ук уйландырсын;
5.Исеме үзенә җәлеп итсен. Баш исем газета укучыны шунда ук кызыксындырырлык, җәлеп итәрлек булырга тиеш.

**Класс җитәкчесе: сезнең фикерегезчә, интервью алганда иң мөһиме дип тагын нәрсәне саныйсыз?**

Интервьюда кешегә мөрәҗәгать итү мөһим урынны алып тора. Аралашу бит эндәшүдән башлана. Без төрле кешегә төрлечә эндәшәбез: җитәкче кешегә, укытучыларга бертөрле, олы яшьтәге абый-апаларга икенче төрле. Гаилә, туганнарга шулай ук башкача. Дуслар, сыйныфташлар белән үзебезчә гадирәк аралашабыз. Кешегә эндәшү чарасы буларак, шәхеснең исеме зур урын тота.

**Класс җитәкчесе:** алдагы класс сәгатендә иҗади бирем итеп, “Әнием, минем яшьтә син нинди идең?” дигән темага әниләрегездән интервью алырга кушылган иде. Бу биремне үтәгәндә, кыенлыклар тумадымы?

**Ришат:** Минем проблема килеп чыкты. Әйдәгез, дуслар, миңа киңәш бирегез әле. Минем әни тәрбияче булып эшли, эштән бик арып кайта. Бер көнне әнидән интервью алмакчы идем: “Улым башымны катырма, садикка обрнадзор килә, документлар әзерлим,” - диде. Мин берничә көн көттем дә, тагын әнигә сораулар бирә башладым. “Улым, садикка санэпидстанция килә, син дә ичмаса аптыратма!” – дип мине ачуланды. Мәктәпкә килгәч, Зөләйха Мусиновна ачуланды. Нишләргә инде миңа?

**Класс җитәкчесе:** Әйдәгез, Ришатка киңәшләрегезне бирегез! Җаваплар тыңлана.

- Үзең гаепле, Ришат. Унай психологик климат булдырырга кирәк иде. Мәсәлән, әниең кайтышка өйне җыештырырга, ашарга пешерергә.

- Күбрәк яхшы билгеләр алып, башта әниеңә көндәлегеңне күрсәтергә иде.

**Класс җитәкчесе:** Әйе, әңгәмә үткәрүнең бик күп кагыйдәләре бар. Интервью алу өчен уңайлы вакыт сайлау, әңгәмәдәшкә дөрес итеп мөрәҗәгать итү, психологик әзерлек, сөйләм иясенең холкын белеп эш итү, кеше белән итәгатьле аралашу - болар барысы да һәр журналист өчен бик тә әһәмиятле булган сыйфатлар.

**Укучылар, журналистка өлкәсендәге һөнәр сайлау өчен,үзеңдә нинди сыйфатлар булдырырга кирәк дип уйлыйсыз? Җаваплар тыңлана.**

1. Кызыксынучан, таләпчән, күзаллавы киң, тырыш.
2. Матур булырга тиеш. Аралашу күңелле була.
3. Оперативлык хас. Кыска вакыт эчендә кызыклы язма иҗат итәргә тиеш.
4. Максатчан, белемгә омтылучан.
5. Юмор хисе.
6. Ишектән кереп булмаса, тәрәзәдән керә.
7. Тиз аралашу, уртак тел табу мөһим.

Профессиональ журналистлар әзерләүче КФУның татар журналистикасы кафедрасы доценты Резидә Локмановна сезне игътибар белән күзәтеп бара. Аны тыңлыйк әле. “Аз сүзле, табигате буенча йомык кешеләр белән уртак тел табарга, аны кызыксындырган сорауларга җавап алырга тырышырга кирәк. Моның өчен яхшы психолог һәм филолог булырга кирәк. Әгәр әңгәмәдәш куелган сорауга тулы җавап бирү урынына "әйе" яки "юк" дип җавап бирә икән, шунда ук "ни өчен" дип сорарга кирәк. Журналист әңгәмәдәш белән ике арадагы психологик киртәләрне җимерергә, үзара җылы мөнәсәбәт булдырырга тиеш. Психологик киртәләр булмаса, интервью да уңышлы була. Шуңа күрә, әңгәмәгә психологик

әзерлек бик мөһим. Психологик әзерлек - бирелгән шартларда үзеңнең сәләтеңне яхшырак куллану сәләте формалаштыру ул.”

Йолдыз Шәрәповага сорау: “Интервью алу өчен, нинди сыйфатларга ия булырга кирәк?”

- Яхшы хәтер, игътибарлылык, күзәтүчәнлек, күзаллау, сизгерлек, җыелганлык, психологик ныклык, аралашучан булу, тапкырлык, тиз реакция, ихтыяр көче, кызыксынучанлык

**Класс җитәкчесе: Әйдәгез, алган белемнәрне гамәлдә кулланып карыйк.** Төркемнәрдә киңәшегез дә, берничә журналистны интервью алырга җибәрегез. Профессиональ журналистлар әзерләүче КФУның татар журналистикасы кафедрасы доценты Резидә Локмановна сезне игътибар белән күзәтеп, фикер-тәкъдимнәрен җиткерер. Укучылар кунакларга сораулар бирә.

**Кәрим:**

1. Без гаиләдә 4 малай. Өчебез дә бу гимназиядә укыйбыз. Төпчек энем Искәндәргә - 4 яшь. Салават абый - 10нчы сыйныфта укый, мин - 6 нчы, энем Камил – 2 нче сыйныфта укый. Абыема мин – энекәш - аны тыңларга кирәк, 2 энемә мин абый - үрнәк күрсәтергә кирәк. Берүземә авыргарак туры килә, кайчак тәртип ягы да аксый, җитдилек җитеп бетми, шаярырыга яратам. Ә Сезгә нинди укучылар ошый? Сезнең мәктәптә нинди укучылар укый?

2. **Айрат:** Мин 2005 елда туганмын. Исемемне депутат Айрат Хәйруллин хөрмәтенә куйганнар. Дәрәҗәле, уңышка ирешүчән булсын дип теләгәннәр. Сез үз исемегезнең тарихын беләсезме? Гомумән, исем кеше тормышында мөһим урын алып торамы? Әллә кеше үзенең эш-гамәлләре белән исемен бизиме?

3. **Камилә:** Мин “5” легә генә укыйм. Әле бер “2” билгесе дә алганым юк, шуңадырмы “2”ледән бераз куркам да. Кәрим: “2”ле билгесе алмаган кеше чын укучы булмый”,- дип, минем белән бәхәсләшә. Безнең бит Бердәм дәүләт имтиханнары бирәсе бар. Шуңа күрәдер, бераз куркыта да. Ә Сез бу хакта ничек уйлыйсыз? Кунакларның җаваплары тыңлана.

**Класс җитәкчесе:** Бездә кунакта танылган шагыйрә Йолдыз Шәрәпова. Шигырь турында сөйләшми калу мөмкинме соң? Икенче сәхифә -”Ач, шигърият, серләреңне!” укучылар үзләре иҗат иткән шигырьләрне укыйлар, киңәш сорыйлар, шагыйрәнең осталык-классын тыңлыйлар.

**Кыям Миңлебаев**

Кыям абый Миңлебаев-
Автографы - “ Кыям Дәрвиш”.
Безнең туган бистәбезне
Китапларына керткән ич!
“Кала-авыл” диеп атаган
Безнең Дәрвишләр бистәсен.

Белгән бит ул бистәбезнең
Даны ерак китәсен.

**Әминә Бикчәнтәева**

Балаларның Дәү әнисе-
Әминә Бикчәнтәева.
Бистәбезнең Энтузиаст урамында
Яшәгән бит кем белә?
Балалар тәрбиясенә
Керткән бит ул зур өлеш.
Шагыйрәнең китапларын
Син дә укырга тырыш!!!!
Дәрвишем –туган ягым
Төз наратлар кочагына
Сыенган минем бистәм.
Горурлык хисе уяна
“Без – Дәрвишләрдән” дисәм.
Күп әдипләр өчен дә ул
Булган кадерле төбәк.
Зур талантлар яшәгәнен
Бирербез сезгә сөйләп.
Атилла Расих, Габдрахман Минский,
Җырчы-шагыйрь Хөсәен.
Дәрвишләрдән фатир алып,
Табалар яшәү ямен.

Йолдыз Шәрәпованың киңәшләре тыңлана.

**Класс җитәкчесе:** (Рефлексия) Укучылар, иҗади эшчәнлеккә карата синквейн аша үзегезнең хис-тойгыларыгызны, фикерләрегезне белдерегез. Иҗат ул .....

Сыйныф сәгатен йомгаклау.

*Төзүче: Казан шәһәре Совет районы 47 нче урта гомуми белем мәктәбенең беренче квалификация категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы Зарипова Хания Миңнегол кызы*

**Тема: Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк.**

**Максат, бурычлар:** 1.Данлы үткәнебез турында күзаллауны булдыру, җирдә тынычлыкта яшәүнең нинди зур көчкә ия булуын аңлату.

2. Укучыларны мөстәкыйль фикер йөртүгә өйрәтү аша, сугыш ветераннарына хөрмәт – ихтирам хисләре, кешелеклелек сыйфатлары, җаваплылык хисе тәрбияләү.
3. Батырлык турында фикералышу аша укучыларга патриотик тәрбия бирү; туган илгә мәхәббәт хисе тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең, кече сеңлесе Хәдичә Җәлилованың портретлары,укучыларның презентацияләре.

**Сыйныф сәгатенең эпиграфы:**

Исәннәрнең кадерен бел,
Үлгәннәрнең каберен бел.

**Сыйныф сәгатенең барышы**

I. Оештыру, исәнләшү.
II. Уку мәсьәләсен кую.
1 Укытучының кереш сүзе.

-Исәнмесез, хәерле көн, укучылар! Бүгенге класс сәгатебездә батырлык, кешелеклелек, нәсел төшенчәләре турында сөйләшербез. Яшәеш мәгънәсе нәрсә ул ?дигән сорауга җавап эзләрбез.

**Укытучы:** Минемчә,Туган илен, халкын, гаиләсен, туган-тумачасын яратмаган, нәселен белмәгән кеше батырлык эшләргә дә, игелеклек кылырга да көчсез кеше. Юкка гына халык:

Илен белмәгән – игелексез,
Халкын белмәгән – холыксыз,
Ә нәселен белмәгән – тарихсыз, -дип әйтмәгән.

Үз халкы, туган иле, нәселе белән горурланырга сәләтле кеше генә үлем белән күзгә-күз очрашканда шушы изге төшенчәләр хакына газиз гомереннән вас кичә, батырлык эшли ала.

- Нәрсә соң ул батырлык?

-Укучылар, сез”батырлык “ төшенчәсен ничек аңлыйсыз? (*Һәр укучының фикере тыңлана.)*

Ә татар теленең аңлатмалы сүзлегендә бу сүзгә менә ничек аңлатма бирелгән икән. (*Мәгънәсе укыла)*

1.Батыр – курыкмаучанлык, кыюлык, көчлелек, уңганлык сыйфатлары белән танылган шәхес.

2. Көрәштә барлык башка көрәшчеләрне җиңеп чыккан кеше,тәвәкәллек.

**Укытучы:** Әйе, мин сезнең фикерләрегез белән тулысынча килешәм. Сугыш вакытында, яу кырында гына түгел, көндәлек тыныч тормышта да батырлык күрсәткән бик күп шәхесләрне атарга булыр иде.

Хәзер, укучылар, дәһшәтле Бөек Ватан сугышы елларына әйләнеп кайтыйк.

Сугыш илебезгә бик күп күз яшьләре, күп газаплар, күп югалтулар китерде. Бәхетле киләчәкне якынайту өчен күпме кан коелды, күпме җан кыелды.

Татар каһарманы Советлар Союзы Герое Муса Җәлил һәм аның Каршылык төркемендәге куркусыз эшчәнлеге турында белмәгән кеше юк. Без барыбыз да аның белән горурланабыз!

1нче укучы сугышта геройларча һәлак булган Муса Җәлил һәм ун татар каһарманының батырлыклары турында сөйли. (*Презентация*)

**Укытучы:** Элек-электән татар халкы "нәсел"гыйбарәсенә зур игътибар биргән. Йортка килен төшергәндә, кызларын кияүгә биргәндә кияүнең, кәләшнең нинди нәселдән булуы бик мөһим роль уйнаган. Җәлиловлар нәселе...Кешелеклелек, тәвәкәллек, максатчанлык, саф күңеллелек хас бу горур нәселдән чыккан кешеләргә. Сүзебез герой-шагыйрь Муса Җәлилнең кече сеңлесе Хәдичә Мостафа кызы Җәлилова турында.

**2 нче укучы:** Муса белән Хәдичә арасында аерма унике яшь. Яшьли ятим калган сеңлесенә абыйсы гел ярдәм итәргә тырыша. Хәдичәне балалар йортына да ул урнаштыра.Әмма сеңлесенә анда ошамагач, студент Муса аны үз янына ала. Соңрак, еллар үткәч, Хәдичә Җәлилова "О моем брате"дигән кечкенә генә бер китап та яза. Ә үзе турында ул сөйләргә яратмый. Бигрәк тә сугышта үткән еллары хакында.(*Презентация*)

**3 нче укучы:** Хәдичә Җәлилова 1942 елның маенда үзе теләп сугышка китә. Горкий шәһәрендә элемтәчеләр әзерләү полкында укый.Укып бетергәч, аңа бу полкта укытучы булып калырга тәкъдим итәләр, ләкин ул кискен каршы килә.

**4 нче укучы:** Брянск фронт штабының 65 нче аерым элемтә полкына эләгә. Шифрланган радиограммалар штабка өзлексез килеп тора, шуның кадәр үк җибәрелә дә. Хәдичә Җәлилова авиация һәм танк частьлары белән элемтә тота.

**5 нче укучы**: 1943 нчы елның гыйнваре. Ул коточкыч көн мәңге хәтерендә кала. Бу көнне Хәдичә Җәлилованы Ефремово шәһәрендәге особый отделга алып килеп, ялгыз камерага кертеп ябалар.

**6 нчы укучы**: М.Җәлилнең "Хыял"шигыреннән бер куплет укый.

Таш диварлар алды шатлыгымны,
Биреп картлык, кайгы, ютәлне.
Ишегемә барсам, ишек бикле,
Тәрәзәмә килсәм –челтәрле.

**Укытучы:** Яраткан абыйсының бу вакытта аңардан да авыррак шартларда дошман кулында әсирлектә утыруын, төрмәдә газап чигүен Хәдичә шактый еллар узгач кына белә әле.

**7 нче укучы:** 58 нче статья буенча ун елга хөкем итәләр Хәдичә Җәлилованы. Иреккә чыгарга өч ай калгач,1952 нче елны гына аклана. Азат

ителгәннән соң лаеклы ялга чыккан көнгә кадәр Оренбургта мелиоратор булып эшли. Бу дөньядан вакытсыз киткән апасы Зәйнәпнең ятим калган кызын тәрбияләп үстерә.

**8 нче укучы:** Хәдичә Мостафа кызы Советлар Союзы Герое, яраткан абыйсы Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлеге турындагы истәлекләр белән бик күп чыгышлар ясый, гомеренең соңгы көннәренә кадәр милләтебез язмышы, аның киләчәге белән кызыксынып яши.

**Укытучы:** Шундый газаплар күреп тә, шундый кимсетүләр аша узып та кешелеклеген, кешеләргә ышанычын югалтмый; игелекле һәм якты күнелле чын кеше булып кала Хәдичә Җәлилова.

Укучылар, нәрсә соң ул кешелеклелек?

**9 нчы укучы**: Тормыш сине ничек кенә какмасын, сукмасын, нинди генә авырлыклар биреп сынамасын кешелек сыйфатларын югалтмаска, күңелдә миһербанлык, игелеклек хисләрен саклап калырга кирәк.

**Укытучы:** Хәдичә Җәлилова да бер гөнаһсыз ун елга якын гомерен төрмәдә үткәреп тә, кешелек сыйфатларын җуймаган, кешеләргә карата ярдәмчел, ачык һәм хөр күңелле чын кеше булып кала.

**Сыйныф сәгатен йомгаклау**.

Кадерле укучылар, мин сезнең акыллы, тәвәккәл, миһербанлы, кешеләргә карата игелекле булып үсүегезне телим.

Кыл яхшылык кешеләргә-
Кеше булыйм дисәң.
Авыр булыр, өсләреңә
Гөнаһ туны кисәң.
Кирәк булса коткарырга
Батып баручыны,
Кулың суз да коткар сагыш-
Моңга таручыны.
Кеше булып яшим дисәң,
Бул син кешелекле.
Бәхетле көн итим дисәң,
Бул син игелекле.

Сыйныф сәгатен Минтимер Шәймиев сүзләре белән тәмамлыйсым килә. “Батырлык ул – рухи матурлык... Әнә шуңа күрә дә халкыбыз кеше күңеленең рухи бөеклеген югары бәяләгән. Батырларның кылган изге гамәлләре, данлы исемнәре әкиятләргә күчкән, җырларга кергән. Шул олуг батырлык алдында безнең чор кешеләре генә түгел, киләсе гасырларда яшәүчеләр дә башларын иярләр әле....”

*Төзүче: Казан шәһәре Совет районы 159 нчы лицейның
югары квалификация категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы
Галимуллина Лилия Фәргат кызы*

**Тема: Туган телем-татар теле.**

**Максат:**

- туган телгә - ана телебезгә мәхәббәт тәрбияләү;
- телебезне сакларга һәм якларга кирәклеген төшендерү;
- тел байлыгын үстерү;
- туган телнең матурлыгын тоярга өйрәтү.

**Сыйныф сәгатенең барышы**

Укучыларны сыйныф сәгатенә оештыру.

Исәнмесез, укучылар.
Хәерле көннәр сезгә.
Зиһен һәм тел ачкычлары
Телимен һәммәгезгә.

-Укучылар, мин сезгә табышмак әйтәм, җавабын әйтеп карагыз әле?

Көйдергән дә ул,
Сөйдергән дә ул,
Иң ачы да ул,
Иң татлы да ул.
Ул нәрсә?

-Җавап: тел.

- Дөрес.

- Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшербез?

- Тел турында.

- Тел, туган телебез - татар теле турында сөйләшербез. Укучылар, Каюм Насыйри сүзләрен искә төшерик.

“Без татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул”, - дигән телебезне үстерүгә гаять зур өлеш керткән галимебез К.Насыйри. Туган тел! Һәркем өчен дә газиз сүз. Чөнки иң кадерле сүзләрне без туган телдә әйтәбез. Тел булмаса — хәтер, хәтер булмаса — тарих, тарих булмаса — халык юклыгын һәркем яхшы аңлый.

Укучылар, әйтегез әле, нәрсә ул тел?

- (*Орган, аралашу коралы, тел булмаса без сөйләшә алмас идек, билгеле бер халыкны да тел генә берләштерә*)

- Укучылар татар теленең аңлатмалы сүзлеге барыгызга да таныш. Анда һәрбер сүзгә төгәл аңлатма бирелгән. Тел сүзенең шушы аңлатмалы сүзлектә ничә мәгънәсе бар икән.?

- (*Укучылар аңлатмалы сүзлекләрдән тел сүзенең мәгънәсен эзләп табалар, танышалар, 13 мәгънәсен укыйлар*).

- Укучылар, безнең телебездә тел сүзе кергән фразеологик әйтелмәләр, тотрыклы гыйбарәләрне бик күп. Күбесен без сезнең белән аларның көндәлек сөйләмебездә дә кулланабыз. Әйдәгез, шул тотрыклы гыйбарәләрне искә төшерик.

- ( *Тел ачкычы, тел ачу, тел ачылу, тел бару, тел бәйләнү, тел шартлату, тел көрмәкләнү, тел очында, тел тидерү, теле телгә йокмау, тел тотылу, тел төбе, тел чишү, тел шомарту*....)

- Укучылар безнең телебенең шундый матур, аһәңле булуына мәкальләрдә сәбәпче. Хәзер тел турында мәкальләрне искә төшерик. Бер өлешен мин әйтәм, калганын сез искә тошереп карагыз. Бу биремне үтәгән дә биредәге карточкалар сезгә ярдәмгә килер. Аларда мәкальләрнең инде икенче өлеше бирелгән. Сезгә бары, төгәл парлары белән генә туры китерергә кирәк.

- *1. Сүз - бер көнлек, тел - гомерлек*.
- *2. Тел - ананың баласына иң кадерле бүләге.*
- *3. Бер телдә ун хикмәт,*
- *Ун телдә йөз хикмәт*.
- *4. Тел - күңелнең көзгесе*.
- *5. Телләр белгән - илләр белгән*.
- *6. Тел ташны эретә.*
- *7. Инсафлының теле саф*.
- *8.Туган телем - иркә гөлем,*
- *Киңдер сиңа күңел түрем*.

- Афәрин укучылар, килеп чыккан мәкальләребезне тагын бер кат укып чыгыйк һәм истә калдырыйк.

- (*Укучылар мәкальләрне чиратлашып укып чыгалар*).

Укучылар, тактадагы ромашка чәчәгенә игътибар итегез. Таҗлары нинди? ( *Ромашканың таҗлары төрле төстә?)*

- Әйе, укучылар, сез бик дөрес игътибар иттегез. Безнең ромашкабызның таҗлары төрле матур төсләргә буялган. Бу гади генә ромашка түгел. Аның һәрбер таҗына күренекле галимнәребезнең тел турында фикерләре язылган.

- Мондый галимнәрдән кемнәрне атар идегез?

- (*К.Насыйри, Г.Тукай, К.Ушинский, Ә.Кәримуллин, Р.Йосыпов)*

- Бик яхшы. Укучылар бу фамилияләрне истә калдырырга кирәк, Әйдәгез, аларның тел турындагы фикерләре белән танышып китик. Ромашка таҗындагы фикерләрне укыйсыз һәм бу фикергә карата үз мөнәсәбәтегезне белдерәсез.

- (*Укучылар чиратлап бу биремне башкаралар*).

- Без - татарлар, телебез - татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул. (К.Насыйри)

- Халыкның теле - аның рухи тормышының иң яхшы, беркайчан да шиңми, мәңге яшәреп тора торган иң матур чәчәге. Телдә халык һәм аның Ватаны җанлы рәвештә гәүдәләнә, телдә халыкның бөтен рухи тормышының тарихы чагыла.(К.Ушинский)

- Милли тел язмышы ул - милләт яшәешенең нигезе. Телнең зәгыйфьләнә баруы ул - милләтнең юкка чыга баруының күрсәткече. Милләт ул - теле булган халык.

- Тел - халыкның, милләтнең иң беренче, иң әһәмиятле билгесе. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү - мәдәниятле, зыялы һәр кешенең изге бурычы. (Р.Йосыпов)

- Укучылар, Милли тел, милләт төшенчәләренә тукталып узыйк? Сез бу сүзләрне, сүзтезмәләрне ничек аңлыйсыз)

( *Укучыларның фикерләре тыңлана. Милли тел - берәр халык һәм алар яшәгән территория белән бәйле булган тел. Милләт - индустриаль чорның социаль -икътисади, мәдәни-сәяси һәм рухи җәмгыяте*)

- Дөньяда иң – иң матур ил -
Ул минем туган илем.
Дөньяда иң – иң матур тел –
Ул минем туган телем.

- Димәк, укучылар без сезнең белән тел турындагы мәкальләрне, шигырьләрне, галимнәребезнең эчтәлекле, төпле фикерләрен искә төшереп уздык. Сыйныф сәгатенең икенче өлешенә күчик. Берничә уенга тукталып узыйк.

(*Укучылар 2 төркемгә бүленә*)

**1нче бирем**. Һәр төркемгә сүзтезмәләр укыйм. Бу сүзтезмәләрне бер сүз белән алыштырырга кирәк, димәк, җавап биргән вакытта бер сүз белән генә җавап бирәсез.

I. – Истән чыгу. ( Оныту)
- Ике куллап. ( Ризалык)
- Инә күзеннән үткәрү . (Җентекләп)
- Борыны гына утырып калу. ( Ябыгу)

II. -Түбәсе күккә тию. ( Шатлану)
-Табан ялтырату. ( Бик тиз юкка чыгу)
-Җиде кат җир астында. ( Бик еракта)
-Борын төбендә генә.(Бик якын)

**2 нче бирем.** “Сүз эчендә сүз”дип атала О Л И М П И А Д А сүзеннән русча, татарча сүзләр төзергә кирәк.

О Л И М П И А Д А

(*Лампа, мода, пила, липа, дама, лом, Олимп, Мила, Лида, Дима, Ада, ипи, ми*)

**3 нче бирем.** Тел темасына синквейн (биш юллы шигырь) төзибез.

Синквейн төзү тәртибе:

Беренче юл - бер исем

Икенче юл - ике сыйфат

Өченче юл - өч фигыль

Дүртенче юл - бер җөмлә -девиз, лозунг була алырлык.

Бишенче юл - бер сүз (беренче сүзнең синонимы, нәтиҗә.

(*Һәр төркем үзенең синквейнын төзи, төркемнән бер кеше укый.*)

ТЕЛ

МИЛЛИ, АҺӘҢЛЕ.

ӨЙРӘТӘ, АҢЛАТА

ТЕЛ - МИЛЛӘТНЕ ЯШӘТӘ.

БАЙЛЫК.

**Рефлексия.**

Укучылар! Сүзебезне йомгаклап, зур ышаныч белән шуны әйтәсем килә. Татар теле – милләт теле. Без үз телебезне яратырга, хөрмәт итәргә тиеш. Көндәлек тормышыбызда без үзебезнең туган телебез-татар телендә күбрәк аралашсак иде. Милли телне саклау – милләтне саклау ул. Туган телебезне, милләтебезне саклау, яклау өчен без сезнен белән үз көчебезне кертергә тиеш. Сез минем фикерләрем белән килешәсезме, укучылар ?

(*Укучыларның да фикерләре тыңлана*)

- Афәрин укучылар. Бүгенге сыйныф сәгатебезне “И туган тел, и матур тел” җыры белән тәмамлыйк.

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле.
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән
Әнкәм бишектә көйләгән.
Аннары төннәр буе
Әбкәм хикәят сөйләгән.

*Казан шәһәре Совет районы 159 нчы лицейның*
*югары квалификация категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы*
*Шәрифуллина Саҗидә Якуп кызы*

**Тема: Муса Җәлилгә багышланган сыйныф сәгате.**

Сыйныф бүлмәсе бәйрәмчә бизәлгән. Уртада Муса Җәлил портреты. Аның янында кичәнең эпиграфы итеп шигъри юллар эленгән һәм Муса Җәлил әсәрләреннән китап күргәзмәсе куелган.

Эпиграф.

«Исемең калсын үзең үлсәң дә
Тарихларда укып ятларлык » .

**Максат:**

1. М. Җәлилнең туган илгә тугрылык хисе белән сугарылган шигырьләренең тарихи әһәмиятен ачыклау.
2. Укучыларның эзлекле фикер йөртү сәләтен, бәйләнешле сөйләм телләрен үстерү
3. Укучыларда М.Җәлил иҗатына һәм шәхесенә карата ихтирам, гражданлык һәм патриотлык хисе тәрбияләү.

**Җиһазлау.**

Китаплар күргәзмәсе, М. Җәлил портреты, рәсемнәр, иҗади эшләр күргәзмәсе; Муса Җәлил турында күренекле шәхесләр сүзләре язылган плакатлар.

**Катнашучылар**: 6 нчы сыйныф укучылары.

**Сыйныф сәгате формасы:** ШТК (Шаяннар, тапкырлар клубы).

## Сыйныф сәгатенең барышы

**I. Оештыру**.

Оештыру моментының төп максаты: балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру. Моның өчен укучылар белән әңгәмә үткәрелә.

Кәефләрегез әйбәтме? Парталарыгызда ятучы смайликлар ярдәмендә кәефегезне күрсәтегез.

- “Көнне яхшы сүз белән башласаң, бөтен көнең яхшы үтәр”, – диләр. Әйдәгез әле, бер-беребезне яңа көн белән котлыйк һәм бер-беребезгә елмаеп карыйк.

**II. Уку мәсьәләсен кую**.

Укытучы:

-Укучылар, игътибар белән экранга карагыз. Презентациядә язылган шигырьне укыгыз.

Иртәнге таң нурыннан
Уянды ромашкалар.
Елмаеп, хәл сорашып,

Күзгә - күз караштылар.

-Бу шигырьнең авторы кем? Бу өзек нинди шигырьдән?

-Укучылар җавап бирәләр.

- Укучылар, бүген без Муса Җәлил иҗаты турында сөйләшербез.

Быел, 2021 елны, Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 115 ел тула. Бүген без дә Муса Җәлилнең туган көнен билгеләп үтәргә дип җыелдык. Бөтен татар халкына, шулай ук башка милләт кешеләренә дә билгеле булган бу олы датаны без онытырга тиеш түгел. Муса Җәлил – халкыбызның горурлыгы. Аның исеме, шигырьләре мәңгелек!

IV. **Уку мәсьәләсен адымлап чишү**.

- Әйдәгез, ике төркемгә бүленер өчен ромашка таҗларын алыйк.

(*кызыл, ал төсле таҗлар*)

(*Укучылар ике төркемгә бүленәләр. Командаларга исемнәр, девиз, җыр уйлыйлар).*

- Биредә ике команда көч сынаша. ШТКның нәрсә икәнен сез беләсез инде. ШТК да бары тик зирәкләр, тапкырлар, эшкә оста, сүзгә кыска булган укучылар гына катнаша. Сезнең алда шундый ике команда. Ялыгыз күңелле үтсен! Зур уңышлар телим сезгә! Сизгер һәм кыю булыгыз!( *Сыйныф сәгатенә югары сыйныф укучылары хөкемдар итеп чакырыла*)

Бер-берсен сәламләү өчен ике команда укучылары тезелгән.

Сүз "Ромашка" командасына бирелә.

- "Ромашка" командасыннан "Сандугач" командасына ялкынлы кайнар сәлам!

Девизыбыз:

Чәчәктә таҗлар ни чаклы,

Бездә дуслар шул чаклы.

Җырыбыз:

"Җырларым" (М.Җәлил сүзләре).

Сүз "Сандугач" командасына бирелә.

- "Сандугач" командасыннан "Ромашка" командасына ялкынлы кайнар сәлам!

Девизыбыз:

Укырга, тырышырга!

Эзләнергә, табарга!

Җырыбыз:

"Тик булса иде ирек" (М.Җәлил сүзләре).

**Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты буенча белемнәрен тикшерү бәйгесе**. (*Һәр команда укучылары үзара киңәшләшә. Командадан бер укучы*

*җавап бирә. Җавап дөрес булмаса, бу сорауга икенче команда укучылары җавап бирә)*

"Ромашка" командасы сораулары:

1.Муса Җәлилнең әнисе кем исемле?

(Рәхимә.)

2.Муса Җәлил гаиләдә ничәнче бала булып дөньяга килә?

(Ул гаиләдә алтынчы бала була.)

3.Муса Җәлил кем белән бер төрмәдә булган?

(Абдулла Алиш.)

"Сандугач" командасы сораулары:

1. Беренче шигыре ничәнче елда һәм нинди псевдоним астында чыга?

(13 яшьтә, Кечкенә Җәлил.)

2. Тоткынлыкка ничәнче елда эләгә?

(1942 елда.)

3.Муса Җәлил кызының исеме ничек?

(Чулпан.)

(Хөкемдарларга сүз бирелә.)

**Муса Җәлил шигырьләре буенча рәсемнәр бәйгесе.**

(*Муса Җәлил шигырьләренә карата ясалган рәсемнәр күрсәтелә. Кайсы шигыренә иллюстрация? Кайсы команда күбрәк очко җыя? Беренче команда үз соравына дөрес җавап бирә алмаса, икенче команда җавап бирә*)

«Сандугач» командасы -«Ромашка» командасы

-«Бүреләр» -«Бакчачы бабай»

-«Куян» -«Карак песи»

-«Әтәч» -«Сәгать»

-«Ишек төбендә» -«Көз җитте»

**Муса Җәлил әсәрен сәхнәләштерү бәйгесе**.

“Сандугач" командасы “Бакчачы бабай”, “Ромашка” командасы “Кызыл ромашка” шигырен сәхнәләштереп күрсәтәләр.

(*Хөкемдарларга сүз бирелә*.)

**Капитаннар бәйгесе.**

Бирем: Ромашканың таҗ яфракларына Муса Җәлилнең шигырьләреннән өзекләр язылган. Шигырьнең исемен дөрес итеп әйтергә.

а) «Сиңа миннән хәбәр китерсәләр...»? (“ Ышанма”)

б) «Кайгырма, дус, яшьли үләбез дип..» ( “ Дуска”)

в) «Алар... Алар җыйнап аналарны...» (“ Вәхшәт” )

г) «Кешеләр сугыша, кан коя...» (“ Бүреләр”)

д) «Тик чуклары ак түгел....»( “ Кызыл ромашка”)

**IV. Рефлексия.**

-Укучылар, М. Җәлил иҗаты нәрсә белән исегездә калды?

(*Укучыларның җаваплары тыңлана*).

Аннары хөкемдарларга сүз бирелә.

**Йомгаклау.**

Муса Җәлил исән, ул безнең арабызда. Муса Җәлил – халык шагыйре. Ул – халыклар герое! Бөтен гомерен халык өчен биргән, бөтен җырын халыкка багышлаган герой- шагыйрь үлемсез!

**Әдәбият**


1. Җәлил М. Моабит дәфтәрләре. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2000 ел
2. Җәлил М Сайланма әсәрләр.- ТАРИХ-2004
3. https://nsportal.ru/shkola/rodnoy-yazyk-i-literatura/library/2019/12/05/musa-zhlil-batyrlygyn-halyk-mnge-onytmyy
4. https://nsportal.ru/shkola/rodnoy-yazyk-i-literatura/library/2020/05/22/gabdulla-tukayga-bagyshlangan-kvn-kichse
5. https://botana.biz/prepod/drugoe/ofav049c.html



*Төзүче: Казан шәһәре Совет районы 141 нче гимназиянең*
*югары квалификация категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы*
*Әхмәдуллина Рәмзилә Фердинант кызы*


**Тема: Муса Җәлилнең “Ана бәйрәме” шигырен сәхнәләштерү**

**Сыйныф сәгатенең формасы**: әдәби-музыкаль кичә, IV сыйныф

*Илебез Җиңүне бәйрәм иткән көннәрдә мәктәпләрдә дә төрле чаралар үтә. Мин рус мәктәбендә эшлим, кызганыч, шәһәр җирлегендә чиста татарча сөйләшүче балалар бик аз, әсәрләр сәхнәләштергәндә бу нык сизелә. Шулай да укучыларга туган телебезнең матурлыгын җиткерәсе, аларны сугыш кырларында ятып калган шагыйрьләребез, язучыларыбыз иҗаты белән таныштырасы килә. Хәзерге балалар китап укырга яратмыйлар, вакытларын күбрәк телевизор алдында үткәрәләр. Мин, дәресләрне кызыклырак итү максатыннан, мультфильмнар күрсәтәм. Интернет киңлекләрендә татарча бик матур мультфильмнарны табарга мөмкин.*

*Әлеге сыйныф сәгатенә әзерләнгәндә укучыларга Муса Җәлил шигырьләренә төшерелгән мультфильм белән алдан таныштырдым. Шагыйрьнең “Ана бәйрәме” шигырен әлеге мультфильм ярдәмендә сәхнәләштердек. Кичә Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Нур Баян һәм башка шагыйрьләрнең шигырьләреннән тора. Сыйныфымда рус балалары да булуын исәпкә алып, кайбер шигырь юлларын гадиләштердем.*

**Максат:** Укучыларда туган илгә карата патриотик хисләр тәрбияләүне дәвам итү.
**Бурычлар:**
-белем бирүдә: укучыларга сугыш алып килгән фаҗиганен тирәнлеген аңлату, сугыш чорында иҗат иткән шагыйрьләрнең шигырьләре һәм сугыш темасына багышланган җырлар белән таныштыру;
-үстерелешле: балаларда кызыксынучанлыкны үстерү, сөйләм телләрен баету;
-тәрбияви: әниләргә карата хөрмәт, туган җиреңбелән горурлану хисләре тәрбияләү.

Алдан эшләнгән эш: “Ана бәйрәме” мультфильмын карау, сугыш темасына, җиңү бәйрәменә багышланган шигырьләр, җырлар өйрәнү.
**Җиһазлау**: сугышны, авыл тормышын, җиңү бәйрәмен сурәтләгән презентация, магнитафон.

Катнашалар: ике алып баручы, әни, әнинең өч улы, кош, хат ташучы, өч ромашка, чишмә, берничә малай һәм кыз.
(*Вакыйга өйдә бара. Әнинең ике улы һәм берничә малай һәм кыз шаярып өйдә уйныйлар, көлешәләр.*)
**1нче кыз**. Әйдәгез уйнарга!
**Әнинең зур улы**. Әйдәгез, дусларым! Каникул бит! Ял итәбез.
**2 нче кыз**. Иртәгә Сабантуй! Бергәләшеп җырлыйбыз. Сабантуйга әзерләнәбез!
**Әнинең кече улы**. Әйдәгез, иртәгә Сабантуйга җырлыйсы җырны кабатлыйбыз!
(*Бергәләшеп К. Булатованың “Солдатлар” җырын башкаралар. Күңелле җыр вакытында әни килеп керә.*)
**Әни.** (*Кулларын сөртеп.*) Балалар! Туктагыз! Тагын уйныйлар, тагын җырлыйлар. Кайчан мина булышасыз, өйдә күпме эш!
**1 нче кыз**. Күрше апа, без бит Сабантуйга әзерләнәбез, ачуланмагыз инде.
**Әнинең уртанчы улы**. (*Улы йөгереп кайтып керә.*) Әни, әни сугыш башланган, радионы куй!
**Әни**. (*Әни куркып радионы кабыза.*) Балалар, тавышланмагыз, тыңлагыз!
**Балалар**. (*Бергә.*) Сугыш! Сугыш башланган! (*Радиода Левитан тавышы, барысы да куллары белән башларын тоталар, акрын гына чыгып китәләр.*)
**Әни**. (*Залда үзе генә.*)
Улларым, кош кебек очыгыз,
Дошманны сез илдән куыгыз.
Без түзәрбез, сезне көтәрбез,
Илгә Җиңү белән кайтыгыз!
(*Еракта солдатларның марш атлавы ишетелә, тавыш якыная. Сугыш киеменнән әнинең кече, уртанчы, өлкән улы һәм хат ташучы кыз, шәфкать туташы һәм берничә бала кулларын болгап, саубуллашып, сугышка китәләр.*)

**Бергәләшеп**. Без урамнан үткән чакта
Күтәрелде томаннар,
Дөнья хәлен белеп булмый
Сау булыгыз туганнар. (*Әни күз яшьләрен сөртеп, озатып басып кала.Залга 1нче алып баручы кыз чыга.)*

**1 нче алып баручы**.
Менә шулай халык ул елларда
Ватан өчен утка атылды.
Менә шуңа күрә бу зур сугыш
Ватан сугышы дип аталды.
(Резеда Вәлиева)

(*Бераздан әни чыга. Аның янында кош киеменнән кыз салмак кына көйгә биеп йөри. Әни ялварулы тавыш белән кошка эндәшә.*)

**Әни**.
Өч баламны, очар кош итеп,
Мин очырдым иркен далага.
Әйтче, кошым зинһар, үз итеп,
Сагыш белән кипкән анага.
Кайда йөри минем улларым?
(Муса Җәлил)

(*Кош очып чыгып китә. Сугыш кыры. Салмак көйгә өч ромашка чыга. Алар әкрен генә әйләнәләр, куллары белән салмак хәрәкәтләр ясыйлар. Араларында кош йөри. Сугыш тавышлары ишетелә. Ромашкалар талгын гына чүгәлиләр. Кош алар артына кача. Әнинең өлкән улы чыга. Ул автоматы белән дошманнарына ата, ләкин егыла.*)

**Әнинең өлкән улы**.
Минем өстән пуля яуса да,
Яралардан каннар тамса да,
Халкым өчен постта торам,
Халкым өчен мин үләм.
( Нур Баян)

**2 нче алып баручы**.
Иртәнге таң нурыннан
Уянды ромашкалар.
Елмаеп, хәл сорашып,
Күзгә-күз караштылар.
(Муса Җәлил)

(*Ромашкалар акрын гына торалар, кош чыга, җирдә солдат ята.*)

**Ак ромашка**. (*Ул бик нык гаҗәпләнә.*) Без барыбыз да ак күлмәктән, дустым, синең күлмәгең ни өчен кызыл?

**Кызыл ромашка**. (*Ромашка солдатны сыйпый.*)

Төнлә минем яныма
Ятып батыр сугышчы
Атты дошманнарына.
Ул берүзе сугышты
Унбиш солдатка каршы;
Чигенмәде, тик таңда
Яраланды кулбашы.

(Муса Җәлил)

(*Барысы да акрын гына чыгып китәләр, сәхнәдә кош кала, ул әни янына кайта.*)

**Кош**. Кайгы сиңа, ана, Кырымда
Улың үлде сугыш кырында.

(Муса Җәлил)

**1 нче алып баручы**. (*Ул ак шәлне әнинең өстенә сала.*)

Катып калды ана, дәшмәде,
Ярсып чыкты кайнар яшьләре.
Кайгысыннан өлкән улының
Көмеш төсле булды чәчләре.

(Муса Җәлил)

(*Сәхнәдә талгын көй яңгырый, әни алгарак чыга, артта хат ташучы хатлар өләшә. Әни ялварулы тавыш белән аңа эндәшә.*)

**Әни**. Өч баламны, очар кош итеп,
Мин очырдым иркен далага.
Әйтче, зинһар, үз итеп,
Сагыш белән кипкән анага.
Кайда минем уртанчы улым?
Кайталмады өйгә зур улым.

(Муса Җәлил)

(*Әни сәхнәдән чыгып китә. Сугыш кыры. Уртанчы улы килеп чыга, юл сумкасыннан кружка алып, су эчә, автоматын куя. Хат яза башлый. Артта хат ташучы килә. Талгын көй.*)

**Уртанчы малай**.

Бәлки, әни, бу хат соңгы хатым булыр,
Иң дәхшәтле утка керәмен,
Шулай була калса, кояшны да
Бүген соңгы тапкыр күрәмен.

(Фатих Кәрим)

Сау бул, әнием, илем өчен мин үләмен.
(*Солдат хатны хат ташучыга бирә, үзе сәхнәдән чыгып китә. Хат ташучы әнигә өчпочмаклы хатны кайтарып бирә.*)
**Хат ташучы**.
Кайгы сиңа, ана, уртанчы
Улың үлде сугыш кырында.
Соңгы йөрәк тибеше тынганчы,
Автоматы булды кулында.
(Муса Җәлил)
Әнисе, туган иле иде уенда.
(*Әни хатны укый, күз яшьләрен сөртә. Сәхнәгә кабат кош чыга. Әни тезләнеп, кошка эндәшә.*)
**Әни**.
Ике улым үлде сугышта,
Бер өметем калды тормышта:
Күрмәсәм дә бергә өчесен,
Мин күрермен, бәлки, кечесен?
(Муса Җәлил)
(*Әни кереп югала, кош очып йөри. Сугыш тавышлары ишетелә һәм туктап кала, аны чишмә челтерәве алыштыра. Сәхнәгә чишмә булып киенгән малай чыга. Кош аның янында бөтерелә.*)
**Чишмә**. Кичә минем суны фашист агулады, бүген аны батыр егет эчәчәк. Мин белмим аңа ничек булышырга. Дустым-кошым, ярдәм ит солдатка. Эчмәсен минем суны!
**Кош.**
Кайгырма, күз нурым!
Ул килсә эчәргә,
Коткарам мин үзем,
Мин беләм нишләргә!
(Муса Җәлил)
(*Сәхнәгә әнинең кече улы чыга.*)
**1 нче алып баручы**.
Батыр егет килде, күрде чишмәне,
Ул теләде эчәргә салкын суны.
**2 нче алып баручы**.
Кошчык бик озак сайрады,
Егетне коткарырга ул теләде.
(*Солдат егет чишмәне күрә.*)
**Кош**. Батыр егет, эчмә, син бу суны.Ул бит агулы! (*Егет су эчәргә тели.*)

**Әнинең кече улы**. Чишмә суы, бик эчәсем килә. Кошым, мин бит аңламыйм сине! (*Солдат кружкасындагы суны кош эчә һәм егыла*.)

**Әнинең кече улы**. Димәк, чишмә суы агулы булган?! Кошым, мине коткарган өчен рәхмәт сиңа.

**Ике алып баручы**. (*Бергә.)*

Никтер очмый күктә күгәрчен,
Җил дә тынган, йоклый, күрәсең.
Тик яңратып урман буйларын,
Ишетелә быргы уйнавы.

(Муса Җәлил)

(*Еракта быргa тавышы ишетелә, аны дәртле җиңү көе алыштыра. Сәхнәгә чәчәк тотып хат ташучы кыз һәм батыр егет килеп керә*.)

**Әни**. (*Әнинең шатлыгы йөзенә чыга*.)

Балам! Кайттыңмы, улым, алтыным!
Куанычым минем, актыгым!

(Муса Җәлил)

(*Хат ташучы кыз әнигә чәчәкләр бирә*.)

**Әнинең кече улы**. Әнием, синең кече улың Җиңү шатлыгын алып кайтты. Абыйларым сугышта улсә дә, аларның батырлыгын мәңге онытмаслар!

Дүрт ел дәвам иткән бу сугышта
Миллионнар башын салдылар.
Ватан сугышының геройлары
Тарихларга кереп калдылар.

**Ике алып баручы**. (*Бергә*.)

Җиңү килде җирне нурга күмеп,
Шатлык белән күзне чылатып.
Килде ул көн — горур күкрәкләрдә
Орден-медальләрне чыңлатып.

(Рамазан Байтимиров)

(*Катнашучылар сәхнәгә чыгалар. Уртада әни*.)

**Әни.** Беркайчан да булмасын сугышлар! Тыныч тормышта гына яшәсен оныклар!

(*1 нче сыйныф укучылары тынычлык турында шигырьләр сөйлиләр. Ахырдан бергә " Бөек шагыйрь- Муса Җәлил" җырын башкаралар*.)

**Әдәбият**


1. Муса Җәлил "Ана бәйрәме" шигыре.
2. Муса Җәлил " Кызыл ромашка" шигыре.
3. Муса Җәлил "Сандугач һәм Чишмә" шигыре.
4. Нур Баян " Минем өстән пуля яуса да..." шигыре.

5. Рамазан Байтимиров “Җиңү көне” шигыре.
6. Резеда Валиева “Муса Җәлил – халкым улы” шигыре.
7. Фатих Кәрим “Ватаным өчен” шигыре.

*Төзүче: Казан шәһәре Совет районы 11нче татар гимназиясенең югары квалификация категорияле башлангыч сыйныф укытучысы Шиһабиева Әдилә Халик кызы*

**Тема: Матур өй**

**Максат:**

1)Туган телдә әдәби китаплар укуга кызыксыну уяту, фикер йөртү сәләтләрен, сөйләм телләрен үстерү.

2) Йорт төзелеше белән бәйле һөнәрләр хакында мәгълүмат бирү

3) Туган якка мәхәббәт, табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.

**Күрсәтмәлелек:** Презентация, машина, өй макетлары, балалар санынча Р.Харисның “Матур өй” шигыре.

**Катнашучылар**: 3 нче сыйныф укучылары

**Класс сәгатенең барышы**

**<u>Сыйныф җитәкчесе:</u>**

- Исәнмесез, укучылар. Әйдәгез әле бер-беребез белән исәнләшик, хәерле көн телик.

*<u>Балалар “СӘЛАМ” җырының 1 куплетын башкаралар.</u>*

**<u>2 нче слайд. Сыйныф җитәкчесе:</u>**

- Бүгенге сыйныф сәгатебездә төркемнәрдә эшләрбез. Һәр өстәлдә <u>табышмак-шигырьләр</u> бар. Аларның җавапларын табыйк.

**<u>3 нче слайд</u>**

1. Өй салалар күр әнә
Өелеп бара ...... **(бүрәнә)**
2. Таш өйләр дә була ич,
Өелеп ята ..... **(кирпеч)**
3.Түшәмгә кирәк чакта
Китерделәр бит ..... **(такта)**
4. Читтә торма син алай
Түбәгә кирәк ....**(калай)**
5. Өй салуга көчеңне түк
Кыстырырга кирәк...... (мүк)

*<u>Укыйлар, җавапларын әйтәләр, тактага рәсемнәре чыга бара</u>*

**Сыйныф җитәкчесе:** Укучылар, болар барысы да кая кулланыла? *(төзелештә, биналар төзегәндә, өй салганда)*

**Сыйныф җитәкчесе:** Димәк, бүгенге класс сәгатендә нәрсә турында сөйләшербез? *(төзелеш турында, өй салу турында)*

**Сыйныф җитәкчесе:** Бик дөрес. Без бүген “Матур өй” дигән шигырь укырбыз.

**4 нче слайд: -**

-Аны кем язганын, шушы башваткычны чишкәч белербез. Аның өчен төшеп калган хәрефләрне өстәргә кирәк. Башваткычта өй салу белән бәйләнгән сүзләр язылган.

**5 нче слайд, тикшерәбез**

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **Х** | е | з | м | ә | т |
| б | у | р | **а** | | | | | |
| | к | ә | **р** | н | и | з | | |
| | | | **и** | д | ә | н | | |
| | б | а | **с** | к | ы | ч | | |

- Димәк, шигырьнең авторы кем булды? **6 нчы слайд:** Ренат Харис

**Сыйныф җитәкчесе:** Р. Харисның шигырь яза белү сәләтеннән кала тагын бик күп осталыклары бар. Ул бик матур итеп рәсемнәр ясый, гармунда да уйный белә. Шул эшләр белән шөгыльләнгәндә ял итүен, күңеленә сихәт алуын әйтә ул.

**7 нче слайд сыйныф җитәкчесе:** Бүгенге сыйныф сәгатендә үз алдыбызга нинди максатлар куярбыз? *Максатларны балалар билгели. Мәсәлән:*

*1: Яңа шигырен сәнгатьле укырга өйрәнәбез*

*2: Өй салу тәртибе белән танышабыз*

*3: Нинди өй матур булганын беләбез*

**Сыйныф җитәкчесе:** Башваткычтагы сүзләрнең барысында сез Ренат Харисның “Матур өй” шигырендә очратырсыз. Мәгънәләрен карап китик әле.

**8 нче слайд. Сыйныф җитәкчесе:** Хәзер шигырь белән танышабыз. Ни өчен шигырь “Матур өй” дип атала икән?

*(Шигырьне бергәләп укыйлар, 9-11 слайд шигырьгә иллюстрация).*

**Сыйныф җитәкчесе:** Шигырь ошадымы? *(Әйе)*

-Нәрсә белдегез? Берүзең генә өй салып буламы? (*Алар дус эшләгәннәр, бергә эшләгәннәр, ял иткәннәр, өй салу авыр эш, өй салу бик җаваплы эш, өй салуның тәртибен белдек һ.б.)*

**Сыйныф җитәкчесе:** Өй салу җиңелме? (*Юк*)

**12 нче слайд. Сыйныф җитәкчесе:** Кешеләр генә түгел, кырмыскалар да өйләрен бергәләп төзиләр. Без дә аларга булышып алыйк әле.

*Физминутка: “Кырмыскалар” җырын хәрәкәтләр белән башкару*

**13 нче слайд. Сыйныф җитәкчесе:** Өй салуда нинди һөнәр ияләре катнаша? *(Балта остасы, ташчы, буяучы, машина йөртүче)*
**14 нче слайд. Сыйныф җитәкчесе:** Өй салуда кешегә ярдәмгә нәрсәләр кирәк? *( Машиналар килә)* Төзелештә нинди машиналар катнаша?
**15 нче слайд** (*Уенчык машиналар күрсәтелә, укучылар белгәннәрен сөйлиләр*)
**16 нчы слайд. Сыйныф җитәкчесе:** Өй матур булсын өчен нишләргә кирәк? Шушы сорауга җавапны тексттан табып, хор белән укыйк әле.
**17 нче слайд**

- Сез әти-әниләрегез белән бергә проект эше эшләгән идегез. Төрле өй макетлары төзедегез. Шулар арасыннан күргәзмәдә бу өй 1 урынны алды. *(Бүрәнәдән салынган өй макеты күрсәтелә)*

– Өй матурмы? Бу өй Ренат Харисның “Матур өй” шигырендәге сез укыган өйгә охшаганмы?” Буген Гузаярова Алсу да безгә үзенең язган шигерен бүләк итәргә тели. Әйдәгез, аңа сүз бирик әле.

**Өй кайчан матур була?**

Өй кайчан матур була?
Дуслар җыелган чакта.
Дус һәм тату булып
Бергә эшләгән чакта.
Өй кайчан матур була?
Дус, тату яшәгәндә.
Бергәләп ял иткәндә,
Бергәләп эшләгәндә.

**18 нче слайд. Рефлексия. Сыйныф җитәкчесе:**

- Сезнең арада да кайберләрегез үз өйләрендә яши. Күпфатирлы йортларда яшәүчеләр дә бар.

*Балаларга тәрәзәсез күпфатирлы өй макеты куела.*

- Бу өй матурмы? Нәрсә җитми?
- Хәзер без сезнең белән тәрәзәләрдә утлар кабызырбыз. Моның өчен сезгә тәрәзәнең төсен сайлап алырга кирәк булыр:

Зәңгәр төстәге тәрәзәләр – барысы да аңлашылды, кызык булды.
Кызыл төстәге тәрәзәләр – әзрәк сораулар калды.

*Төзүче: Казан шәһәре Киров районы 8 нче урта гомуми белем мәктәбенең беренче квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хәйруллин Илһам Рифкать улы*

**Тема: Туган телем – иркә гөлем (Туган телләр һәм халыклары дуслыгы елына багышланган сыйныф сәгате).**

**Максат**: Туган телебез, туган ягыбыз, әти-әниләребезгә мәхәббәт тәрбияләү, туган телебезнең нәфислеген тоярга өйрәтү.

**Сыйныф сәгатенең барышы**

*Әкрен генә Габдулла Тукайның "Туган тел" шигыренә язылган көй яңгырый.*

**Укытучы**: Укучылар, сез бу көйне тыңлагач, шигырьнең авторын таныдыгызмы? Бүгенге сыйныф сәгатебезнең темасын ачыклыйк әле.

**Көтелгән җавап:** Бу татар халык шагыйре Габдулла Тукайның "Туган тел" шигыренә халык тарафыннан язылган көйне тыңлап уздык. Шигырьнең исеменнән аңлашылганча, бүгенге сыйныф сәгате туган телебезгә багышланачак.

**Укытучы:** Әйе, укучылар, бүген без туган телебез хакында сөйләшербез, аның турында кызыклы мәгълүматлар белән танышып китәрбез.

**1 нче укучы** (*Энҗе Мөэминова шигырен сөйли*):

Дөньяда иң-иң матур ил,
Ул - минем туган илем.
Дөньяда иң-иң матур тел,
Ул – минем туган телем.
"Балам!" – диеп туган телдә
Эндәшә миңа әткәм.
"Әнием!" – дип, энкәемә
Мин туган телдә әйтәм.
Туган телемдә сөйләшеп,
Яшим мин туган илдә.
"Туган ил" сүзен дә
Әйтәм мин туган телдә.
Иң изге хисләремне мин
Туган илдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин яратам.

**Укытучы:** Туган тел һәм Туган ил, әни төшенчәләре гел янәшә кабатлана. Әйдәгез, әни турында бер шигырьне тыңлап узыйк.

**Укучы:** (*Әлфия Ситдыйкованың әниләргә багышланган шигыреннән өзекне сөйли)*

Ана җирдә бала өчен
Гомер буе булып торәге.
Аннан суга, янган утка керә,
Бала өчен тибә йөрәге.
Бер минут та истән чыгармый ул,
Гомер биргән сөю җимешен.
Җаны белән тоеп яши Ана
Баласының йөрәк тибешен.
Ана күңел-диңгез. Бар да сыя:
Борчулар да, шатлык – барсы да.
Сөенечле язлар, якты җәйләр,
Көзе-кышы, моңы-зары да.

*("Әнкәйнең догалары"(Роберт Миңнуллин шигыре, Илгиз Закиров көе) җыры башкарыла).*

**Укытучы:** Кошның ике канаты булган кебек, баланың да ике канаты -таянычы бар. Берсе – әни, икенчесе - әти. Әтиләр турында да бер шигырь тыңлыйк.

**Укучы: (***Әнисә Насретдинованың шигырен сөйли***)**:

Һәрвакытта иңнәремдә
Тоям әтием кулларын.
Һәрчак тыныч һәм бәхетле
Булсын барыр юлларым.
Кирәк булса, әтиләр күк
Утлар-сулар кичәрбез.
Илебезне саклау өчен
Батыр булып үсәрбез.

**Укытучы:** 2020 нче ел безнең өчен нинди тарихи дата белән истә калды икән? Шуны искә төшереп узыйк әле.

**Көтелгән җавап:** 2020 нче елда Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасының 100 еллыгын билгеләп үттек.

*1) ТАССРның 100 еллыгына багышланган презентациясе белән танышу;*

*2) Азат Аббассов башкаруында "Без кабызган утлар" (Кәрим Тинчурин сүзләре, Салих Сәйдәшев көе) җырыннан өзек тыңлап китү.*

**Укытучы:** Әйдәгез, бүгенге сыйныф сәгатенең төп темасына – туган телебез хакында турында мәгълүматлар белән танышып китик.

Без - татарлар, туган телебез татар теле.

Татар теле... Тугач та иң газиз кешеңнән ишетә башлаган, күп гасырлык тарихы булган, Каюм Насыйрилар, Тукайлар нигез салган, 7 миллион халык сөйләшкән, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган,

бүгенге көндә камилләшкән, иң-иң авыр кимсетүләргә дә түзгән, сынмаган-сыгылмаган, баш имәгән горур татар теле!
*(Укучылар бер-бер артлы татар теле турында кыскача белешмәләр белән таныштыралар, шул ук мәгълүматлар слайдлар рәвешендә күрсәтелеп бара).*
**1 нче укучы:** Татар теле - ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья аралашу теле дип саналган телнең берсе: инглиз, алман француз, испан, итальян, португал, гарәп, фарсы, рус, кытай, төрек, япон, һинд, татар телләре.
Татар телен белгән кеше 30дан артык төрки халык белән иркен аңлаша һәм аралаша ала.
**2 нче укучы** Хәсән Туфанның "Туган тел" шигыреннән өзекне сөйли.
Һәр галимнең, һәр шагыйрьнең сүзе
Җитсен иде һәрбер күңелгә,
Җилләр, сулар тавышы шикелле үк,
Үзләренең асыл телендә.
Атом көче, радио заманында
Күрсәм иде шуны мин тагын:
Ярдәмләшеп, телләр бер-берсендә
Тапса фәкать кардәш, туганын.
**3 нче укучы:** Татарлар – Россиянең күп кенә өлкә-республикаларында, Урта Азия һәм Европа илләрендә, Америка Кушма Штатларында, ерак Австралиядә гомер кичерүче халык.
Россиядә татарлар сан буенча икенче урында. Иң күп яшәү төбәкләре – Татарстан һәм Башкортостан республикалары.
"Туган телем" җырын (*Рәфис Корбан шигыре, Мөхтәр Минһаҗев көе*) башкару.
**4 нче укучы:** Татар теле башка төрки телләрне белү өчен ачкыч булган, Һиндстан, Кытай, Иран һәм башка күп кенә илләр белән рәсми эш кәгазьләре татар телендә алып барылган. Ягъни Россиядә гомер бакый дипломатия теле хезмәтен башкарган.
**5 нче укучы:** 1764 нче елдан башлап Әстерхан мәктәпләрендә солдат балаларына татар теле укыталар. Екатерина II боерыгы буенча, гимназиянең беренче укытучысы итеп Сәгыйть Хәлфин билгеләнә. Гимназиядә татар теле укыту тәҗрибәсенә нигезләнеп, ул "Әлифба" дәреслеген яза. 1778 нче елда бу хезмәт Мәскәүдә басылып чыга. Татар басма әлифбасының тарихы шушы китаптан башлана.
*("Әлифба" җырын (Рәзил Вәлиев шигыре, Рәшит Абдуллин көе) башкару).*
**6 нчы укучы:** Язу тарихы белән кыскача танышып китик. Борынгы төркиләрнең һәрберсенә хас – рун язуын куллану. Идел Болгарстанында ислам дине рәсми төстә кабул ителгәч, гарәп графикасы кулланышта була. 1929-1939 нчы елларда латин графикасы нигезендә алфавит файдаланылган. Ә 1939 нчы

елдан башлап кириллица графикасына тагын татар теленә хас 6 хәреф өстәлгән алфавит кулланышта.

**7 нче укучы: Нажар Нәҗминең “Татар теле” шигыреннән өзекне сөйли.**

Туган җирең Идел буе,
Һәр телнең бар Туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.
Ак алъяпкыч бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йөзле татар теле.

**Укытучы:** Кызыклы мәгълүматлар белән танышып китик.

“Үзе бер карыш, сакалы биш карыш” дигән сүзләр әкиятләрдә еш очрый. Күпме озынлыкта булган соң ул сакал? Яисә “түтәрәм-түтәрәм тарым бар, күтәрә алсаң, барын да ал” дигән табышмак-гыйбарәне кем генә белми икән? Бер түтәрәм тары күпме авырлыкта булган соң?

Борынгыдан килгән болгар-татар үлчәү (озынлык, ераклык һәм авырлык) берәмлекләрен күбебез хәзер олылардан ишетеп кенә, яисә китаплардан укып кына белә, әмма күп очракта мәгънәләрен аңламый калабыз. Менә кайбер шундый үлчәү берәмлекләренең аңлатмалары:

Ук атымы - атылган укның очу ераклыгына тигез ара.

Колач – як-якка сузылган икен кул арасы (бер кулның бармак очларыннан икенче кулның бармак очына кадәр).

Бер кул буе – җилкәдән бармак очларына кадәр булган ара.

Карыш – киерелгән кулның баш бармагы очы белән урта бармак очы арасы, уртача чирек аршынга тигез.

Күз күреме – тигез урында күреп була торган ара.

Өрмәк – эт өргән тавышны ишетеп булган ара.

Аршын – 71 см тигез.

Кадак (гөрәнкә) – 409, 5 грамм чамасы.

Мыскал – 1/96 кадак – якынча 4,26 грамм.

Түтәрәм – нәрсәнең дә булса чиреге, ягъни дүрттән бер өлеше.

Әҗмуха – нәрсәнең дә булса сигездән бер өлеше.

Безнең бабайлар чиләк, капчык, подаука (бер пот әйбер сыешлы агач яки калай савыт), коштабак кебек үлчәү берәмлекләрен дә кулланган.

**1 нче укучы**: Иң борынгы әдәби ядкяре булып, Кол Галинең “Йосыф-Зөләйха” поэмасы тора (13 йөз). Ул иске татар әдәби телендә язылган.

**2 нче укучы:** 19 нчы гасырның 2 нче яртысында тулаем хәзерге татар әдәби теле формалаша башлый, 1910 нчы елга тәмам иске татар әдәби телен

кысрыклап чыгара. Татар халкы Россия империясендә яшәүче иң укымышлы милләтләрнең берсе була.

**3 нче укучы**: 18 гасыр ахырыннан башлап татар теле дәресләре Мәскәү университеты каршындагы Академик гимназиядә, Тобольскида һ.б. берничә шәһәрдә дә алып барыла. Томск, Оренбург, Сарытау, Әстерхан, Ставрополь гимназияләрендә татар теле мәҗбүри уку предметлары исемлегенә кертелә. 1812 нче елдан Казан университетында татар теле укытыла башлый.

**4 укучы:** Татарстан Республикасында ике тел дәүләт теле, дип исәпләнелә. Алар – рус һәм татар телләре. Бу ике телне белү – һәрберебезгә дә файдага.

**5 укучы:** Шәйхи Маннурның шигыреннән өзекне укып китә:

Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел,
Икесе дә безнең өчен
Бик кирәкле, затлы тел.

**Укытучы**: Шуның белән сыйныф сәгате ахырына якынлаша. Барыбыз да басып, татар халкының гимнына әверелгән “Туган тел” җыры белән тәгалләп куябыз.

*Төзүче: Казан шәһәре Мәскәү районы “М.С. Устинова исемендәге 102 нче гимназиянең югары квалификация категорияле туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучысы Лифантьева Лилия Гарифулла кызы*

**Тема: Яхшы сүз - җан азыгы (4 - 5 сыйныфлар өчен).**

**Максат:** Яхшы сүзнең яхшы тәрбия бирүдә тоткан урынын күрсәтү, матур итеп сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Компьютер, проектор.

**Сыйныф сәгате барышы**

**I. Оештыру.**

- Исәнмесез, укучылар! Хәерле көн! Сыйныф сәгатебезне башлыйбыз.

**II. Уку мәсьәләсен кую.**

- Бервакыт хуҗа үзенең колын чакырта. “Менә сиңа акча, базарга бар һәм дөньяда иң гүзәл нәрсәне алып кайт”, -ди.

Кол китә һәм өсте салфетка белән ябылган поднос алып килә. Салфетканы күтәреп карасалар, анда тел ята.

“Син тел алып кайткансың”, - ди хуҗа.

“Бу дөньяда иң гүзәл нәрсә түгелмени? Тел белән без иркәләү, тугрылыклы булу һәм сөю сүзләре әйтәбез”, -дип җавап бирә кол.

Хуҗа бераз уйлаганнан соң болай ди: “ Син кабат базарга бар һәм дөньяда иң коточкыч нәрсәне алып кайт”.
Кол шул ук поднос белән әйләнеп кайта. Салфетка астында тел ята. Хуҗа: “Син тагын тел алып кайткансың”, - ди.
Кол болай ди: “Ул коточкыч нәрсә түгелмени? Тел белән без нәфрәт сүзләрен әйтәбез. Тел белән без сугыш игълан итәбез”...
**Сораулар:**
- Бу притчада сүз нәрсә турында бара? ( Телнең яхшы хәбәр сөйләргә дә, начары турында белдерергә дә сәләтле булуы турында).
- Андый хәбәрләрне тел нәрсә аша җиткерә? ( Сүзләр белән).
- Сүзләрнең ниндиләре була? ( Яхшылары да, яманнары да).
- Димәк, бүген без нәрсә турында сөйләшәчәкбез? (Укучыларның фикерләре).
**III. Төп өлеш**
- Нәрсә ул тел? (Аралашу чарасы, сөйләү өчен хезмәт итә торган корал).
- Яхшы сүзне кемнәр әйтә? ( Укыган, белемле, тәрбияле, әдәпле кешеләр әйтә).
- Ә ачу килгән вакытта яхшы сүз әйтеп буламы? ( Мондый вакытта акыллы кешеләр начар сүз кулланмас: алар йә эндәшмиләр, йә кешенең күңелен яраламый торган сүзләр кулланып, әйтәселәрен аңлатырлар).
- Начар сүзләрдән котылып буламы? Ничек? ( Була. Үз-үзеңне тәрбияләргә кирәк; сүз байлыгыңны арттырырга кирәк, моның өчен күп укырга кирәк).
Каюм Насыйриның «Китаб – әт – тәрбия» китабында түбәндәге юллар бар:
64 нче тәрбия. «Тел җәрәхәте кылыч җәрәхәтеннән ачырактыр вә яманрактыр, ягъни телдән әйтелгән ачы вә кабәхәт сүзләрнең адәмгә тәэсире тәнеңне пычкы белән кискәннән дә ачырактыр. Әй, угыл, һичбер кешегә телең белән җәрәхәт салма, ягъни яман сүз әйтмә... Әмма бер сүзне син кулай хисаплап әйтсәң дә , кешенең күңеленә бик каты тияр. Әй,угыл, каты сүзле булма. Изге холык вә йомшак сүзгә адәмнең күңеле эреп китәдер. Кешегә ашыгып сүз әйтмә вә уйламыйча ашыгып җавап бирмә”.
89 нчы тәрбия. “Әй, угыл, кешенең күңеленә хилаф килә торган сүзне телеңә китермә. Бер сүзне син уйламыйча әйтеп җибәрерсең, ишеткән кешенең күңеле җәрәхәтләнә торган сүз булыр, күңеле рәнҗер. Кеше күңелен рәнҗетүдән бик саклан.”
- “Йомшак сүзгә адәмнең күңеле эреп китәдер”, - дигән җөмләне ничек аңлыйсыз? ( Кешеләрнең күңеле, кәефе күтәрелә, рәхәт була).
- Кешене рәнҗетүне сез ничек аңлыйсыз? ( Рәнҗетү –кемгә дә булса хаксызлык күрсәтү, кыерсыту, кимсетү).
- Әлбәттә, балалар, начарлыкны эшләмәскә кирәк, чөнки күңел ярасы төзәлми. Бигрәк тә әти-әнинең хәтерен калдырырга ярамый. Балалар, уйлап карагыз әле:

сезнең кайчан булса да әтиегез яки әниегезгә авыр сүз әйткәнегез юкмы? (Укучыларның җаваплары тыңлана. )

- Әйе, кайчагында үзебез дә уйламыйча, иң якын кешеләребезнең хәтерен калдырабыз. Сүзне әйтер алдыннан яхшылап уйларга кирәк. Уйламыйча әйтелгән сүз кешенең күңелен җәрәхәтләргә мөмкин. Сүз кешене сөендерә дә, көендерә дә, дәртләндерә һәм оялта да белә. «Әйт кенә тәмле сүз – иркәләр күпме күз» дигән әйтем бар. Безнең телебез матур сүзләргә бик бай. Бу сүзләрне искә төшерик, төркемнәрдә эшлибез.

**IV. Төркемнәрдә эш**

**1 нче бирем. "Тәмле, ягымлы" сүзләрне языгыз.**

**-** Тикшерәбез, кайсы төркем күбрәк язган.

( Исәнмесез, хәерле көн, сезгә саулык-сәламәтлек, бәхет-шатлыклар, иҗат уңышлары телим! Рәхим итегез, хуш киләсез, кадерлеләр! Афәрин, җаным-бәгърем, син нинди акыллы, гүзәл, искитмәле, тапкыр, зирәк, кыю, нәфис, сөйкемле, көчле, җитез, баш иям!)

- Балалар, бу сүзләрне ишетү һәркемгә рәхәт, шулай бит?

**2 нче бирем. Тел, сүз турында бирелгән мәкаль һәм әйтемнәрне язып бетерегез.**

1) ...мең бәладән коткара. (Бер яхшы сүз)
2) Сүзне...(үлчәп сөйлә).
3) Туры сүз ..., ялган сүз баш яра. ( таш яра)
4) Уйнап сөйләмә. ...(уйлап сөйлә)
5*)* Иң татлы тел – ... , анам сөйләп торган тел. (туган тел)

**3 нче бирем. Бирелгән сүзләрдән мәкаль төзегез.** (Сүзләр аерым битләрдә язылган)

1) Теле татлының- дусты күп.
2) Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел.
3) Әдәп башы — тел.

- Яхшы, укучылар. Афәрин! Менә күпме мәкаль һәм әйтемнәрне искә төшердек.

**IV. Йомгаклау.**

- Укучылар, без бүген нәрсә турында сөйләштек? Нинди нәтиҗә ясый алабыз? (Җаваплар тыңлана.)

- Тел - гомерлек юлдашыбыз. Кешенең бөтен тормышы тел белән бәйле. Туганнан алып соңгы сулышына кадәр тел һәм сүз кешенең аерылгысыз юлдашы. Җанга рәхәт, тәнгә сихәт бирүче матур сүзләрне дә без бары тик ана телебездә генә әйтәбез. Һәрберебез тәмле телле булыйк. Җылы сүзебезне, яхшы мөнәсәбәтебезне кызганмыйк. Юкка гына халкыбыз "Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен" димәгән. Кешелекле, ягымлы булыгыз! Сау булыгыз!

**Әдәбият**

1. В.С. Казыйханов. Әхлак дәресләре. Яр Чаллы, 1998.
2. К. Насыйри. Китаб-әт-тәрбия. Казан, 1992.
3. Н.Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. Казан, 1967

*Төзүче: Казан шәһәре Мәскәү районы КФУ каршындагы Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясенең беренче квалификация категорияле башлангыч сыйныф укытучысы Сипиева Алия Фирдүс кызы*

**Тема: Олыласаң олыны,**
**Олыларлар үзеңне.**

**Максат:** Укучыларның әбиләре белән очрашу, гаиләдә әбиләр тәрбиясенең әһәмиятен аңлату, балаларны аларга карата мәрхәмәтле, ихтирамлы булырга өйрәтү, әбиләрнең нәсихәтләрен тотарга кирәклеген төшендерү.
**Җиһазлау:** Магнитофон, әбиләр турында балаларның ясаган рәсемнәре, иншалары, "Әнкәй догалары" дискы, "Дәү әниемнең оста куллары", "Әбием пешергән тәмле ризыклар" күргәзмәләре, фотографияләр белән ясалган слайдлар, йомшак уенчык, яулыклар.
**Материаллар:** "Ачык дәрес" газеталары (04/2008, 05/2008, 09/2008, 11/2006), "Мәгариф" журналы (10/1998), "Раушан күзге" китабы, "Уку китабы" 2 класс, авторы С.Г. Вагыйзов.

**1. Кунакларны сәламләү.**

1) Бәйрәм кирәк әтигә,
Бәйрәм кирәк әнигә,
Бабай белән әбигә.
Безнең халык кунакчыл
Якты чырай, такта чәй, -дип,
Каршы ала кунакны.
2) Ата – бабай гадәтләрен
Без дә дәвам итәрбез.
Кунаклар килгән безгә
Зур хөрмәт бездән сезгә!

**2. Оештыру өлеше.**

Укытучы: Исәнмесез, балалар!
Матур үтсен көнебез!
Көләч булсын йөзебез!
Булыйк һәрчак әдәпле

Отыйк матур гадәтне.
Дөрес, матур утырыйк
Тырышып җавап бирик!

**3. Җыр тыңлау.**

Ташлама, әнкәй, ташлама
Мине изге догаңнан.
Ташласаң, изге догаңнан
Мин бәхетле булалмам.

- Бу җыр сезгә танышмы?
- Аны кем башкара?
- Җырчы мине нәрсәдән ташлама дип җырлый?
- Ә догаларны без күбрәк кемнән ишетәбез?
- Сез әбиләрегезгә ничек эндәшәсез?
- Ә алар кайда яшиләр? Башта әбиләре белән бергә яшәүчеләр кул күтәрсеннәр әле?
- Ә кемнәрнең әбиләре авылда яши?
- Кайберләрегезнең әле ике әбисе дә бар?
- Менә никадәр әбиләребез бар икән!

**4. Слайдлар (фотографияләр) белән эш.**

- Ә хәзер, әйдәгез, әбиләребез белән якыннанрак танышыйк әле.

*(Компьютер аша фотографияләр күрсәтелә бара, берничә укучы чыгып кыска гына инша укый)*

1. Галиәкбәрова А.
2. Хәйруллина А., Хәйруллина Р., Шарова А.
3. Борханова А.
4. Гайнетдинова А.

**5. Инсценировкалар.**

Укытучы: ә хәзер әбиләр белән оныклар арасында булырга мөмкин булган кайбер тормыш хәлләре белән танышыйк әле.

**1нче өзек.** Бер әби артыннан бер бала бара. Әбинең өч төенчеге бар. Берсе ялгыш төшеп кала.

- Әби, синең бер төенчегең төшеп калды.
- Юк, балам, үземдә.
- Әби, синең төенчегең өчәү иде, ә хәзер икәү генә.
- Әй, бала, бала, син математиканы яхшы үзләштергәнсең, тик бер кагыйдәне белмисең шул. Нинди кагыйдәне белми?

Өзекләр уку:

Бер малай сагыз чәйни-чәйни, юл аркылы чыгып бара. Янәшәдән генә кулына авыр сумка күтәргән әби дә атлый. Ә малай аны күрми дә. Ул малай урынында булсагыз, сез нәрсә эшләр идегез?

Раилә мавыгып рәсем ясый. Шулчак дәү әнисе: "Балам, күзлегемне генә табарга булыш әле!"-ди. Ә Раилә: "Аптыратма әле, шунда гынадыр", -дип җавап бирә. Ә дәү әнисе уфылдый-уфылдый һаман эзли. Раилә дөрес эшлиме?

Автобуста бер олы яшьтәге бабай басып тора. ә малай аны күргәч, тәрәзәгә таба борылып утыра. Сез дә шулай эшлисезме?

**2 нче өзек.** Әби белән бала.

-Әби, су бир әле.

-Мә, балам, су.

-Юк, су эчәсем килми икән, сөт бир!

-Хәзер, балам, хәзер сөт тә бирәм.

- Тәмсез ич бу. Суга сөт кушып бир.

-Мә, инде, алайса.

- Барыбер тәмсез, суны кире ал.

-Әй аллам, ничек итеп?

**Сораулар:** сөтне судан аерып буламы? бу бала нинди? киреләнү, юк-бар белән борчу яхшы гадәтме?

**3 нче өзек.** Әби белән малай.

-Йокы сәгате җитте, улым. Сүндер компьютерыңны, әйдә йокларга вакыт.

- Мин әле уйнап туймадым.

- Иртәгә уйнарсың.

- Әйттеләр бит инде сиңа, ишетмисеңме әллә?

**Сораулар:** кем хаклы? тыңламау, дорфа сөйләшү кешене бизиме?

Нәтиҗә чыгару: матур сөйләшергә, киреләнмәскә, тыңларга, булышырга кирәк.

**6. "Ялкын" журналыннан өзек уку.**

Укытучы: Укучылар, ашны-чәйне кайнарлап, безне мәктәптән көтеп торганда, оекбашлар бәйләп кидергәндә рәхәт икәнен барыбыз да беләбез. Әмма сез үскән саен әби картая бара. Ул инде әллә ни эшли дә алмый, әмма гомерлек гадәт буенча, тик тә тора алмый. Менә "Ялкын" журналына Эльвира исемле кыз язган хат белән танышыйк әле.

*Минем әбием бар. Карт та, чирле дә. Җитмәсә әйткәнне тыңламый. Һәр көн иртән әни белән өйне җыештырабыз, юабыз, чистартабыз. Ә ул кая тели, шунда утыра, пычрата, бөтен эшебезне юкка чыгара. Юри шулай эшли ул. Без чыгып киткәч, өйнең астын-өскә китерә. Әле генә урынына утыртасың, тагын торып китә.Мин аны карый –карый туйдым инде, әти белән әни дә туйдылар. "Ялкын" бер киңәш бир, әби белән нишләргә?*

Укытучы: Менә шундый хат җибәргән Эльвира. Бу хат журналда басылып чыккач, редакциягә йөзләгән хат килгән. Кайберләрен укырбыз да әле. Ә үзебез нинди киңәш бирер идек бу кызга?

*(Укучыларның фикерләре тыңланыла.)*

Укытучы: Газетага язылган хатларның кайберләрен укыйк әле. Менә Эльза Шаталова исемле кыз болай яза:

*Эльвира сезнең үегез шулкадәр матурмы? Карт әбиең шул матурлыкны бозып торамы? Их, син! Әзрәк уйлап карар идең... Сезгә рәхәт, җиңел булсын өчен шул көнгә төшкән бит ул. Әле генә урынына утыртасың, ул да түгел торып киткән була дисең. Менә сиңа мә! Бер җирдә генә утырып торырга, курчак яисә песи баласы түгел бит ул. Сиңа һәм синең кебек юньсезләргә киңәш бирә алмыйм, теләмим дә.*

Укытучы: Мин Эльвирага киңәшне тактадагы мәкаль белән бирер идем:

**Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне.**
**Ата-анасына игелек күрсәтмәгән,**
**Картайгач үзе дә күрмәс.**
**Пычрак ярасы китә,**
**Күңел ярасы китми.**

Укытучы: Әбиләр бит алар беркайчан да кычкырмыйлар. Ә менә ярамаган эшне алдан кисәтә беләләр. Минем әбиләрдән “Ашаганда аягыңны селкеп утырма, шайтан килер” кебек әйтемнәр ишеткәнем бар. Сезнең дә әбиләрегездән шундый әйтемнәр ишеткәнегез бардыр. Исегезгә төшерегез әле.

Укучыларның җаваплары мондый булырга мөмкин:

**Өйдә сызгырма, фәрештәләрне качырырсың.**
**Өйдә туп белән уйнама, яшен керер.**
**Авызыңны зур ачып иснәмә, шайтан керер.**
**Өстәлне кәгазь белән сөртмә, тавыш чыга.**
**Сыныгыңны ашап бетер, бәхетең кала.**

**7. Уен** . Дәү әни белән онык бер-берсенә матур сүзләр әйтешә. ( *Йомшак уенчык белән)*

**8. Монтаж**

1. “Дәү әни” С. Рәхмәтуллин шигыре.

2. Әбиемнең кулларын сыйпарга яратам мин. Җыерчыкланып, авыр эштән бирчәеп беткәннәр алар, кан тамырлары беленеп тора. Шулай да сине иркәләгәндә, алардан да йомшаграк куллар юктыр кебек.

3. Әбием! Нинди матур яңгырый бу сүз. “ Әни “ дигән сүз кебек үк күңелгә якын һәм кадерле. Алар булмаса, өйдә ямь калмый. Аларны рәнҗетмик, үзләрен генә ялгыз калдырмыйк.

4. Безнең дәү әниләребез бик тә уңганнар, бер дә тик торырга яратмыйлар. Алар бәйли дә беләләр, тәмле ризыклар пешерергә дә осталар. Менә бүген дә буш килмәгәннәр. Бик тәмле ризыклар пешереп алып килгәннәр.

5. Хөрмәтле дәү әниләр!

Сезгә булган безнең хөрмәтебез
Урын алсын йөрәк түрендә.
Шатлык һәм куаныч, зур бәхетләр
Юлдаш булсын сезгә гомергә.
Гомер юлларыгыз озын булсын,
Матур тормыш аны бизәсен.
Яшәү дәвере якты көннәр бирсен
Авырлыклар мәңге килмәсен.

*(“Әнкәй догалары” җыры яңгырый).*

*Төзүче: Казан шәһәре Мәскәү районы Ф.Г. Аитова исемендәге*
*12 нче гимназиянең югары квалификация категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Хуҗина Рузилә Тәлгать кызы*

**Тема: Музей сәгате.**

**Максат.** Халкыбызның тарихында зур роль уйнаган күренекле шәхесләр белән белән таныштыру; тарихыбызга, телебезгә, мәдәниятебезгә мәхәббәт тәрбияләү.
**Үткәрү урыны.** Гимназия музее.

*Телгә, тарихка, мәдәниятқә мәхәббәт тәрбияләүдә мәктәп музейларының роле әйтеп бетергесез зур роль уйный. Гимназиябез татар халкының мәгърифәтче кызы Ф.Г. Аитова исемен йөртә. Гимназиядә өч музей эшли. Шуларның берсе – Фатиха Аитова музее. Килгән кунаклар, укучылар еш була бу музейда. Стендларда Фатиха апа белән бер чорда яшәгән, аның белән бергә мәгърифәт нурлары тараткан игелекле ханымнарның портретлары да бар. Сүзебез замандашларының олы хөрмәтенә ирешкән зыялы ханым Зәйнәп Хәсәни турында. Бу ханымның язмышы миңа бик кадерле, якын, чөнки ул минем туган авылым белән бәйле. Аның әтисе Ногман хаҗи Әтнә районы Түбән Көек авылы кешесе. Дөрес, ул авылдан бик яшьли, 12 яшьләрдә чыгып китә, ләкин ул яшәгән йортны кечкенә чагымда бабамның миңа күрсәткәне, аның турында сөйләгәне бар. Авылның нәкъ уртасында, дәрәҗәле урында, мәчет янәшәсендә иде аларның йортлары.*

- Укучылар, замандашлары язуы буенча Г.Тукай хатын-кызлар белән әңгәмә корудан кача, ятсына торган була. Тик аның бер хатын-кыз белән кыенсынмыйча, үз иптәше кебек сөйләшүе билгеле. Кем икән бу ханым?

- Ул “Аң” журналының секретаре Зәйнәп Хәсәни, редактор Әхмәтгәрәй Хәсәнинең хатыны.

- Аның турынданиләр беләсез?

- Аның фотографиясе Ф.Г.Аитова музеенда стенда тора. Үз заманының алдынгы карашлы, белемле хатын-кызы.

- Зәйнәп - Ногман хаҗи кызы, ә Ногман абзый үзе тумышы белән Әтнә районы Түбән Көек авылыннан. Ул 12 яшендә авылыннан чыгып китә, казакъ җәйләүләрендә көтү көтеп, Оренбург, Казан байларына хезмәт итеп байлыкка ирешә, үз акчасына 13 мәчет, 7 мәдрәсә салдыра. Кызы Зәйнәп тугач, ул гувернантка яллый. Зәйнәп татар теле белән беррәттән рус, француз телендә сөйләшкәннәрне ишетеп үсә. Өйләрендәге китапханәдә татарча, төрекчә китаплар белән бергә рус һәм европалы халыкларның класссик әдәбияты үрнәкләрен күрергә мөмкин була. Үскәч, сәүдәгәр Сибгатулла хаҗи улы Әхмәтгәрәйгә кияүгә чыга. Ире Әхмәтгәрәй белемле кеше була. “Мөхәммәдия” мәдрәсәсендә белем ала, әтисе, укытучы яллап, өйдә дә укыта. Шуңа күрә ире дә төрек, гарәп, француз, рус телләрен яхшы белә. Әтисе аның сәүдәгәр булуын теләсә дә, егет әдәбиятка тартыла: үзен язучылык, тәрҗемә өлкәсендә сынап карый. “Гасыр” исемле нәшрият ачып, рус классик әдәбиятын татар телендә бастырып чыгаруга күп көч куя. 1910 нчы елда тәҗрибә туплау максатыннан Швейцария,Франция, Германия, Польшада булып кайта.

Менә шулай затлы тәрбия алган яшьләр матур гына үз тормышларын башлап җибәрәләр. Әдәбиятны яхшы белгән Зәйнәп иренә нәшрият эшләрендә ярдәм итә. Алар янына татарның күренекле, алдынгы яшьләре тартыла. Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Гобәйдуллин, Г.Коләхмәтов тәкъдиме белән ул “Аң” журналы чыгара башлый. Ә бу журналның җаваплы секретаре Зәйнәп Хәсәни була.

**“Фактлар” рубрикасы:** (материал Т. Биктимированың “Ил язмышын салып иңнәренә” дигән китабыннан алынды, Казан, 2006 ел)

1. Г.Тукай журнал өчен махсус шигырь яза, һәм ул шигырь 1912 нче елның 15 декабрендә беренче санның тышлык битендә басылып чыга.

Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән,
Эшкә дәгъвәт итте безне кемдер изге ним белән...

2. Г.Тукайның соңгы көннәре дә Хәсәниләр белән бәйле. Безнең көннәргә кадәр сакланган ике хаты да Хәсәниләргә. Аның берсе Зәйнәпкә аталган. 1913 ел, 28 март.” 8 нче санга бар кадәремне җибәрдем. Беренче корректурасын үземә күрсәтсәгез икән”, - ди.

3. Хәсәниләр белән беренче күрешү. Бу турыда олуг әдибебез Ф. Әмирхан язып калдыра. 1912 елда Хәсәниләр дачасына кунакка чакырылгач, Тукай Фатихка:”Юк, хатын-кыз булган җирдә минем өчен уңайлык булмый инде. Син үзең генә бар, анда мин бармам”, - дип баш тартмакчы була. “Ләкин шунысы гаҗәп, - дип яза Ф.Әмирхан, - барып җитеп, әвәлге чәй янында ук хуҗа хатын белән танышу мәҗбүрияте куелгач, ул моннан артык уңайсызланган шикелле күренмәде... Соңа таба инде ияләште вә сөйләшеп утыра башлады”.

Зәйнәп ханым җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Фатиха апа Аитова ачкан кызлар мәктәбендә (1909) һәм соңрак ачылган гимназиясендә (1916) ул попечительләр советы әгъзасы була. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, мөселман яралылары өчен махсус лазарет ачуны башлап йөрүчеләр дә алар икесе була. Лазарет өчен кирәкле әйберләрне дә Хәсәниләр йортында тегәләр.

1917 елда Бөтенрәсәй мөселман хатын-кызлары корылтаен оештыруда башлап йөргән Хәдичә Ямашева-Таначевага (Хөсәен Ямашевның сеңлесе) иң зур ярдәмне күрсәтүчеләрнең берсе дә ул. Корылтайда төшкән фотода Зәйнәп апа Фатиха Аитова белән янәшә утырган.

Октябрь революциясеннән соң татар халкына хезмәт куйган игелекле гаиләнең тормышы җимерелә. Ире Әхмәтгәрәйне 1931 нче елда кулга алалар (сәбәбе – эмиграциядәге язучы Гаяз Исхакый белән хат алышкан, аның әсәрләрен бастырган). 1933 елда Әхмәтгәрәйнең “Мине сөргенгә җибәрәләр, килә алырсыңмы?”- дигән хатын ала. Җавабы -”Дөньяның кайсы почмагында сиңа урын бирсәләр, мин шунда синең яныңа барам”.

**Фаҗигале язмышлар. Фактлар рубрикасы:**

1. Зәйнәп апа Фатиха апа белән гомер буе дус була. Фатиха апа авырып, 16 ай буе түшәктә ятканда, аның янына соңгы көннәренә кадәр килеп йөри.

2.“Халык дошманы”ның хәлен белергә кем килә? Беркем дә! Хәтта аның туган-тумачалары да күрмәмешкә салышалар. Минем үз башымнан узган хәл бу: этине “алгач”, аның иң якын туганнары да бездән ераклаштылар... Гали Рәхим янына исә бердәнбер Зәйнәп апа Хәсәни (... әле 1968 елда гына дөньядан китте, мин аның янында ике тапкыр булып, бик күп истәлек язып калган идем) килеп китә. Ул Гали Рәхимгә ризыклар, иреннән калган (ире Әхмәтгәрәй 1934 елда ук Сталин корбаны булган) кием-салым алып килгәли.” (Мөхәммәт Мәһдиев” Каһәрләнгән язмыш” мәкаләсеннән)

3.Красноярск краена сөргенгә җибәрелгән Хәдичә Ямашева шунда үлгәч, Хәдичә апаның ире Вәлидхан абый Зәйнәп апага мөрәҗәгать иткән. «Зәйнәп, — дип яза ул, — Син безнең дустыбыз. Мондый зур үтенеч белән бары зур дусларга гына мөрәҗәгать итәргә була». Хәдичәнең каберенә утыртырга гарәп язулы таш сорый ул, һәм Зәйнәп ханым җибәрә.

Туган телен камил белгән, шунлыктан башка телләрне дә үзләштерә алган Зәйнәп апаның туган йорты Нәриман һәм Фатих Кәрим урамы чатында урнашкан, әле дә бар. Ә хәзер, укучылар, сезнең игътибарга викторина сораулары тәкъдим итәм.

**Викторина сораулары:**

1.“Аң” журналының беренче саны кайчан чыга?

2. Кем журнал өчен махсус шигырь яза?

3. Г. Тукайның Хәсәниләр белән беренче очрашу тарихын кем истәлекләреннән беләбез?

4. Хәсәниләр белән очрашуга Тукай кем белән бара?

5. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Зәйнәп ханым кем белән берлектә мөселман яралылары өчен лазарет ачуны башлап йөри?

6. Зәйнәп апаның ире кем исемле була?

7. Зәйнәп апа янында булып, аның истәлекләрен язып алган язучыны атагыз.

Тукай белән аралашырлык зәвыклы, әдәбият дөньясында, сәясәттә мәгълүматлы игелекле ханым Зәйнәп Хәсәни язмышы үзе бер тарих. “Без -тарихта эзлебез”, - дип сөекле шагыйребез дөрес әйткән. Без, укучылар, сезнең белән зыялылар кебек аралашырга, сөйләшә белергә өйрәнергә тиешбез. Ә аның өчен һәркемнең белемле, эрудицияле, креатив фикер йөртә белүе дә мөһим. Белемле кеше беркайчан да югалмас, үткәнен белгәннең киләчәге дә өметле.

Музеебызда татар халкының тарихи сәхифәләренә мөрәҗәгать итүне алга таба да дәвам итәрбез.

**Әдәбият**

1.Биктимирова Т.Ә. Ил язмышын салып иңнәренә. - Казан:”Алма-Лит”, 2006. – 239 б.

2.Мөхәммәт Мәһдиев ”Каһәрләнгән язмыш” http://beznenmiras.ru/mohammat-mahgiev-kaharlangan-yazmysh/

*Төзеде: Казан шәһәре Мәскәү район КФУ каршындагы Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясенең югары квалификация категорияле башлангыч сыйныф укытучысы Җәләлетдинова Гөлназ Әхәт кызы*

**Тема: Туган телем – газиз телем!**

**Максат:** Язучыларның тел турында әйткән шигырьләре, әйткән сүзләре белән таныштыру.

Туган телгә мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлау**: Г.Тукай портреты, карточкалар, яфрак рәсемнәре артына язылган сораулар, җыр көйләре.

Мәкальләр: “Халкын белмәгән-халыксыз, нәселен белмәгән-нәселсез,
телен белмәгән-телсез”.
“Уйның күрке тел, телнең күрке сүз”.

Без - татарлар, туган телебез – татар теле.

Татар теле... Тугач та иң газиз кешеңнән ишетә башлаган, күп гасырлык тарихы булган, Каюм Насыйрилар, Тукайлар нигез салган, 7 миллион халык сөйләшкән, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, бүгенге көндә җитлеккән, камилләшкән, теләсә нинди катлаулы фәнне өйрәтергә мөмкинлеге булган, Моабитның таш диварлары эчендә дә тынмыйча, аның калын стеналарын тишеп чыгып, бөтен дөньяга яңгыраган, утларга-суларга салсалар да, чукындырсалар да, ассалар – киссәләр дә исән калган, иң-иң авыр кимсетүләргә дә түзгән, сынмаган-сыгылмаган, баш имәгән горур татар теле! Бүгенге класс сәгатебезне сиңа багышлыйбыз.

Кемнәр генә сиңа сокланмаган һәм мактау җырламаган?! Кемнәр генә синең ярдәмеңдә дөньяны танып белмәгән һәм үзенең уй-хисләрен башкаларга сөйләмәгән?!

1 укучы: И минем җандай кадерлем,
И җылы, тере телем!
Кайгылар теле түгел син,
Шатлыгым теле бүген.

Тик синең ярдәм белән мин,
Тик синең сүзләр белән
Уйларын йөрәккәемнең
Дөньяга әйтә беләм.

Туган тел төшенчәсенә зур мәгънә салынган. Ул Ватан, туган җир, ата-ана сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә торучы бөек, изге һәм кадерле сүз. Ул телне шуңа күрә туган тел дип атыйлар да. Ул телгә баланы аның иң газиз, иң якын кешесе-анасы өйрәтә. Шул телдә аңа бишек җырларын җырлый, иркәли, юата. Шуңа күрә аны халык ана теле дип атый.

*“Туган тел” җыры (Г.Тукай сүзләре, халык көе) башкарыла.*

Әйе, Г.Тукай телебез турында әнә шулай матур итеп әйтеп биргән. Телне “матур тел”, “әткәм-әнкәм теле” дип атаган. Без сезнең белән туган тел турында инша яздык. Шул эшләр арасыннан берничәсен тыңлап үтик әле.

*(Фидаил, Айгөл, Русланның иншалары тыңлана).*

Туган тел. Һәркем өчен дә газиз сүз бу. Чөнки иң кадерле, бернәрсә белән дә алыштырылмый торган “әти”, “әни”, “бабай”, “әби” сүзләрен башлап туган телдә әйтәбез. Тугач та бу телне балам, кызым, улым дигән сүзләрне дөньяга сине тудыручы, яратучы, багучы газиз әнкәңнән ишетәсең. Шул турыда шагыйрьләребез берсеннән-берсе матур шигырьләр иҗат иткәннәр.

2 укучы: Дөньяда иң-иң матур ил-
Ул минем туган илем.
Дөньяда иң-иң матур тел-
Ул минем туган телем.

“Балам” диеп туган телдә,
Эндәшә миңа әнкәм.
“Әнием!” дип әнкәемә,
Мин туган телдә әйтәм.

Туган, үскән илнең яктылыгын, Ватанның газизлеген тоярга да безгә әнә шул туган тел ярдәм итә. Милли шагыйрьләребезнең җанга якын шигырьләрен укып рухланабыз. Менә бүген дә без аларның туган телгә-татар теленә булган җылы хисләре белән тулы шигырьләрен ишетәбез.

3 укучы: Туган телемдә сөйләшеп
Яшим мин туган илдә.
“Туган ил” дигән сүзне дә
Әйтәм мин туган телдә.

Иң изге хисләремне мин
Туган телдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин, яратам.

Безнең телебез –матур, күркәм тел. Әгәр милләтнең теле кулланылмый икән, ул юкка чыга. Моның өчен сугыш та, кан кою да кирәкми. Телен бетердең исә, үз халкыңның әдәбияты да, гореф-гадәте дә бетә. Шулай итеп, милләт тә үлемгә дучар була. Безнең телебез дә әле шундый аяныч хәлгә төшеп бара иде. Тел саклансын өчен, ул тулы хокуклы аралашу чарасы булырга, тормышның күп өлкәләрендә кулланылырга тиеш.

Безнең бурыч - телебезне яхшы белү, аны ярату.Тел өчен көрәш-милләт өчен көрәш. Әгәр телебезне дәүләт яклый икән, аны дәүләт теле итеп кабул итә икән, димәк, без бар, без яшибез.

7 укучы: Үз телеңне сөймәгәндә,
Ярты ул алган белем
Канатсыз коштай буласың,
Белмәсәң ана телен.

Әни кебек газиз күреп
“Туган тел” дип җан атып
Яшик әле дөньясында
Татар телен яратып.

*(“Әйлән-бәйлән” җыры башкалыла)*

Мин сезгә мәкальнең башын әйтәм, сез дәвам итегез.

1. *Сөйдергән дә тел,(биздергән дә тел)*
2. *Телең озын булса, (гомерең кыска булыр)*
3. *Кылыч ярасы бетәр, (тел ярасы бетмәс)*
4. *Телнең зиннәте-(туры сүз)*
5. *Тик тормаган тел, (кунак чакыра)*
6. *Теле барның, (юлы бар)*

Һәр мәкальнең мәгънәсе буенча фикер алышу.

Ә хәзер, әйдәгез, уен уйнап алыйк әле.Ул уен “Син туган республикаңны һәм телеңне яхшы беләсеңме?” дип атала. Тактага беркетелгән сары яфраклар артына республикабыз турында, ә яшел яфраклар артына туган телебезгә карата сораулар язылган.

Сораулар:

1. Синең республикаң нинди республика дип атала?
2. Татарстан Республикасының башкаласы нинди шәһәр?
3. Республиканың Президенты кем?
4. Татарстанның гербына нәрсә ясалган?
5. Казанга ничә ел булды? Ничәнче елда?

1.Билгеле бер тәртиптә урнашкан хәрефләр җыелмасы?
2.Татар телендә нинди сузык авазлар бар?
3. Капма-каршы мәгънәдәге сүзләр?
4. Г Тукайның алтын тарагы кемдә?
5. “Сертотмас үрдәк” әкиятен кем язган?

8 укучы: Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле, затлы тел.

Татарчасы туган тел,
Безгә газиз булган тел.
Атаң-анаң, әби-бабай
Сине сөя торган тел.

Тел кешене дус итә
Бер-беренә беркетә.
Бел, балам, син рус телен
Һәм онытма үз телең!

*Мәзәкләр тыңланыла:*

Бер егет армиядә хезмәт итеп кайткан. Үзе гел русча гына сөйләшеп кылана икән.

Бер көнне күрше егете белән мунча керергә киткәннәр. Күрше егете мунча ташына чүмеч тутырып эссе салып җибәргән. "Довольно, довольно!"- ди солдат. Күрше егете аңламаганга салышып тагын ике чүмеч тондыра. Солдат кызуга чыдый алмый, "Җитте дип әйттем бит инде мин сиңа!" –дип мунчадан чыгып йөгерә.

Ишек алдында бер әби сөйләнә. Күреп торам-татар әбисе. "Әйдә, әйдә, пайдум дамуй, пайдум дамуй",- ди. Кем белән сөйләшә икән дип борылып карасам, эт белән икән. Көлмичә түзә алмадым. "Нәрсә әби, этегез дә русча гына сөйләшә белә мәллә?" – дидем. Әби аптырагач, үзе дә рәхәтләнеп көлде.

Бер хат: "Альфинур! Мин сиңа обещать итәм. Бер вакыт некому сүз әйттермәм. Үзем бу случайны гомергә онытырмын. Бу миңа гомерлек урок булсын. әгәр минем обещаниега ышансаң, мин синең ышанычыңны оправдать итү өчен все сделаю. Кирәк булса гомеремне опасность астына куярга да риза".

Йомгаклау сүзләре:

Туган тел – иң татлы тел,
Туган тел – иң тәмле тел.
Тәмле дип, телең йотма-
Туган телне онытма!

Халкым бер тумыш көндә дә
Тукаен онытмады.
Без – "Туган тел"дән туганнар,
Без – Тукай оныклары.

*Төзүче: Казан шәһәре Мәскәү районы Г.Ибраһимов исемендәге*
*17 нче татар гимназиясенең югары квалификация категорияле*
*туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Абдуллина Рамилә Әгъзам кызы*

**Тема: "Ач, шигърият, серләреңне".**

**Максат:** 1) Туган телгә, татар шигъриятенә мәхәббәт хисе тәрбияләү;
2) татар әдәбияты буенча белемнәрне ныгыту;
3) сәнгатьле сөйләм һәм тыңлый белү күнекмәләрен ныгыту;

**Җиһазлау:** 1) Сәхнәнең арткы өлешендә "**Ач, шигърият, серләреңне..** " сүзләре һәм ачылган китап, каурый каләм рәсемнәре беркетелә яки экранга презентация форматында чыгарыла.
2) Жюри өчен критерийлар язылган бәяләү битләре, беркетмә.
3) Курай музыкасы.
4) Бүләккә китаплар.

**Үткәрү формасы**: әдәби кичә - шигырь бәйгесе.

**Бәйгенең барышы:**

*(салмак кына курай тавышы яңгырый)*

**Алып баручы:** Исәнмесез хөрмәтле шигырь сөючеләр, кадерле катнашучылар һәм бәйгебез кунаклары! Без сезне шигърият бакчасында сәламнәргә шатбыз!

Сезнең кайчан да булса, тезелешеп очкан кыр казларына карап сокланганыгыз, шулар биеклегенә күтәрелергә теләп ашкынганыгыз бармы икән?.. Әгәр булса – сез шагыйрь!

Тезелешеп очкан кошлар зәңгәр күккә ак канатлары белән шигырь язып китәләр. Язларын алар үз шигырь-җырларын җиргә чәчәк итеп сибәләр. Хәтерләгәнегез бардыр: җылы яктан беренче кошлар кайта башлауга җирдә чәчәкләр күренә башлый. Ул чәчәкләрнең кайберәүләре кошлар йөрәгеннән тау битенә, кайберәүләре карурманнарның яшерен яланнарына төшеп кала. Алсу нурларын тирә-юньгә балкытып, һәр үткән болытка яулык болгап калучы гүзәл тау чәчәге, һичшиксез, йөрәкнең шатлыктан мөлдерәп тулуыннан тугандыр. Ничек кенә булмасын, кеше җанына һәрвакыт гүзәллек, матурлык кирәк. Менә шушы кабатланмас гүзәллек өчен ул җиде диңгез кичеп, җитмеш тауны үтеп, югарыга күтәрелергә әзер. Кешене үзе тапкан матурлык кына сокландыра, үзе ачкан серләр генә гаҗәпләндерә. Ә шагыйрь кеше һәркөнне берәр яңалык, берәр матурлык ачучы.

Бүгенге кичәдә яңгыраячак шигырьләрнең һәрберсенең үз төсе, үз моңы, үз матурлыгы. Аларның күбесен укучылар үзләре, күңелләренә хуш килерлек

итеп, сайлап алып ятладылар. Бәйгедә 1 нче сыйныфтан алып 11нче сыйныфка кадәр булган укучылар катнашачак.

Бәйге булгач, җиңүчеләрне билгеләргә кирәк була. Ә моның өчен безгә жюри әгъзалары ярдәм итәчәк. *(Таныштыру)*

Хөрмәтле жюри әгъзалары!
Үлчәвегез төгәл булсын
Бу сынаулы көрәштә,
Гадел була күрегез,
Дөрес бәя бирегез,
Теләгебез шул Сезгә!

Әйдәгез, башта сүзне 1 нче сыйныф укучыларына бирик. Алар бүгенге кичәбезне бөек шагыйребез Г. Тукайның нәниләр өчен язган шигырьләре белән башлап җибәрәләр.

*Түбәндәге шигырьләр яңгырый:*
*Г. Тукай. "Бәйрәм бүген"*
*"Сабыйга"*
*"Бала белән Күбәләк"*
*"Бәхетле бала"*

**Алып баручы**: Башлангыч сыйныф укучыларының иң яраткан шагыйрьләре Г.Гыйльманов белән Ш.Галиев икән.

Бәйгебезне әниләр турында шигырь белән дәвам итәбез:
Әни безне тудырган,
Әни безне үстергән,
Әни сөте гомерлеккә
Җитә торган көч биргән.
*(Г.Гыйльманов "Үлмә генә, әнием" шигыре яңгырый)*

**Алып баручы**: Шагыйрьләр табигатьтәге һәр мизгелдән, тормыштагы һәр вакыйгадан шигырь тудыралар. Тыңлап карыйк әле!

*Г.Гыйльманов. "Уңган суык"*
*Г.Гыйльманов. "Суык бабай күчергән"*
*Ш.Галиев."Каты салкын"*
*Ш.Галиев. "Һай, тешем"*
*Йолдыз Шәрапова "Матур ялган"*
*Ленар Шәех "Физкультура дәресендә"*

**Алып баручы**: Башлангыч сыйныф укучыларының чыгышы шуның белән тәмам. Алдагы сыйныф укучыларының чыгышына күчкәнче, тамашачылар игътибарына бер уен тәкъдим итәбез. Бу уен "Танып бел" дип атала. Сезгә чәчмә һәм тезмә әсәрләрдән өзекләр тәкъдим ителә, ә сез аларның авторын һәм әсәрнең

исемен әйтергә тиеш буласыз. Һәрбер дөрес җавап өчен сезгә “йолдызчык”лар таратыла. Кем иң күп “йолдызчык” җыя, шул җиңүче була.

*Өзекләр:*

1. Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре
Карт бабайларның моны күрсәң, бөтен саулэтләре
Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе:
Ах!-дисең,без ник болай соң?
Без дә хакның бәндәсе.(Г.Тукай “Шүрәле”)

2. Әни мин уйнаганда
Көчек күрдем урамда.
Әни, ул туңган иде,
Урамда кунган иде,
Әни, салкын яңгыр астында
Ул бик күшеккән иде.
Ул бик ачыккан иде.
Ул бик талчыккан иде.(Р.Миннуллин”Әни,мин көчек күрдем”)

3. Өмет бар ки, тәңре сиңа бирер мөлкәт,
Кодрәт белән насыйб итәр бик күп нигъмәт,
Барлык кардәшләрен кылыр сиңа хөрмәт,-
Унбере дә сиңа хезмәт итәр имди. (К.Гали “Кыйссаи Йосыф”)

4. Юлбасарлар таптый җиребезне
Ватан сугышына мин китәм.
Менә - балам, син әнкәсе аның,
Балабызны тотып ант итәм! (Ф.Кәрим”Ант”)

5. -Әй, ханиям, ханиям,
Тугрыңа кунган Төкле Аяк
Тугыз йортка дан булса,
Синең белән дан булды,
Кичә син дә чал булдың
Бүген ул да чал булды. (“Идегәй”)

6. Ул бер үзе сугышты
Унбиш укчыга каршы.
Чигенмәде, тик таңда
Яраланды кул башы. (М.Җәлил.”Кызыл ромашка”)

7. Кайдан килеп, кайда баруы һичкемгә мәгълүм булмаган бер үткенче мосафир бабай бездә хәл җыярга туктаган вакытта, үлеп калды. Ул бик карт иде. Бөтенләй ялгыз иде. Шуның өчен кызганып яшь түгүче булмады. Менә шул бабай үләр алдыннан үзенә чакырып алды да, миңа бер уч тутырып орлыклар бирде. (Г.Ибраһимов “Кызыл чәчәкләр”)

*(Нәтиҗә чыгарыла)*

**Алып баручы**: Р. Миннуллин – балалар психологиясен тирән белүче шагыйрьләрнең берсе. 5 нче сыйныф укучыларының аның шигырьләрен сайлап алуы очраклы хәл түгел. Дәресләрдә шагыйрь иҗатын алар җентекләп өйрәнәләр. Моны алар аны хәзер үзләре расларлар.

*Р.Миннуллин.”Балачак бәйрәме”*

*“Бутаган”*

*“Энекәш кирәк миңа”*

*“Сабантуй”*

**Алып баручы**: Укучылар, сез ничек уйлыйсыз, балалар күбрәк кем булырга хыялланалар? Әлбәттә, космонавт. Ә Ш. Галиев моның турында нәрсә уйлый икән? Тыңлап карыйк әле.

*Ш.Галиев “Космонавт булабыз дип”*

**Алып баручы**: Безнең 6-7 нче сыйныф укучылары Ф. Яруллинны яраталар икән. Чыннан да, һәрбер кеше Ф.Яруллин поэзиясендә үзенә якын булган хисләр һәм вакыйгалар белән очраша.

*Ф.Яруллин “Әллә кече, әллә зур”*

*“Суык төсе”*

*“Өйдә калам”*

**Алып баручы**: Шигъри бәйләмнең бер тәлгәшен Муса Җәлил шигырләре тәшкил итә. Алар “Моабит дәфтәрләре” циклыннан алынган. Әйдәгез, тыңлап үтик.

*М.Җәлил “Ышанма”, “Ана бәйрәме”(өзек) яңгырый.*

**Алып баручы**: Бай тарихлы, бик борынгы, шул ук вакытта бик яшь тә ул безнең башкалабыз Казан. Аның турындагы шигырьләрне дә укучылар читләтеп үтмәделәр.

*М.Хөсәен “Яңа Казан”*

*М.Кәрим “Казан”*

**Алып баручы**: Туган Илкәй...

Бу исемдә язгы таңнар,
Бу исемдә җанга рәхәт татлы моң бар.
Бу исемдә киләчәгем, бәхетем минем
Мәңге, яшә, мәңге яшә, и Туган илем!

Туган як темасын бер генә шагыйрь дә ят итми. Сибгат Хәким иҗатында ул аерым бер урын алып тора.

*С.Хәким “Татарстан минем республикам”... шигыре яңгырый.*

**Алып баручы**: Урта сыйныф укучылары чыгышларыннан соң уйнап алыйк. Бу юлы инде сезгә әдипләрне портретлары буенча танып исемнәрен атарга кирәк. *(Ш. Галиев, И. Юзиев, Р. Харис, Н. Фәттах, Р. Фәйзуллин, Р. Миннуллин, К. Гали, Ф. Кәрим, М.Җәлил портретлары күрсәтелә, нәтиҗәләр ясала)*

**Алып баручы**:

Төнемне көн иттең,
Көнемне төн иттең.
Яндырдың, көл иттең.

Ничек уйлыйсыз,бу шигырь юллары нәрсә турында? Әйе, дөрес, иң гүзәл мәхәббәт хисе турында. Бу темага мөрәҗәгать итмәгән каләм иясе юктыр. Ләкин һәркем аны үзенчә аңлый, үзенчә кичерә. Ә Фәйрүзә Мөслимова сөю турында нинди фикердә икән? Сүз югары сыйныф укучыларына бирелә.

*Ф.Мөслимова “Син түгел”*
*”Язар идем”*
*Р.Гаташ. “Роль биргәннәр”шигырьләре укыла.*

**Алып баручы**:

Шигырьләр иҗат итүе дә, тормышы да батырлык үрнәге булган Ф.Яруллинның берничә шигырен тыңлап үтик.

*Ф.Яруллин “Бер сүз эзлим”*
*“Ак чәчәк”*
*“Җыр калдырыйк”*

Әгәр бүгенге кичәдә Хәсән Туфан шигырьләре яңгырамаса, бәйрәмебез тулы булмас иде. Туфан – күкнең зәңгәрлегенә, җирнең җылылыгына, кешенең олылыгына сокланып туймаган шагыйрь. Шуңа күрә кичәбезне Туфан шигырьләре белән тәмамлыйбыз.

*(Чыгышлар тыңланыла)*

**Алып баручы**:

Кемнәр сөйми икән шигъриятне,
Шигъриятне һәркем ярата.
Шигырь бит ул якты кояш кебек
Иҗат нурын илгә тарата.
Мин дә гашыйк гүзәл шигърияткә
Яратамын сабый чагымнан.
Бүген дә әле Тукай иҗатыннан
Ялкын алып балкып кабынам.

Хәзер сүзне жюри әгъзаларына бирәбез. *(Чыгыш тыңланыла. Җиңүчеләргә бүләкләр таратыла).*

**Алып баручы**: Чыннан да, шигърият дигән серле жанр беркемне дә битараф калдырмый, җанны эретә, күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтү сәләтенә ия. Кем белә, бәлки, сезнең арагызда киләчәктә шигърият күгендә якты йолдыз булып янарлык яшь талантлар да бардыр.

Бер йөрәккә барып тоташалар
Татар каны аккан тамырлар.

Киләчәкнең Тукайлары, Галимҗаннары
Шушы гимназиядә белем алырлар.
Амин, шулай булсын, дип югары нотада бәйрәмебезне тәмамлыйбыз.
Кичәбез тәмам, игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

*Төзүче: Казан шәһәре Киров районы 4 нче гимназия-интернатның*
*югары квалификация категорияле*
*туган тел (татар теле) һәм әдәбияты укытучысы*
*Садыйкова Рәмзия Габидулла кызы*

**Сыйныф сәгате (5-8 нче сыйныфлар өчен)**

**Тема: Әдәплелеккә өйрәнү юллары.**

**Максат:** ”Әдәп“, ”әдәплелек“ сүзләренең мәгънәсенә төшендерү, тәрбияле-әдәпле булырга чакыру.
**Җиһазлау***:* Каюм Насыйриның ”Китаб-әт-Тәрбия“ китабы, Сәйф Сараиның ” Гөлестан-бит-төрки“ хикәяте, ”Татар теленең аңлатмалы“ сүзлеге”.

## Сыйныф сәгате барышы

Эпиграф: Әдәп башы – гадәт.

1. Оештыру өлеше. Исәнләшү.

**Укытучы**. Исәнмесез, кадерле укучылар. Бүген әдәплелек турында сөйләшергә җыелдык. Әдәп нәрсә соң ул? Ул нинди мәгънә аңлата? *(Укучылар җавабы).*
*Слайд №1.* Әдәп–үзеңне тота белү кагыйдәләре.
Әдәп–яхшы гадәт, йола.
Әдәплелек –үзеңне тота белү сыйфаты.
**Укытучы**. Ә хәзер, әйдәгез, бер әкиятнең сәхнәләштерелгән өзеген карап китик әле.

Катнашалар: падишаһ (патша булып киенгән), остаз (әти, укытучы), малай (укучы, шәкерт).
**Падишаһ.** Әссәләмәгаләйкүм, хөрмәтле остаз! Хәлләрегез ничек? Исәнлек-саулыктамы?
**Остаз**. Аллага шөкер. Сезнең хәер-догада.
**Падишаһ**. Остаз, сезгә бер үтенечем бар иде. Сезгә улымны укытмакка һәм тәрбия кылмакка бирергә тиеш идем. Белемле дә, әдәпле дә итәргә тырышуым иде. Риза булып алмассызмы икән?

**Остаз**. Калдырырсыз, падишаһым. Тик ни дә була калса, миңа үпкәләмәссез. Мин тырышып тәрбия кылырмын.

*(Малай, укып кайткач, өендә этисенә әйтә).*

**Малай**. Әти, остаз миңа тупаслык кыла, кыйный.

**Әтисе.** Ничек кыйный? Нәрсә өчен кыйный! Булмас. Кеше баласын кыйнау тиеш түгелдер. Кара, тәнеңне кара яндырып бетергән бит бу юньсез. Ник алай итте икән, сөйләшим әле үзе белән. *(Падишаһ остаз янына бара).*

**Падишаһ**. Исәнлек-саулыктамы, остаз?

**Остаз.** Яхшы гына хәлләрдә?

**Падишаһ**. Әй остаз, кара халык, гавам балаларын бу кадәр җәфа кылмыйсың икән, безнең балабызга бу кадәр җәфа вә җәбер күрсәтәсең, ни сәбәптер?

**Остаз.** Олуг кешеләр, байларның балаларын тәрбия вә тәртип бирүдә кара халык балаларыннан катырак булырга кирәк, бай дип иркенлек кылырга ярамый.

**Падишаһ**. Остаз, тәрбия барлык кешегә дә бердер бит.

**Остаз.** Әй, падишаһ, тәрбия бердер, ләкин зирәклек, сәләтлелек башкадыр. Кара халык балалары күбрәк бай балаларыннан өлгеррәк, зирәгрәк буладыр. Шуңа күрә бай балаларына артыграк иҗтиһад-тырышлык сарыф кылмак кирәк, чөнки алар бик иркә булалар.

**Укытучы**. Укучылар, Каюм Насыйри бу тәрбияне ни өчен язган, дип уйлыйсыз? Ишеткәнегез бар микән, татар халкында бер гыйбарә бар: ”Килен, сиңа әйтәм, кызым, син тыңла“. Бу караган өзектә шушы гыйбарәгә тәңгәл килә торган тагын нәрсә бар?

**Укучы**. Остаз бай яисә падишаһ балаларына каты тәрбия кылып, кыйнап укыта, чөнки аларның күңелләре болай да иркенлектә яши. Ә гади кеше балаларының күңеле чиста, алар һәрвакыт чама хисе белән яши беләләр. Әгәр укымасаң, тырышмасаң, безгә дә кыен эләгә дип тырышып укыган гади халык балалары болар.

**Укучы**. Элек менә шулай башкаларга карап тырышканнар, укыганнар.

**Укытучы**. Сез ничек уйлыйсыз: ә менә тәрбияне дә башкаларның яхшы тәрбиясенә генә карап алып буламы икән?

**Укучы**. Тәрбиясез кешеләргә карап та үзеңне тәрбияләп була, дип уйлыйм мин. Чөнки алардан тәрбиясезлекне күрәсең дә, үзеңне шул урынга куеп карыйсың һәм болай булсаң, начар булыр дигән нәтиҗәне чыгарып, үзеңне яхшы якка үзгәртәсең.

**Укытучы**. Хәзер, укучылар 14 нче йөздә яшәгән Сәиф Сараиның ”Гөлстан биттөрки“ хикәятеннән ”Әдәпне әдәпсездән өйрәндем“ дигән бер өзек карап китик.

*(” Гөлестан-бит-төрки“дән өзек күрсәтелә).*

**Ир кеше**. Локман Хәким син әдәпне кемнән өйрәндең?

**Локман Хәким**. Мин әдәпне әдәпсез кешеләргә карап өйрәндем.

**Ир кеше**. Булмаганны! Ничек алай инде ул? Әдәпсез, тәрбиясез кешедән әдәп өйрәнеп була димени? Аларның үзләрен тәрбия итәргә кирәк бит.
**Локман Хәким**. Әйе, сөйләгән сүзем рас. Бактым аларның эш-гамәлләренә. Аларның кайсы хәрәкәтләре миңа хуш килмәде, мин шулардан ихтираз кылдым, ягъни начар эшләрдән тыелдым.
**Ир кеше**. Әй, Локман хәзрәт, димәк, әдәпсез, тәрбиясезләрне шундый юл белән генә өйрәтмәк кирәк алайса.
**Локман Хәким**. Минем сүземдә һич шик юк. Адәм балаларына шушы кагыйдәне өйрәтмәк кирәктер. Бу – бик файдалы бер киңәштер.
**Укытучы**. Әйе, укучылар, мондый тәрбия бирә торган хикәятләр Каюм Насыйри хикәятләрендә дә бар. Без бүген әдәплелеккә өйрәнү юллары белән танышабыз. Каюм Насыйриның әдәплелеккә өйрәтә торган нинди хикәятләре белән таныштыгыз? Ягез, таныштырып китегез.
**Укучы**. Мин Каюм Насыйриның 60 нчы тәрбиясен бик яратып укыдым.

*Слайд 1.* Әй, угыл, белеп тор: сиңа изгелек кылган кешегә яманлык кылма, вә сиңа нигъмәт биргән кешене хурлама вә кимсетү белән карама. Залимлыгы күп булган кеше тиз һәлак буладыр вә һәм дошманнары күп буладыр. Залимлыктан сакланмак кирәк.
**Укытучы**. Бу сүзләр, димәк, безне нинди әдәпкә өйрәтә?
**Укучы**. Яхшылык кылган, эшләгән кешегә начарлык эшләмәскә өйрәтә. Әгәр аның бу киңәшен тотсак, димәк, бу – үзе бер әдәптер.
**Укучы**. Мин 67 нче тәрбиядә әдәпкә өйрәнү юлын күрәм.

*Слайд 2.* Ялганчылар белән танылган кеше һәрникадәр тугры сүз әйтсә дә, шикле. Бер мәртәбә ялганчылыгың сизелсә, һич сүзеңә дә ышанмас булырлар...
**Укучы**. Хәзерге вакытта ихтирам олы кешеләргә бик тә кимеде. Автобусларда да олы кешеләргә урын бирмибез, күрмәмешкә салышабыз. Кечеләрне дә таптап изәргә әзер торучылар бар. Каюм Насыйриның 82 нче тәрбиясендә олыларга, кечеләргә рәхим-шәфкатьле булырга һәм әдәпкә өйрәткән юллары белән танышыйк.

*Слайд №3.* Әй угыл, “Акыллы дошман надан дустан яхшырак”. Ахмак вә надан адәм дуслыкка вә дошманлыкка һәм ярамас. Вә һөнәрсез кеше дуслыкка ярамас. Саклан шул кешедән ки, үзе бернәрсә белмәс, үзен галим вә белекле санар. Бер эшне бер мәртәбә эшләп тугры килмәсә, икенче мәртәбә ул эшкә тотынма, вә кулыңнан килмәгән эшкә тотынма.
**Укытучы**. Укучылар, әйе, бүгенге яшьләрнең күңелләрендә изгелек дигән нәрсә кимеде. Кеше хәлен аңлау өчен, үзеңне шул урынга куеп карарга кирәк. Мәсәлән, транспортларда синең янда басып барган әбиләр урынында әниеңне, я булмаса, үзеңне карт яшькә куеп карарга кирәк. Әйдәгез, сез алай булмагыз!

Рәхимле, шәфкатьле булыгыз. Гомумән, бар яктан да олыларга, кечеләргә ярдәм кулы сузарга әзер булыгыз.

Әдәп башы – гадәт. Бу – мәкаль. Кешеләрдә олы һәм кечеләргә шәфкатьле булу, кешелекле булу, юмарт һәм тугры булу гадәткә керсә, бу сыйфатлар аларда гел кабатланып торачак. Шулай итеп, кешеләр һәрвакыт шундый матур сыйфатларга гына ия булачак. Сез дә әдәпле, тәрбияле булыгыз. Шуның белән сыйныф сәгатебез тәмам.

**Әдәбият**

1. Каюм Насыйри. ”Китаб-эт-Тәрбия“ китабы. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1994.
2. ”Татар теленең аңлатмалы“ сүзлеге”. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1981.
3.Әдәбияттан хрестоматия. 9 сыйныф. Казан. ”Мәгариф” нәшрияты. 2005.

*Төзүче: Казан шәһәре Киров районы 4 нче гимназиянең*
*беренче квалификация категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*
*Юнысова Розалия Гани кызы*

**Тема: Хәтер дәресе**

**Максат һәм бурычлар**:

1. Бөек Ватан сугышы фаҗигасенең масштабын һәм Совет халкының бөеклеген күрсәтү.
2. Укучыларда тарихи кыйммәтләр нигезендә патриотик хисләр тәрбияләү.
3. Ватанга, туган якка карата горурлык, соклану хисләре уяту.
4. Татарстан халкының Бөк Ватан сугышында җинүне якынайтуга өлешләрен керткән герой сугышчылар белән таныштыру.
5. Геройларның батырлыгына хөрмәт тәрбияләү, аларның Бөек Ватан сугышы елларында күрсәткән батырлыклары, тырыш хезмәтләре белән таныштыру, сугыш ветераннарына олы хөрмәт уяту, кешеләрне хөрмәт итү хисе тәрбияләү.
6. Сугыш чоры кешеләренең җиңүгә булган ышанычын, батырлыгын, рухи ныклыгын аңлату.

**Сыйныф сәгатенең барышы**

**1. Мотивлаштыру-ориентлаштыру өлеше**

Бүген бик матур, кояшлы, тыныч көн. Әмма кешеләр һәрвакыт шулай тыныч, ямьле тормышта гына яшәмәгәннәр. 1941 елның 22 июнендә кешеләр дә бәхетле, яхшы кәеф белән уянганнар. Әмма нинди коточкыч сүздән алар курыкканнар ? (Сугыш)

Кемнәр аны чакырды,
Сызылып таңнар атканда?
Җәйнең июнь азагында,
Халык йокыда ятканда?
Кемгә кирәк булды ул,
Ник безнең илгә керде?
Ачы сагыш китереп,
Җилләр дулатып йөрде?
Җимереп ватып, төзелгәнне,
Челпәрәмә китерде.
Кызыл кандай җеп белән,
Кайгы — хәсрәтләр үрде...

4 ел Бөек Ватан сугышы бара. Бу сугыш турында без китаплардан, дәреслекләрдән һәм фильмнардан карап беләбез. Әмма бөтен кешелек дөньясына бу дәресне биргән кешеләр әле дөньяда яши. Алар инде бик-бик аз калдылар, ләкин безнең бәхеткә алар әле бар. Эле безгә аларның йөзләренә, күзләренә карап була, аларның гади, сугыш турында ачы сөйләүләрен ишетергә була.

Данлы еллар хәтирәсе булып,
Һаман сыкрый әле яралар.
Сезнең батырлыктан үрнәк ала
Җирдә күпме газиз балалар.

Кызганмыйча соңгы каныгызны,
Сакладыгыз изге Ватанны.
Сезнең исем Җирдә генә түгел,
Хәтта Галәмгә дә яңгырады.

Үткән тормышыгыз китап кебек:
Һәрбер бите чиста, пакь аның.
Сезнең бөек исем, һич тапланмый,
Күп гасырлар буена сакланыр.

### 2. Чараның темасын игълан итү

Солдатларның төп бурычы - Ватанны саклау бурычы булган. Ә аларны хәтерләү, аларны истә тоту - безнең бурычыбыз. Безгә сугыш дәһшәтләрен онытырга ярамый. Безнең киләчәгебез өчен һәлак булган солдатларны онытырга хакыбыз юк. Без барысын да истә тотарга тиеш, шуңа күрә бүген бездә ХӘТЕР ДӘРЕСЕ.




**3. Бөек Ватан сугышының ике көне**

Без Бөек Ватан сугышы турында сөйләгәндә беренче чиратта нинди ике дата хәтергә килә? Әйе, 1941 елның 22 июне һәм 1945 елның 9 мае.

Календарьның ике бите...

Җир планетасының ике көне...

Кешелек тарихының ике көне...

Алар календарьда төрле төсләр белән билгеләнгән:

берсе – кара төсле - һавадан төшүче бомба һәм автоматлы 1941 елның 22 июне- Хәтер һәм кайгы көне.




Икенчесе - кызыл көн- 1945 елның 9 мае - Совет халкының Бөек Ватан сугышында Җиңү көне.



Календарьның ике көн!. Ә алар арасында күпме яшь, хәсрәт. Шуңа күрә без 1941 елның 22 июнен дә, 1945 елның 9 маен да да истә тотарга тиеш.

Мәскәүдән Берлинга кадәр - 2600 км. Бик үк артык күп тә кебек түгел. Бу араны поезд белән 2 тәүлектә, самолет белән 3 сәгатьтә үтеп була.




Ә җәяүләп һәм үрмәләп -4 ел….
4 ел...1418 көн...34000 сәгать... һәм 27 млн. һәлак булган кеше.
Димәк:
Көн саен 19 мең кеше ,
1 сәгатькә 800 кеше,
Минутына 13 кеше үлүче.
Моны да без истә тотарга тиеш.

**4. Бөек Ватан сугышы ветераны белән танышу**

Әгәр без тарихның кабатлануын теләмибез икән, без бабаларыбызның батырлыкларын истә тотарга тиеш. Безнең илдә һәрбер гаиләдән дә Ватаныбызны саклау өчен сугышка киткәннәр. Ә минем әтием сугышта булган...




Минем әтием - Халиков Гани Халик улы 1924 елның 15 июлендә Апас районының Багыш авылында туган. 1941 елның 5 ноябрендә армиягә алына һәм

Горький өлкәсенең Кулебәк шәһәренә җибәрелә. Анда хәрби хезмәткә башлангыч әзерлек уза.

1942 елның уртасында Чита өлкәсенә хәрби эшелон белән җибәрелә. Шунда ук 582 нче укчы полкында хәрби хезмәт үтә. Полк 210 укчы дивизиясе составына керә. Бер елдан соң шул ук ротада командир итеп билгелиләр. Сугышчан казанышлары өчен «Кызыл Йолдыз» ордены һәм күпсанлы медальләр белән бүләкләнә.

Туган авылына 1947 елның 27 апрелендә кайта. Кызганычка каршы, 12 ел элек әтием вафат булды. Ул озын, гадел гомер кичерде.

Яшь чакта туган илен яклады, ә сугыштан соңгы елларда җитәкче урыннарда эшләде. Һәрвакыт гадел, мәрхәмәтле кеше иде. Сугыш беркайчан да кабатланмаганын теләде.

## 5. Солдат аналары турында

Минем әти сугыштан кайткан, ә кызганычка каршы, барлык аналар да үз балаларын сугыштан исән-сау кайтканнарын күрә алмаганнар...

Хәлләр ничек, солдат аналары?
Язлар җитте, көтеп балаларны
Теләп бар дөньяга тынычлыклар,
Озын-озак үтте быел кышлар.
Менә тагын берәү янып-көеп,
«Хәерле юл, балакаем», — диеп,
Яшен йотып, капка төпләрендә
Улын озатып калды. Кат-кат үбеп.
Ә кайсыгыз йоклый алмый төнен,
Улы тәрәз чиртер кебек бүген.
Берәвегез шатлык яшен сөртә.
Кемдер мәңге кайтмас улын көтә…

## 6. Бер минут тынлык

Халыкта шундый әйтем бар: “Тормыш киткәч - хәтер килә һәм хәтер тормышны дәвам итә…»

Һәлак булганнар истәлегенә 1 минут тынлык үткәрү традициясе бар.
Хәзер дә яу кырында һәлак булучыларны искә алып 1 минут тынлык тәкъдим итәм.

*( 1 минут тынлык)*

Әле генә без һәлак булганнарны бер минут тынлык белән искә алдык, ә һәлак булган һәрбер солдатка берәр минут тынлык игълан итсәк, күпме дәшмичә торырга туры килер иде безгә?
Һәрбер сугышта үлеп калучыны аерым искә алсак 38 ел кирәк булыр иде...

## 7. Ветераннарга хат

Кадерле укучыларым, без тыныч вакытта яшибез һәм моның өчен кемгә бурычлы икәнебезне бик яхшы аңлыйбыз. Сез өйләрегездә ветераннарга рәхмәт хатлары язган идегез, нәкъ сугышта язылган очпочмаклы хатлар формасында.

Өчпочмаклы солдат хатлары.... Аларда сугышның тетрәндергеч авазы. Без ул авазны аңларга тиешбез. Яшәүнең ямен, гомернең кадерен белү өчен.
Мин үземнең хатымны инде яздым, менә тыңлагыз:

"Хөрмәтле ветераннар! Бөек Ватан сугышы илебез тарихында тирән эз калдырган вакыйга. Сугышта илебез җинеп чыккан. Җину җиңел яуланмаган, ә бик-бик күп корбаннар, кеше гомере хисабына бирелгән. Утлы яу кырында калган гомерләрне, ни аяныч, кайтарып булмый. Кайтарып булмаса да, онытмыйбыз.

Рәхмәт сезгә ветераннар.
Буыннардан буыннарга...
Күчә барыр сезнең даннар...
Рәхмәт сезгә, ветераннар!
Берлингача барып җитеп.
Фашистларны тар-мар итеп
Илгә Җиңү китергәннәр,
Рәхмәт Сезгә!
Рәхмәт сезгә, ветераннар!"

*(Балалар үзләренен ветераннарга язган рәхмәт хатларын укыйлар)*

## 8. Татарстан Бөек Ватан сугышы елларында

Татар халкының уллары һәм кызлары Бөек Ватан сугышының бөтен хәлиткеч яуларында сугыша. Хәрәкәттәге армиягә республикадан 700 меңләп кеше алына. Шулардан 350 меңгә якыны (һәр икенчесе) Ватаныбыз азатлыгын һәм бәйсезлеген яклап сугышканда һәлак була. Аларның исемнәре 27 томлы Хәтер китабына кертелгән. Китапның максаты изге – татарстанлыларның сугышта күрсәткән батырлыкларын мәңгеләштерү, тыныч күк йөзебез өчен башларын салучыларның исемнәрен киләчәк буыннарга илтеп җиткерү.

Сугыш елларында якташларыбыз үзләрен кыю һәм курку белмәс сугышчы итеп күрсәтә. Легендар патриот-шагыйрь Муса Җәлил, Брест ныгытмасының чыдам сакчысы Петр Гаврилов, кыю очучы Мәгубә Сыртланова, төз укчы, Александр Матросов батырлыгын кабатлаган Газинур Гафиятуллин, ару-талуны белмәс сапер Мотыйк Әхмәдуллин һәм тагын бик күпләрнең исемнәре Бөек Ватан сугышы елъязмасына мәңгегә алтын хәрефләр белән язылган. Илнең иң югары бүләгенә лаек булган 11519 совет сугышчысы арасында татарлар, рус, украин һәм белоруслардан гына калышып, сан буенча 4 нче урында тора.

### 9. Йомгаклау өлеше

Кадерле укучыларым, Бөек Ватан сугышы солдатлары кебек үк сез дә үз илегезне яратыгыз. Һәм ышанасы килә, үз мәхәббәтегезне сезгә сугыш кырында исбатларга туры килмәс дип. Әмма сез үз мәхәббәтегезне киләчәктә яхшы укуыгыз, белемегез, намуслы хезмәтегез белән исбатлый аласыз. Бәлки, сез бик яхшы табип, галим булырсыз һәм Ватаныбызны Бөек ачышлар белән данларсыз. Бу да үз илеңне ярату бит. Тынычлык кына булса, калганы һичшиксез булачак. (13 нче слайд)

Барысы да «Һәрвакыт булсын кояш» җырын башкаралар.

*Төзүче: Казан шәһәренең 57 нче рус-татар урта мәктәбенең*
*югары квалификация категорияле туган тел укытучысы*
*Маткулова Чулпан Фердус кызы,*
*беренче квалификация категорияле туган тел укытучысы*
*Камалеева Гөлнара Рафаил кызы*

**Тема: Исемнәр бакчасында.**

**Максат:**

1) Дөньяви тормышта татар халык традицияләрен кулланырга өйрәтү;
2) Исемнәрнең тирән мәгънәгә ия булуын аңлату һәм аларның фәнни, тарихи, әдәби яктан өйрәнелүе белән таныштыру.

**Җиһазлау:**

Ноутбук, колонкалар, шарлар, Г.Саттар-Мулилле “Татар исемнәре ни сөйли”, плакатлар, китап күргәзмәсе, бишек, өй күренеше.

**Үткәрү формасы**: кичә.

Хәерле көн, кадерле укучылар, хөрмәтле кунаклар. Исемең матур, кемнәр куйган.... дигән сыйныф сәгатен башлыйбыз. Чарабызны безнең Урман арты бистәсендә туып үскән кызыбыз, хәзерге вакытта К.Тинчурин театры артисткасы Резедә Сәләхова сүзләре белән башларбыз. Игътибар белән тыңлыйбыз. *(1 мин)*

**РЕЗЕДА:** Иман... Иманлы кеше булыгыз. Халкыбыз аңына бик борынгыдан сеңгән төшенчәләр бу. Иманлы булу – ул динле булу, дингә генә табынып яшәү дигән сүз түгел әле, ул әхлакый кагыйдәләр буенча тормыш итүне аңлата. Әдәп саклау, инсафлы, намуслы булу, ата-ана хакын хаклау, ярдәмчел булу- шундый сыйфатлар безгә борын-борыннан, мирас булып калган.

Бәхетле бул, балам! Җиргә яңа кеше туа һәм якты дөнья белән исәнләшкәндәй, беренче тапкыр кычкырып аваз сала. Бәхетеннән чиксез шатланган әниләребез,елмаеп, сабыена төбәлә һәм әкрен генә әлеге сүзләрне

кабатлый: “ Син дөньяга килдең, син бәхетле, чөнки син тынычлык патшалык иткән кояшлы илдә тудың, аның киләчәге синең кулда”. *(2 мин)*

**Айсылу:** Әби-бабаларыбыздан калган традиция буенча, баланың дөньяга беренче аваз салуына Ана сәбәпче. Бала туа.. Әти-әни уенда баласына нинди матур, мәгънәле исем кушарга дигән иң беренче фикере туа. Исем мәгънәлерәк булган саен яхшырак, чөнки исемнең мәгънәсенә бәйле рәвештә балада холык та формалаша. Шуңа күрә дә иң беренче исем сайлаганда, ата-аналар балаларында кушыласы исемнең тирән мәгънәгә ия булуын телиләр. *(1 мин)*

**Укытучы: Исем кушу күренеше.**

Укучылар , сезгә Урман арты бистәсе имам-хатибы Радик хәзрәт балага исем кушуның ничек үтәлүен күрсәтеп китә. Рәхим итегез. *(5 мин)*

Рәхмәт, Радик хәзрәт! Исемне куштык.

**Исламия**: Яхшы исем кыйммәт барыннан да,
Аннан тугры дусны күрмисең,
Безнең хакта мәңге ядкарь булып,
Картаймыйча яши һәр исем.

**Укытучы:** Укучылар, шушы шигъри юлларга бәйле “Исемнәрдә-ил тарихы” дигән әйтем бар. Ничек аңлыйсыз? (*Исемнән тарихны белеп була, илнең тарихы турында белеп була.)*

**Укытучы:** Яхшы.

**Укытучы:** Сез туган ягыбыз, Казаныбыз тарихы белән бәйле нинди төрки-татар исемнәрен беләсез?

**Укучы**: Идегәй , Йосыф-Зөләйха, Сөембикә, Кубрат хан. *(1 мин)*

Исемнәр турында Рәсүл Гамзатов мондый сүзләр язган:.

**Укучы**: *(Ватманда)* Кыз бала исемендә йолдыз балкышы яки чәчәк нәфислеге, ир-ат исемнәрендә кылыч чыңы һәм китап акылы чагылсын! (Р.Гамзатов)

**Укытучы:** Кемдә нинди фикер туды? Ир-ат исемнәре кылыч чыңы һәм китап акылы чагылсын диелгән. Нинди ир-ат исемнәре?

**Укучы**: Ир-атлар нык булырга тиеш, аларга Минтимер, Тимерхан, Арслан, Алмаз, Булат кебек исемнәр куябыз. *(1 мин)*

**Укытучы:** Кыз бала исемендә йолдыз балкышы яки чәчәк нәфислеге дигәндә нинди хатын-кыз исемнәрен әйтә аласыз?

Хәзер чәчәк исемнәре белән бәйле нинди кыз исемнәре белүегезне тикшереп алыйк әле. Ике укучы чыгыгыз әле. Конкурс: кем күбрәк чәчәк белән ясалган исемнәрне күбрәк белә? . (Ландыш, Роза, Ясминә, Ләлә, Ширинә, Миләүшә, )

**Җиңүче бүләкләнә**. Афәрин!!! *(1 мин)*

**МУЗЫКА.**

**СЛАЙД.** Аклы ситсы күлмәгемнең
Якаларын кем куйган?
Әй Рәйхан, исемең кемнәр куйган
Сине күреп кем туйган?

**Укытучы:** Әйе, татар халкында әле кеше исемнәренә багышланган җырлар күп. Нинди татар халык җырларын беләсез?

**СЛАЙД.** “Сәҗидә”, “Мәдинәкәй”, “Җәмилә”, “Галиябану”, “Ал Зәйнәбем”. *(1 мин)*

**Укытучы**: Кеше исемнәренә багышланган бию такмаклары да бар икәнен беләсез. *(1 мин)*

**Айсылу:** Чал тарих дәвамында татар милли исемнәр хәзинәсе байый-тулылана, яңара, камилләшә баруын күрәсез, укучылар.

**СЛАЙД.** Хәзерге көндә дә кеше исемнәрен өйрәнү татар гыйлемендә актуаль. Татар кеше исемнәрен җыюда иң беренче чиратта, Саттаров Гомәр Фәиз улы исемен атап узарга кирәк. Аның ике сүзлеге бар. (*Күрсәтергә*). Мәшһүр галим-Гомәр Саттаров Мулилленең “Татар исемнәре сүзлеге”(1981), “Татар исемнәре ни сөйли?” (2000) китапларында 15 меңгә якын (төрдәшләре белән 20 меңнән артык) татар ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре тупланган. Аларның татарча һәм русча дөрес язылышлары, генезислары (кайсы тел сүзе булулары) күрсәтелгән, лексик мәгънәләре һәм этимологияләре аңлатылган. *(1 мин)*

**Укытучы:** Укучылар, хәзерге вакытта инстаграм челтәрендә, контакт һ.б социаль челтәрләрдә загс аккаундында атна саен иң популяр, сирәк исемнәр турында мәгълүмат-информация бирелә. Узган атнада Казан шәһәрендә 215 малай, 192 кыз туган. Аларга иң популяр исем-Ранел, Ясминә, Алинә, Әмир, Тимур , ә иң сирәк –Сөембикә, Адәм, Сөләйман исемнәре кушылган. *(1 мин)*

“Кеше исемнәре – гаҗәеп бер бакча. Җимеш бакчасында төрле агачлар үскән кебек, исемнәр бакчасында да төрле җимешләр- исемнәр бар”.(Ш.Бабич).

**Укытучы:** Бу юллар белән нәрсә әйтә алабыз? Мисаллар китерегез.
(исемнәр күптөрле, күпмәгънәгә ия) (1 мин)

**Исламия:** Чыннан да, исемнәр бакчасы татар-башкорт шагыйре Шәехзадә Бабич әйткәнчә, гаҗәеп бер бакча ул. “Исемнәр бакчасында” дип аталган шигырендә хатын-кыз исемнәренә карата матур шигъри юллары билгеле:

**Алсу:**

Гөлгенәнең керфекләре гөл киенгән,
Ике күзе тонык күл диелгән;
Ай, кояшның ак нурларын оялтырлык
Күзләренә чем-карачкыл нур җыелган.
(Гөлгенә - фарсыча-татарча “гөлдән генә гыйбарәт” мәгънәсендә)

**Ләйсән:**

Нәфисәгә сәлам нәфис җил аркылы ,
Беләсез – уңган туташ һөнәр колы,
Шагыйрьләрнең күбесенә илһам килә
Сезнең кеби назлы бил аркылы.
( Нәфисә - “нәфис, күркәм чибәр, кыйммәтле, затлы” дигәнне аңлата.)

**Регина Шакирова:**

Әй Зөләйха, бер елмайсаң, исертәсең,
Бер минутта биш туңдырып биш эретәсең:
Бер як күзең бер як кырын бер генә сал,-
Шул вакытта очыртасың, очыртасың...
(Зөләйха - гарәп теленнән “ шома, тыгыз гәүдәле”). *(1-2 мин)*

**Укытучы:** Ә хәзер 4г сыйныфы укучыларының исемнәр бакчасына тукталабыз. Исемнәрегезнең мәгънәләрен белеп килергә кушкан идем. Кайсыгыз әйтә?

**Укучылар** җавап бирә. *(4 мин)*

Сиңа исемне кем кушкан, ни өчен шундый исем кушканнар?

**Укытучы:** Ә хәзер “Исемнәр бакчасында” дигән конкурс үткәрәбез. Малайлар һәм кызлар чыгыгыз минем янга. Малайларга “Гөл” кушымчасына башланган хатын-кыз, ә кызларга “Ил” дән башланган ир-ат исемнәрен язарга.. Кем күбрәк белә? Сезгә 2 минут вакыт. Кем өсти? *(2 мин)*

**Җинүче бүләкләнә**. ( Гөлназ, Гөлгенә, Гөлинә, Гөлбану, Гөлшат , Гөлчәчәк, Гөләндәм, Гөлшат ( Татар исемнәре сүзлегендә 219 исем бирелгән; Илдар, Илнур, Илгизәр, Илгиз, Илфат, Илшат, Илфак 92 исем бирелгән ) АФӘРИН!

Укучылар, сезнең исемнәрегез дә тирән мәгънәле, әти-әниләрегез матур исемнәр кушканнар! Чарабызда бик күп исемнәрнең тарихы турында ишеттек. Тактада эленгән битләргә игътибар иткәнсездер. Бу исемнәр сезгә танышмы? (Әйе, сезнең исемнәр)

Болар сезгә нәрсәне хәтерләтә? (битләрне)

Нәрсәгә охшаганнар? (китап битләренә)

Нишләтә алабыз без бу битләрне?

Анда нәрсәләр куелган? Әйдәгез, китапны җыябыз. Менә нинди **матур китап** чыкты! Ә сезгә истәлеккә менә шундый китапчыкларны бүләк итәбез!

Бүгенге чара сезгә ошагандыр дип уйлыйм.

Киләчәк тормышыгызда файдасы булыр дип саныйбыз.

**Укытучы:**Укучылар, исем бетә икән – җисем бетә, башны кисү белән бер бит ул!

**Исламия**:

Гарьләнмә татарлыгыңнан,

Алыштырма исемеңне,
Онытма телеңне, илеңне,
Асылыңа кайт, татар!
Исемнәрегезне саклагыз, өйрәнегез! Сез – безнең киләчәгебез!
Игътибарыгыз өчен Сезгә дә кунаклар Зур рәхмәт! *(3 мин)*

*Төзүче: Казан шәһәре Мәскәү районы 2 нче лицей-интернатның беренче квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ибәтуллин Рамил Рәшит улы*

**Тема: Әдәплелек.**

**Максат:** Укучыларда әдәплелек тәрбияләү, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре , бөек шәхесләребезнең әдәплелек турындагы фикерләре белән таныштыру.

## Сыйныф сәгатенең барышы

**1.**Әңгәмә оештырыла.
-Исәнмесез, балалар. Кәефләрегез ничек? Кулларыгыз белән күрсәтегез.
*(Куллары белән күрсәтәләр)*
-Укучылар, без бүген сезнең белән безнең тормыштагы бик мөһим, бик кирәкле сыйфат турында сөйләшербез.
Ә хәзер бергәләп бөек шәхесебез Р.Фәхретдин язган юлларны укып китик.
**(Слайд №1)**
***Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә - тәрбияле баладыр. Ата- ана өчен тәрбияле бала кебек олы байлык һич булмас.***

***Ризаэтдин Фәхретдин***

-Бу юлларда нәрсә турында сүз бара?
*-тәрбияле бала*
-Тәрбияле сүзенең тагын нинди синонимнарын беләсез?
*-әдәпле*
-Сез ничек уйлыйсыз, без бүген нәрсә турында сөйләшербез?
*-Әдәплелек турында*
-Әйе, без сезнең белән әдәплелек, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында сөйләшербез.
-Әдәпле кеше нинди була соң ул?
**- ...**
ПРОЕКТОР СҮНДЕРЕЛӘ.

**2. Кластер төзү.**

-Хәзер без төркемнәрдә эшләрбез. Һәр төркем үзенең капитанын билгели. Әдәпле кешенең 3 төрле сыйфатын язарсыз, аннары чиратлашып тактага беркетерсез.

**3. "Түгәрәк уен"**

-Эйе, дөрес әйтәсез, әдәпле кеше үз сөйләменә бик игътибарлы була, ул һәрвакыт тылсымлы сүзләр кулланып сөйләшә.

-Тылсымлы сүзләр барлыгын барыбыз да беләбез. Әйдәгез, шуларны искә төшереп үтик әле. Моның өчен хәзер түгәрәк уен уйнарбыз. Түгәрәкләнеп басабыз, музыка астында менә шушы тартманы кулдан-кулга йөртәбез. Көй туктаганда, тартма кемдә кала, шул кеше тартмадан бер язуны алып укый, анда нинди тылсымлы сүз турында сүз барганлыгын әйтә.

-Олы кеше белән очрашкач, нинди сүз әйтәләр?(Исәнмесез)

-Йокыдан торгач (Хәерле иртә)

-Кешегә үтенечең төшсә (Зинһар өчен)

-Ашап бетергәч (Рәхмәт)

-Кешегә ялгыш бәрелсәң (Гафу итегез)

-Ашый башлаганда (Ашыгыз тәмле булсын)

-Кешегә сораган әйберен биргәндә (Рәхим итегез)

-Саубуллашканда (Сау булыгыз)

-Кич белән күрешкәч (Хәерле кич)

-Көндез күрешкәч (Хәерле көн)

-Йокларга ятканда (Тыныч йокы)

**4. Мизансцена күрсәтү.**

***Ситуацияләр бирелә. Шуларны укыйлар, әдәпсезлек мизгелен мизансценада күрсәтәләр.***

-Укучылар, хәзер сезгә бирелгән ситуацияләр белән эшлибез. Бирелгән ситуация белән танышасыз. Аннан әдәпсезлек мизгелен мизансценада күрсәтәсез. Сезнең сорау туарга мөмкин. Нәрсә соң ул мизансцена? Билгеле бер күренешне, хәрәкәтне чагылдырып, катып калган хәлдә күрсәтү. Моның өчен арагыздан режиссерны сайлап аласыз, ул рольләрне билгели, кем кая баса, нинди халәттә шуларны карый, тикшерә, кирәк булса төзәтә.

***1 төркем.***

Ситуация 1.

Укучылар кабинетка керергә ишек төбендә басып торалар. Бөтен кешене эткәләп-төрткәләп, Вәли ишеккә килә. Кабинетка кергәндә, чыгып килүче Зиләне этеп җибәрә, бер сүз әйтмичә, үз урынына барып утыра.

***2 төркем***

Ситуация 2.

Вәли, төшке аш вакытында, ашханәгә килә. Чиратта тормыйча гына, ризыкларын алып ашарга утыра. Ашаган вакытта телефонда уйный, җитмәсә авызын чәпелдәтеп ашый, өстәлгә ипи валчыкларын коя, иптәшләре белән кычкырып сөйләшә.

***3 төркем***

Ситуация 3.

Вәли, өйгә кайтканда, автобуска утыра. Ул алдагы урындыкларның берсенә рәхәтләнеп утыра. Колакчыкларын кия, телефонын кабызып уйный башлый. Аның янына карт кына бер әби килеп баса. Вәли әбине күрми дә, ишетми дә.

**5. Мезасценалар күрсәтелгәч, икенче группа нинди әдәпсез күренешләр булганын әйтә.**

**6.Ситуацияне төзәтү –телдән генә әйтәләр.**

-Бу эшләрне әдәпле кеше эшлиме?

-Юк.

**(Слайд №2)**

**-Әдәплелеккә әдәпсезләрдән өйрәндем,- дип язган Локман Хәким.** Димәк, укучылар, кемнеңдер әдәпсез эш гамәлен күреп, шуны үзең кабатламау безне тәрбиялелеккә илтә.

7.”**Төшеп калган сүзне куй”**

**Ике төрле Тәүфыйк.**

Мәктәптә безгә еш кына Директор да күргән икән,
Күрсәтәләр Тәүфыйкны Үрнәк итеп китерде.
Һәм мактыйлар: Кайсыннан үрнәк алыйк соң-
-Ул Тәүфыйклы, Тәүфыйк бит ике төрле!
Бер дә бозмый тәртипне. Берсе “**Рәхим итегез**”не
Кызлар белән дә тату бит, Сүз аралаш кыстыра.
Мөгамәлә матур бик- Икенчесе,тел күрсәтеп,
Ялгыш кына кагылса да: Аяк тибеп кычкыра.
-Кичер мине**, гафу ит...** Тәртипле дип әйтсеннәр дип,
Шулай итенгән була-
Юри аякка баса да
Гафу үтенгән була...

-Балалар, сезгә бу малай ошадымы? Ул бит тылсымлы сүзләрне белә?!

-...

-Әйе,балалар,тылсымлы сүзләрне дөрес кулланганда гына алар шифалы була. Ә аларны дөрес куллану өчен әдәплелек кагыйдәләрен беләргә кирәк.

***8.*Табышмаклар белән эш. *“Әкият геройларын беләсеңме?”.***

-Укучылар җир йөзендә тәрбияле кешеләр күп. Без алардан үрнәк алабыз. Әйдәгез, яхшы эш-гамәл кылган төрле халык әкиятләре геройларын таный алырсызмы икән?
**1)**Мин бик тә әбиемне яратам.
Ул урман артында яши, авырып китте.
Мин аның өчен борчылам һәм аңа пәрәмәчләр илтәм. (Кызыл калфак)
**2)**Авыр минутта мин һәрвакыт хуҗам янында.
 Аның бәхете өчен миңа "людоед" ягъни кеше ашаучы белән очрашырга туры килде.
Минем аягымда матур итекләр. (Итекле песи)
**3)** Минем ике апам бар.
Әнием авырып китте.
Бер апам - бакага, икенчесе үрмәкүчкә әверелде.
Мин кулларым камырлы килеш әнием янына йөгердем. ( Төпчек кыз)
**8.Рефлексия өлеше**
**-**Мин сезгә ситуация әйтәм, сез әдәплелек булса, кул чабарсыз, әдәпсезлек булса, каты итеп тыпырдарсыз**.**
Очрашканда исәнләшү
Этеп җибәрү, гафу үтенмәү.
Төшеп киткән әйберне алып биру.
Урыннан гына укытучыга эндәшү.
Төчкергәч, гафу итегез дип әйтү.
Өлкән кешегә урын бирмәү.
Кешегә ярдәм иткәнең белән мактану.
Өлкән кешегә "Сез" дип эндәшү.

-Афәрин. Сез дә әдәплелек кагыйдәләрен үтәрсез дип ышанам.
*Әдәплелек нәрсә дигән сүз?*
*Әдәплелек- кеше белән дөрес аралаша белү ул.*
*Әдәпле булу- кешегә игътибарлы, инсафлы булу дигән сүз.*
*Әдәпле кешене һәркем ярата, хөрмәт итә.*
*Әдәпле кеше һәрвакыт үзенең якыннары,дуслары турында кайгыртып яши, аларга ярдәм итәргә әзер тора.*
*Әдәпле, чын тәрбияле баланың тик торырга вакыты калмый. Аның һәр эше алдан исәпләнгән була.*
*Әдәпле укучы мәктәпкә дә, эш эшләргә дә бервакыт соңга калмый.*
*Әдәпле кеше начар сүзләр кулланмый, ул дөресен генә сөйли.*
*Әдәпле бала этешми, төртешми, кешене үртәми***.**

*Төзүче: Казан шәһәре Идел буе районы 68 нче татар –рус урта гомуми белем мәктәбенең беренче квалификация категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы Андреева Елена Василий кызы*

**Тема: “Көчле, бай, ягымлы да ...”**

**Максат:**
- Туган телебезнең байлыгын, матурлыгын, камиллеген күрсәтү, телебезне сакларга һәм якларга кирәклеген төшендерү;
- сөйләм күнекмәләрен үстерү, тел турында күзаллауларын киңәйтү;
- туган телгә карата кызыксыну уяту, туган тел турында күбрәк белү теләге булдыру.

**Җиһазлау***:* мультимедиа слайдлары, музыкаль бизәлеш, туган тел турында плакатлар, китап күргәзмәсе.

**Үткәрү формасы:** әдәби кичә.

**Әдәби кичә бишек җыры белән башланып китә.**

*1нче алып баручы:* Дөньяга саф, пакъ, чиста күңелле, беренче авазлары белән, үзенә яшәү хокукы даулап яңа кеше туа. Ананың йөзләрендә елмаю, шатлык. Менә бит аның тугыз ае буе карынында җил-давыллардан саклап, яклап йөрткән нәние аваз бирде. Бала әкрен генә үсә һәм көннәрдән бер көнне үзенең беренче, иң татлы, көтеп алыган сүзләрен әйтә: Әннә, Әттә. Бу мизгелдә әти белән әнидән дә бәхетле кеше булмый. Менә аның нарасые Ана телендә беренче сүзләрен әйтте. Ана теле. Туган тел. Татар теле.

*1 нче укучы.*

Арттырмыйм да, киметмим дә, шуны бел –
Татар теле – энҗе-мәрҗән тулы тел.
Моңлы тел ул, нурлы тел ул – Туган тел –
Баш очында кояш булып тора гел!

*2 нче алып баручы.*

Изге сүзләр болар барысы - изге догам,
Минем арттан кабатла син, әйдә, балам.
Күңелеңнең түренә үк калсын кереп,
Яши-яши аңларсың син барча серен.
Моңлы тел ул, нурлы тел ул – Туган тел! –
Баш очында кояш булып тора гел! (Ф.Әмәк)

Февраль аенда һәр илдә - Халыкара туган тел көне билгеләп үтелә. Әлеге көннең тарихы Пакистан белән бәйле. Пакистанда 1952 нче елның 21 нче февралендә бенгал теленә дәүләт статусы бирүне таләп итеп чыгыш ясаган биш студент үтерелә. Шушы вакыйгадан соң 47 ел үткәч, 1999 нчы елда, 21 нче

февраль Бангладеш тәкъдиме белән, ЮНЕСКО тарафыннан Халыкара туган тел көне дип игълан ителә.

*1 нче алып баручы.* Татарстан күпмилләтле дәүләт. Һәр милләтнең, һәр телнең яшәеше, үсеше өчен шартлар булдырылган. Президентыбыз Р.Миңнеханов тарафыннан туган телләрне саклау, үстерү, халыклар бердәмлеге, дуслыгы өчен төрле эшләр башкарыла, проектлар тәкъдим ителә. 2021 нче ел “Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы” дип игълан ителде.

*2 нче укучы.*

Туган телем
Дөньяда иң-иң матур ил,
Ул – минем туган илем.
Дөньяда иң-иң матур тел,
Ул – минем туган телем.
"Балам!" - диеп туган телдә
Эндәшә миңа әткәм.
"Әнием!" - дип, әнкәемә
Мин туган телдә әйтәм.
Туган телемдә сөйләшеп,
Яшим мин туган илдә.
“Туган ил” сүзне дә
Әйтәм мин туган телдә.
Иң изге хисләремне мин
Туган илдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин, яратам. (*Энҗе Мөэминова)*

*2 нче алып баручы.* Туган тел төшенчәсенә зур мәгънә салынган. Туган ил, Ватан, Туган җир, ата-ана, әби-бабай... Туган иле кебек туган теле дә һәркемгә дә кадерле. Без - татарлар, туган телебез - татар теле, туган җиребез татар иле – Татарстан. Безнең дә бай тарихыбыз, иҗат мирасыбыз бар. Татар теле дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән. Бүгенге көндә ул фәнни яктан да камилләшкән, җитлеккән тел. Без татарча сөйләшәбез, татарча уйлыйбыз, фикерлибез, җырлыйбыз. Без бүген дә горур.

*1 нче алып баручы.* Әйе, татар теле горур тел. Әмма тарихка күз салсак, татар теле үзенең үсеш дәверендә катлаулы юл үтә. Төрле киртәләргә очрый, әмма беркайчан да югалып калмый.

*3 нче укучы.*

Туган җирең Идел буе,
Һәр телнең бар Туган иле.
Туган җирең кебек назлы,

Җырдай моңлы татар теле.
Ак алъяпкыч бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йөзле татар теле.
*4 нче укучы.*
Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син көне-төне.
Ир-егетләреңдәй дәртле,
Гайрәтле син, татар теле.
Ассалар да, киссәләр дә
Үлмәдең син, калдың тере.
Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле.
*5 нче укучы.*
Яндың да син, туңдың да син,
Нишләтмәде язмыш сине.
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй, мөкатдәс Тукай теле.
Төрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән бергә сине.
Төрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.
Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире,
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син, батыр татар теле! (Н.Нәҗми)
*1нче алып баручы.* Галимнәрбез, язучыларыбыз татар теленең, туган телнең бөеклеге, әһәмияте, мөһимлеге турында хикмәтле, матур сүзләр, фәлсәфи уйланулар әйтеп калдырганнар.
Татар телен Такташ сөйде,
Тукай өзелеп мактады.
Урам теле түгеллеген
Насыйри да яклады.
*6 нчы укучы.* “Берәр кеше башка телне өйрәнмәкче булса, башта үз телен белсен”, - дигән Каюм Насыйри.
*7 нче укучы.*
Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,

Бүтән телләр белү яхшы һөнәрдер.
Катыштырма вәләкин телгә телне,
Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер, - дип кисәтә Дәрдемәнд.

*8 нче укучы.* “Тел - халыкның акылын, гореф-гадәтен, дөньяга карашын, фәлсәфәсен, тарихын, кыскасы, бөтен күңел байлыгын, мең еллар буена үзенә сеңдереп килеп, безнең заманнарга җиткергән чиксез кадерле хәзинә”, – дигән Гомәр Бәширов.

*9 нчы укучы.*
И минем җандай кадерлем,
И җылы, тере телем!
Кайгылар теле түгел син,
Шатлыгым теле бүген (Х.Туфан)

*10 нчы укучы.*
“Туган оясыннан аерылган кош
Канатына мәңге ял тапмый.
Туган телен яратмаган кеше
телен яратмый”, - дип яза Әхмәт Ерикәй.

*11 нче укучы.* Ә менә бөек рус педагогы К.Д. Ушинский: “Халык сөйләмендә тел үлдеме, тел иясе буларак халык үзе дә үлә”, - дигән.

*2 нче алып баручы.* Татар халкы бөек шәхесләргә бик бай. Туган телебезне югары биеклеккә күтәргән Тукаебыз, таш зинданнарда да татар булып калган батыр Җәлилебез, мәхәббәтнең бөек хис булуын күрсәткән Кол Галиебез, татар теленең бөеклеген исбатлаган Хәсән Туфаныбыз, туган җиргә мәдхия җырлаган Гомәр Бәширов, Мөхәммәд Мәһдиев һәм башка олуг затларыбыз бар. Алар барысы да иҗат итәр өчен, яшәр өчен көчне туган телдә, халыкта, туган җирдә тапкан. Ул көч – халык көйләрендә, халык моңнарында.

Татар җыры ерак тарихлардан
Алып килә халык хәтерен.
Оялчан ул, ямьле, ягымлы ул –
Үзе салмак, үзе әкрен.
*(татар халык җыры)*

*1нче алып баручы.* Туган тел турында мәкальләр дә бар бит әле. Аларда халкыбызның тапкырлыгы, зирәклеге, телгә булган мәхәббәте күренә. Халык мәкальләрендә хикмәт бар икәнлеген дә онытмаска кирәк. Мин сезгә мәкальләрнең башын укыйм, ә сез дәвам итегез.

Туган тел – үзем өчен, башка тел – …… (көнем өчен).

Һәр илнең ачкычы – тел, телен белгән …… (ил ачар).

Кешенең теле аңа дан да китерә ала, …. (хурлык та китерә ала).

Туган телем – иркә гөлем, киндер сиңа ....... (күңел түрем).

Тәмле тел таш яра, тәмсез тел ……….. (баш яра).

Алтыда белгән ана телен ……… (алтмышта да онытмас).

Ананың балага биргән иң зур бүләге …. (тел).

Туган телен кадерләгән халык …. (кадерле булыр).

Иң татлы тел - туган тел, ….. (анам сөйләп торган тел).

Рәхмәт, укучылар. Туган тел турында мәкальләрне яхшы беләсез икән.

*2 нче алып баручы.* Шул рәвешле, халкыбыз безгә төрле чаралар аша киңәшләрен биргән, безне тәрбияләгән. Хәзер сез туган телнең кадерен белмәгән тиен малае һәм аның үз хатасын аңлавы турында бер әкият тыңларсыз.

*Аю, Куян, Төлке, Бүре аркаларына сумкаларын асып, табышмаклар әйтешеп, укырга баралар. Каршыларына Тиен малае очрый.*

*Тиен:* Сез кая барасыз болай иртә таңнан?

*Куян:* Без Ябалак абый ачкан татар мәктәбенә укырга кердек. Шунда барабыз.

*Тиен малае:* Татар мәктәбенә? Көлдермәгез инде. Анда нәрсә эшлиләр соң?

*Аю:* Туган телебездә укырга, язарга өйрәнәбез.

*Төлке:* Татар халык җырларын җырлыйбыз, уеннарын уйныйбыз.

*Бүре:* Кызыклы әкиятләр укыйбыз.

*Тиен малае:* Белем алып кем баеган? Яз, укы, сана. Өстәвенә татар телендә... Кемгә кирәк ул?! Мин русча беләм шул җиткән.

*Бүре:* Их, син Тиен малае. Туган телеңне белергә кирәк. Менә тыңла әле синең кебек малайлар турында бу.

И родной тел, и красивый,
Папам, мамамның теле.
Мог я узнать күп нәрсәне
Син родной тел аркылы.
Бу языкта коляскада
Мамкам сказку көйләгән.
А затем төннәр буена
Бабуля рассказ сөйләгән.
*Төлке:* А потом ни сәбәптәндер
Өйрәткәннәр рус язык.
Якобы, тик шушы
Алам духовный азык.
Почему же нас детсадта
Синa өйрәтмәделәр?
В школе когда обучали
Синдә сөйләтмәделәр
*Аю:* Вузга поступать иткәндә
Говорят син кирәкми

Дальше – больше жить иткәндә
Нужен ли ты вряд ли.
И родной тел, и матур тел,
Папам, мамамның теле.
Только я их обвиняю
Өйрәтмәгәнгә сине.
Куян: И родной тел, аңлаталар:
Можно жить и синсез.
Папа, мама и бабуля
Оставили меня телсез. *(*Вил Казыйханов)

*Аю, Куян, Төлке, Бүре бергә "Туган тел" җырын җырлыйлар, төрле уеннар уйныйлар. Тиен малае җырны хушы китеп тыңлый, уеннарны кызыгып карап тора.*

*Тиен малае:* Карагыз әле, чынлап та күңелле бугай сезнең мәктәбегездә. Минем дә туган телемдә сөйләшәсем, туган телемдә уйлыйсым, уйныйсым килә. Мине дә үзегез белән алып барыгыз әле?

(*Тиен малаен үз яннарына алып, мәктәпкә китәләр*).

*2 алып баручы*. Дөньяда бик күп телләр бар, ләкин һәр кешегә иң матур тел – туган тел. Күп кеше берничә тел белә, шулай да туган тел иң кадерлесе, иң матуры булып кала. Безнең Татарстаныбызда татар һәм рус телләре дәүләт теле булып санала. Ике телне дә яхшы белү безгә башка милләт вәкилләре белән дус, тату, ярдәмләшеп яшәргә ярдәм итә.

*12 нче укучы.*
Татарча да яхшы бел,
Урысча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле татлы тел.

*13 нче укучы.*
Тел кешене дус итә,
Бер-берсенә беркетә.
Бел, балам, син рус телен
Һәм онытма үз телең!

*1 нче алып баручы.* һәр тел үзе бер дөнья. Тел ул халык күңеле, аның шатлыгы, кайгысы, хәтере, хәзинәсе. Һәр тел хөрмәткә лаек. Кешенең һәр эш-гамәле тел ярдәмендә башкарыла. Телсез фәнне дә, техниканы, сәнгатьне, тормышны да алга таба җибәреп булмый. Бу мәгънәсез бер эш булыр иде.

Җир шарында бик күп телләр бар: татар, рус, казах, алман, инглиз, гарәп, француз һ.б. Кешелек үсешендә төп роль уйнаган 6 телне аерып күрсәтәләр. Болар – инглиз, француз, рус, испан, кытай, гарәп телләре.

Әйдәгез, төрле телләрдә исәнләшеп карыйк. Беләсезме икән?
гуд монин – инглизчә
гутен таг – алманча
бонжур– французча
испан телендә - Буэнос
китай телендә - ни хао
гарәп телендә - әссәләмәгаләйкүм
удмурт телендә – зечбур
корей телендә - аньон хасейо
төрек телендә - мәрхаба

*1 нче алып баручы.*

Күп милләтле илем булгач,
Сөйли төрле телләрдә.
Күп милләтләр телен белү –
Артык түгел кемгә дә.
Бөтен тел үзенчә яхшы,
Сөйләшик төрле телдә
Үзебезнең ана теле,
Булсын йөрәк түрендә.
*(Татар халык җыры башкарыла*)

*2 нче алып баручы.* Татар теле матур, бай, аһәңле, күркәм тел. Туган телебездә рус сүзләрен кушмыйча камил, матур сөйләшергә кирәк. Аның өчен әдәби китаплар укырга, театрларга йөрергә киңәш итәр идем сезгә. Ә хәзер әйдәгез сезнең сүзлек байлыгыгызны тикшереп карыйк әле. Тактада САБАКТАШЛАР дигән сүз язылган. Әлеге сүздән мөмкин булган татар сүзләрен язып алыгыз. Иң күп сүз төзи алган укучы җиңә. *(Кара-каршы әйтешәләр*)

*Укытучы:* Туган телебез – Татар теле. Телебезне саклау, яклау безнең изге бурычыбыз. Милләтнең теле кулланылмый башласа, ул юкка чыга. Ә тел бетсә, халыкның мәдәнияте дә, әдәбияты да, гореф-гадәтләре дә бетә, юкка чыга. Туган телебезне саклау һәм киләчәк буынга тапшыру бары үзебездән тора. Телебезне, милләтебезне саклыйк! Сыйныф сәгатебезне
С. Әхмәтҗанованың “Аңла, балам...” шигырен укып тәмамлыйсы килә.

Илләр, телләр, диннәр алмашына –
Ниләр көтә адәм баласын?
Аңла, балам, сине үзең итеп
Туган телең саклап каласын.
Куштым сиңа сайлап матур исем
– Җисемеңә туры килсен ул.
Милләтеңнең бер мирасы итеп,

Әткәң - әнкәң биргән исем ул.
Вакыт белән бергә үзгәрә бел
Телләр өйрән, балам, дөнья күр.
Йөз чөермә ләкин үз телеңнән:
Бу – Ватанны сату белән бер.
Син тугач та, ана сөте белән
Иренеңә тамган туган тел.
Туган телең җуйсаң, әнкәеңне
Онытуың булыр, балам, бел!

*Төзүче: Казан шәһәре Яңа Савин районы 23 нче лицейның*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Кәримова Алинә Халит кызы*

**Тема: Аралашу серләре**

М**аксаты:** Туган татар теле чараларын кулланып, балаларның аралашу осталыгын үстерү.

**Бурычлар**:

– игътибарлылыкны ныгыту, образлы күзаллау булдыру; балаларны сөйләм культурасына өйрәтү, татар теленең хәзерге заман нормаларына нигезләнеп, дөрес әдәби сөйләмгә өйрәтү;

– коллективизм, активлык, яхшы күңеллелек тәрбияләү;

коллективта эшләү һәм уртак кагыйдәләргә буйсыну сәләтен формалаштыру;

**-** иҗади һәм актерлык сәләтен, сәнгати зәвыкны, ишетү сәләтен, оештыру сәләтен үстерү.

Эшне **оештыру формалары -** төркемнәрдә, шәхси, фронталь.

**Сыйныф сәгате барышы**

1. Бервакыт ике кеше бәхәскә кергәннәр. Иң матур һәм коточкыч әйбер нәрсә ул? Бәхәсне үзләре генә чишә алмагач, дөреслекне эзләп, аксакал (мудрец) янына килгәннәр. “Иң гүзәл әйбер нәрсә ул?”, дип сораганнар. Аксакал болай дип җавап биргән.

Балалар, ничек уйлыйсыз, аксакал нәрсә дип җавап биргән?

Аксакал әйткән: “Дөньяда иң гүзәл нәрсә ул – тел. Тел белән без иркәләү, тугрылыклы булу һәм сөю сүзләре әйтәбез. Тел белән тынычлык урнашуны белдерәбез, тел белән без “ирек” сүзен әйтәбез”.

Шунда икенче иптәш: “Ә иң коточкыч әйбер нәрсә?”, дип сораган.

Балалар, әйтеп карагыз әле, аксакал нәрсә дип җавап бирде икән?

Ә ни өчен шулай дип җавап биргән?

Иң коточкыч нәрсә ул – тел. Тел белән без нәфрәт сүзләрен әйтәбез. Тел белән без “сугыш” игълан итәбез. Тел белән без “кол” сүзен әйтәбез.

- Тел нәрсә өчен кирәк?
